КАБАТЛАНГАН КОРЫЛЫК

Синоптиклар аграрийларны сөендерерлек фаразлар әйтми

> 2

ВАТАН ХАКЫНА

Махсус хәрби операциядән укытучылар да читтә калмады

> 3

БӘРӘҢГЕДӘ КҮРГӘННӘР

«ВТ» журналисты Мари Эл Республикасында булып кайтты

> 4



ХА-ХА-ХАНӘ

Булмас димә, кызык-мызык, фототөрткеләр – монда

> 8

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 143–144 (29110–29111) | Сишәмбе | 3 октябрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

ИЛ КӨТӘ, СОЛДАТ КИТӘ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Хәрби хезмәт

Егетләрне көзен саныйлар. Мәгълүм булганча, 1 октябрьдән хәрби хезмәткә көзге чакырылыш башланды. Гадәттәгечә, ул ел азагына кадәр дәвам итәчәк. Чакырылышның быелгы үзенчәлеге нидә? Хезмәт итү вакыты үзгәрәме? Ир-егетләрне махсус хәрби операция зонасына җибәрмәсләрме?

Билне кысып буар чак

Чакыргач, барасы. Казаннан Азат Гыймаев шулай ди. Качып йөрергә уенда да юк. Быел укуын тәмамлаган егеткә хәрби комиссариаттан повестка килгән.

– Быел көллиятне тәмамладым. Укыган чакта «отсрочка» бар иде. Хәзер эшкә урнашып йөрим. Берсендә: «Военнигың хәл ителеп бетмәгән, без сине эшкә алырбыз да, ә син китәрсең», – дип алмадылар. Гәрчә махсус курслар узып, урнашам дип йөрсәм дә. Шулай булгач, качып йөрүнең ни файдасы бар? – ди ул. – Повестка почтага килде. Алдым да үзем бардым. Качып, үземнең тынычлыгымны бетереп йөрисем килми. Чакыргач, барасы.

Бу чакырылышта солдат шинелен **130 мең кеше** кияргә тиеш. Алдан ук кисәтеп кую дөрес булыр: хәрби хезмәткә чакырылган егетләрне ЛНР, ДНР, Херсон, Запорожье өлкәләренә һәм башка хәрби хәрәкәтләр зонасына җибәрмәячәкләр. Хәрби хезмәт срогы узуга, аларны өйләренә кайтарачаклар.

Билгеле булганча, быел **хәрби хезмәткә чакыру яше**нә үзгәрешләр дә кертелде. Закон нигезендә 18–30 яшь аралыгындагы ир-егетләргә солдат итеген киясе дигән сүз. Әмма бу үзгәрешләр 2024 елның гыйнварыннан гына үз көченә керәчәк. Шуңа күрә быелгы көзге чакырылышка 18–27 яшь аралыгындагы хәрби хезмәткә яраклы ир-егетләр эләгә (1996–2005 елларда туучылар). 27 яшен тутырган егетләр запаска туплана.

Армия сафында **хезмәт итү вакыты үзгәрешсез** кала. Егетләр Ватан алдындагы бурычын **12 ай**, ягъни бер ел үтәячәк. Хәрби хезмәткә чакырылган егетләр башта теоретик һәм практик белемнәрен ныгыта, аннан хәрби өйрәнүләрдә катнаша.

Кемнәр хезмәттән азат?

«Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында»гы Закон нигезендә **армиядә хезмәт итүне кичектерү** (отсрочка) хокукыннан файдалана алучы кешеләр категориясе:

– сәламәтлегенә бәйле рәвештә хезмәт итәргә яраксыз дип табылган гражданнар;

– башка опекуннар булмаганда якын туганнарын даими караучылар;

– 2 яисә аннан да күбрәк баласы булганнар яки өч яшькә кадәрге инвалид бала үстерүчеләр, шулай ук йөклелекнең 26 нчы атнасында булган хатын-кыз белән рәсми никахта яшәүчеләр;

– IT белгечләр, югары уку йорты һәм аспирантурада укучы студентлар.

Мылтык тотып хезмәт итәргә теләмәсәң, альтернатив хезмәт бар. Дөрес, аның вакыты озаграк – 18–21 ай. Мондый хәрби хезмәтне кемнәр уза ала соң? Мәсәлән, армиядә хезмәт итү үзенең әхлакый яки дини ышануларына каршы килә дип санаучылар, шулай ук аз санлы халык вәкилләре. Альтернатив гражданлык хезмәтен узу өчен һөнәрләр исемлеге дә бар. Исемлеккә 64 эшче һөнәр (автомобиль йөртүче, йөк ташучы, җыештыручы, рәссам, официант, аш-су остасы, ашханә эшчесе, чишенү бүлмәсендә эшләүче һәм башкалар) һәм 85 хезмәткәр (тәрбияче, табиб, зоотехник, икътисадчы) кергән.

Сүз уңаеннан, 2023 елның 24 июнендә Россия Президенты Владимир Путин хәрби хезмәт юлын узу югары уку йортларына һәм көллиятләргә бюджет урыннарына кергәндә шәхси казаныш буларак исәпкә алыначагы турында закон имзалаган иде.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Белгеч киңәше

Булат ЗАКИРОВ, «ВТ» юристы:
– Хәрби хезмәткә чакырулы затка нинди очракларда административ җаваплылык каралган? Хәрби комиссариатка җитди сәбәпләре булмаган килеш килмәгән өчен – 10–30 мең сум, яңа яшәү урынына күченгәндә хәрби исәпкә басмаса – 10–30 мең сум, хәрби комиссариатка гаилә хәлен, эш урынын, вазыйфасын үзгәртү турында хәбәр итмәгән өчен 1000 сумнан 5000 сумга кадәр штраф каралган. Шулай ук хәрби комиссариатка Россиядән алты айдан артык вакытка китүе яки Россиягә кире керүе турында мәгълүмат бирмәгән өчен 5 меңнән 15 мең сумга кадәр штраф яный. Хәрби исәп документын югалткан яки бозган өчен 3000 сумнан 5000 сумга кадәр штраф каралган. Шул ук вакытта хезмәткәренә повестка килүе турында хәбәр итмәгән эш бирүчеләр дә җаваплылыкка тартылачак. Җитәкчеләр өчен штраф күләме – 60–80 мең сум, оешмалар өчен 400–500 мең сум тәшкил итә.
Җинаять җаваплылыгы да бар. Әйтик, хезмәттән азат итү өчен законлы нигез булмаганда хәрби хезмәткә чакырудан качкан өчен 200 мең сумга кадәр штраф яки 18 айга кадәрге чордагы хезмәт хакы, башка кереме күләмендә штраф, ике елга кадәр мәҗбүри эшләр, алты айга кадәр кулга алу яки ике елга кадәр ирегеннән мәхрүм итү каралган.

Озакка сузылган кисәтү

Татарстан урманнарында янгыннар чыгу мөмкинлеге турында кисәткәннәр. Гидрометеоүзәк хәбәренә караганда, республикада 3–9 октябрь чорында урманнарда урыны белән югары – IV класслы куркыныч саклана. Яңа кисәтү инде ике айдан артыграк вакыт дәвамында гамәлдә.

Быел урманнарда янгын куркынычының зур булуы турында тәүге кисәтү 13 апрельдә игълан ителгән иде. Ул 12 тапкыр озайтылды. 24 июльгә кадәр гамәлдә булды. Әмма яңгырлар яумау сәбәпле, 2 августтан соң янә кисәтү игълан ителде.

Игътибар! 26 сентябрьдән республика урманнарына җәяү һәм транспортта керү чикләнгән. Чикләү 21 көн гамәлдә булачак.

Көзге мәшәкатьләр

Кырларда урып-җыю эшләре дәвам итә. 70 мең гектар мәйданда көнбагыш, 26 мең гектар мәйданда шикәр чөгендере, 35 мең гектар мәйданда кукуруз (20 мең гектары суктырылачак) җыеп алырга кирәк. Шулай ук 1,4 гектар мәйданда бәрәңге, 854 гектар мәйданда яшелчә җыясы бар әле.

Татарстан Премьер-министры урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров әйтүенчә, бүгенгә шикәр чөгендере мәйданының яртысында эшләр төгәлләнгән. Барлыгы 846 мең тонна тамыразык җыеп алынган. Республикада гектарыннан уртача 327 центнер уңыш чыга. Шикәр заводларында 250 мең тонна чөгендер эшкәртелеп, 38,6 мең тонна шикәр комы җитештерелгән.

Бәрәңгегә килгәндә, анысы бүгенгә 3,5 мең гектар мәйданда (72 проценты) җыеп урнаштырылган. Гектарыннан уртача 258 центнер уңыш чыга.

Быел һава шартлары уҗым культураларын вакытында чәчәргә мөмкинлек бирә. Планда каралган 526 мең гектар урынына 550 мең гектар мәйданда чәчү эшләре башкарылган (план 105 процентка үтәлгән). Министр билгеләп үткәнчә, бик коры булу сәбәпле, туфракка асылда сыек ашлама кертелгән.

Уңайлы түләү

Быел алты ай эчендә Татарстанда банк карталарындагы акча күләме, узган елның шушы ук чорындагыга караганда 17 процентка артып, 386,5 миллиард сум тәшкил иткән.

Россия банкының Татарстандагы бүлеге мәгълүматларына караганда, республикада беренче яртыеллыкта банк карталары белән барлыгы 516,6 миллион тапкыр түләгәннәр. Узган елдагыга караганда 12 процентка зуррак сан бу. Шул ук вакытта түләүнең уртача күләме – 748 сум, терминалдан «тере» акча алуның уртача күләме 18,3 мең сум тәшкил иткән.

Шимбә – ярминкә көне

Авыл хезмәтчәннәре дүрт ярминкә көнендә барлыгы 312,2 миллион сумлык азык-төлек саткан. Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы матбугат хезмәте хәбәренә караганда, шәһәр халкы фермерлардан барлыгы 3169,1 тонна яшелчә, 2221,5 тонна бәрәңге, 57 тонна шикәр комы, 239,9 тонна ит һәм 61,3 тонна сөт сатып алган.

Ярминкәләр 9 сентябрьдә башланды. Алар һәр шимбәдә Казанның 14 мәйданчыгында, Чаллы һәм Яшел Үзән районында – ике, Түбән Камада өч урында уздырыла. Моннан тыш 26 муниципаль районда да кайбер көннәрдә ярминкәләр үткәрелә. Алар 23 декабрьгә кадәр дәвам итәчәк.

Яңалык

Октябрь ае үзгәрешләре

Мошенникларга юл ябыла, хәрбиләрнең пенсиясе арта, повестка буенча хәрби комиссариатка килмәүчеләрне саллы штрафлар көтә.

✓**Хәрбиләрнең хезмәт хакы һәм пенсиясе арта.** Контракт буенча хезмәт итүчеләрнең вазыйфасы һәм званиеләре буенча оклад күләме 10,5 процентка күбәя. Шулай ук хәрбиләрнең пенсиясе дә арта. Моннан тыш, Хөкүмәт карары нигезендә, башка көч структуралары: Росгвардия, полиция, эчке эшләр органнары, ФСИН, янгынга каршы хезмәт һәм таможня хезмәткәрләренең дә окладлары арттырыла.

✓**Дәүләт хезмәткәрләренең эш хакы 5,5 процентка үсәчәк.** Әмма бу кайбер югары вазыйфаларны биләүчеләргә генә кагыла. Ә менә дәүләт органнарында эшләүче гади хезмәткәрләрнең – хисапчы, сак хезмәткәре, кассир, йөртүче, комендант һәм экспедиторларның барысының да кереме 5,5 процентка арта.

✓**1 октябрьдән 31 декабрьгә кадәр** дустанә булмаган илләргә бәрәңге, бодай, арыш, арпа, кукуруз, соя, рапс, көнбагыш һәм шикәр чөгендере орлыгын сату чикләнелә.

✓**Нотариусларга бердәм тариф буенча түли башлаячакбыз.** 1 октябрьдән гамәлгә керүче закон нигезендә, шәхси нотариуслар бертөрле генә түләтергә тиеш. Бу түләүгә федераль һәм төбәк тарифлары кертелә. Төбәк тарифын һәр ел саен Россия

төбәкләренең нотариаль палаталары махсус формула нигезендә билгеләячәк.

✓**Банк карталары хуҗаларын акча урлаудан саклаячаклар.** Банк картасын иминиятләштерү кагыйдәләре үзгәрә – хәзер картаның иминият полисы аны югалтудан яки зыян салудан гына түгел, бәлки мошенниклардан да саклаячак. Ләкин лимиты бар: 100 мең сум. Ягъни иминият оешмасы картадан югалган акчаны шул күләмдә генә каплый алачак дигән сүз.

✓**Мошенникларга юл ябыла.** Үзәк банк Эчке эшләр министрлыгына теге яки бу акча күчерүгә шик төшү турында хәбәр итәчәк. Мондый очракта банклар акча күчерүне ике көнгә туктатып торачак.

Сүзгә-сүз

Валентина МАТВИЕНКО, Федерация Советы спикеры:

Күп кенә төбәкләрдә дәреслекләр җитми. Чөнки алар яңа, бастырып чыгарырга өлгермәделәр. Дәүләт Думасының Мәгариф эшләре буенча комитетыннан бу кимчелекне күзәтү астына алуын сорыйм. Дәреслекләр бөтен җирдә җитәрлек булырга тиеш. Бу теманы ябарга кирәк.

(«Парламентская газета»дан)

РОССИЯДӘ – ЯЛ

Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү белгечләре Россиядә яшәүчеләрнең җәйге ялы ничек узуы хакында кызыксынган.

80% >> ял итәргә беркая да бармаган

35% >> җәен отпуск алмаган

13% >> Россия буенча сәяхәт иткән

3% >> чит илдә ял иткән

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

АМЕРИКАДА – ШАТДАУН, ПОЛЬШАДА – МАРШ

Америкада 1 октябрьдән яңа финанс елы башланды. Башлануын башланды, әмма хөкүмәт эштән туктау куркынычы алдында калды, чөнки конгрессменнар бюджет кабул итә алмады. 4 миллион дәүләт хезмәткәренә түләүсез отпускыга җибәрелү перспективасы яный башлады. Шатдаун, ягъни туктап калу АКШ өчен күрелмәгән хәл түгел. Соңгы унъеллыкта гына өч тапкыр: 2013, 2018, 2019 елларда шундый шатдауннар булды инде. Андый чакта вакытлы бюджет кабул ителә. Вашингтонда шатдаун башланырга санаулы минутлар гына калгач, 45 көнлек шундый бюджет гамәлгә керде, ул 17 ноябрьгә кадәр чыгымнарны алдагы финанс елы күләмендә калдыруны күз алдында тота. Республикачылар чыгымнарны киметүне таләп итә. Байден идарәсе, ягъни демократлар акчаны мул тоту ягында, чөнки шунсыз үсеш юлы була алмый дип саныйлар. Украинага ярдәм күрсәтүгә каршы килүчеләр бар. Вакытлы бюджет, чынлап та, андый ярдәмне исәпкә алмый гына төзелде. Ләкин бу Киевка корал килүдән туктый дигән сүз түгел. Украина конфликтын финанслау өчен махсус закон кабул ителә дигән сүзләр йөри. Илдә бюджет проблемалары исә тирәнәя. Американнар һәрвакытта да бурычлар проблемасын яңа бурыч алу юлы белән хәл итәләр. Яңа әҗәтләрне югарырак процентлар белән түләргә туры киләчәк.

Польшада исә 15 октябрьгә тәгаенләнгән парламент сайлавы алдыннан оппозиция тарафдарлары миллионлы марш оештырды. «Миллион йөрәк маршы» дип аталган акциянең башында элекке премьер Дональд Туск тора. Поляк матбугаты маршның тыныч үтүен хәбәр итте.

Оппозиция Ярослав Качиньскийның «Хокук һәм гаделлек» дип аталган идарәче партиясен закон бозуларда, илне Евросоюздан чыгарырга омтылуда, финанс махинацияләрендә гаепли. Партия гаепләүләрне кире кага. Сайлау алды рейтингы шуны күрсәтә: «Берләшкән уңнар» дигән идарәче коалицияне (аның үзәген «Хокук һәм гаделлек» партиясе тәшкил итә) халыкның 33,8 проценты яклый. Икенче урында «Гражданнар коалициясе» дигән партия. Аңа халыкның 28,1 проценты тавыш бирергә әзер. «Өченче юл» дигән партия – 9, чиктән тыш уңнар партиясе – «Конфедерация» – 8,8, «Яңа суллар» 8,7 процент тавышка өметләнәләр. Сайлауга мөнәсәбәтле рәвештә Варшава белән Киев арасында мөнәсәбәтләр берникадәр бозылды. Әмма ике илнең аркадашлыгы туктар дип өметләнергә ярамый, чөнки, бердән, Польшага Вашингтон басымы көчле, икенчедән, поляклар үзләре дә Россиягә каршы позициядә нык торалар. Словакиядә бу ялда сайлау үтте. Анда Украинага ярдәм күрсәтүгә каршы партия өстенлек алды.

Россиядә

САТЫП АЛМАСАҢ, БӘЯЛӘР ӘЙБӘТ

Россиядә инфляция белән девальвация куркынычы кимеми. Үткән атна башында без доллар курсының пәнҗешәмбе көннән үсә башлаячагын фаразлаган идек. Фараз тормышка ашты: доллар 98 сумга җитте. Дүшәмбе иртәсенең беренче хәбәрләре үк девальвациянең дәвамын күрсәтә. Бу юллар язылганда, евро – 104 сумны, доллар 98,5 сумны узып китте. Инфляция күрсәткечләре дә рәсми фаразларны вата-җимерә. Икътисадый үсеш министрлыгы апрель аенда еллык инфляцияне 5,3 процент булыр дип фаразласа, хәзер санны 7,5 процент дип төзәтте. Үткән атнада Путин, министрларны келәмгә бастырып, бензин бәясен контрольгә алуны таләп итте. Вице-премьер Новак нефтьчеләргә кичекмәстән ягулык бәясен төшерергә әмер бирде. Базар андый әмерләрне бик яратып бетерми бетерүен. Әмма административ басым вакытлыча нәтиҗә бирергә мөмкин. Үткән атнада «Роснефть» менеджерларының бер төркеме кәнәфиләрдән очып төште. Рәсми даирәләр бензин бәясе күтәрелүдә «соры экспорт»ны гаеплиләр, ягъни алыпсатарлар эчке базарда арзанга бензин ала да читкә сата, диләр. Моны булдырмас өчен, тоннага 50 мең сумга кадәр экспорт пошлинасы кертергә җыеналар. Чараларның нигә китерүен алдагы атналар күрсәтер. Хөкүмәт мотор ягулыгын йөгәнли алмаса, инфляция спирале бөтерелүен көчәйтәчәк. Карарларның нәтиҗәсезлеге хөкүмәткә ышанычны да киметәчәк.

Инфляция күрсәткече ике урынлы санга җитәчәк дип фаразлаган белгечләр бар. Үткән атнада Мәскәү финанс форумында финанс министры Силуанов: «Мин интернетта инфляция турында, миңа калса, дөрес фикер укыдым. Анда «сатып алмасаң, бәяләр нормаль» дип язылган иде… Сүз кулланучылар ихтыяҗын көчәйтмәскә кирәклеге турында бара…» – дигән сүзләр әйтте. Министр сүзләрен хаклы дип санар идек, әгәр дә рибага корылган икътисадта ихтыяҗның кимүе катастрофа тудырмаса. Аннан соң халыкның байтагы билләрен шактый ук кысып буды инде, әмма бәяләр маршы туктарга уйламый. Халык кулланыу товарлары җитештерүне арттыру һәм көндәшлек юлы белән бәяләрне төшерү ысулын министр әллә оныткан, әллә Россия җитештерүчеләренең моңа мөмкинлеге юк. Икенче вариант дөресрәктер, чөнки Собянин – Мәскәү мэры алдагы көннәрдә генә Көнчыгыш «дус»лардан зарланды. «Технологияләр бирмиләр, әзер продукт кына алыгыз, диләр. Әзер продуктны исә ике бәягә саталар», – дигән мәгънә ята зар артында. Шулай булгач, бәя төшүгә өметләнеп булмый инде.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

ҮЗӘКТӘ – КЕШЕ

tatarstan.ru

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Чаллыда Машина төзүчеләр көне уңаеннан уздырылган чараларда катнашты. Сүз уңаеннан, әлеге бәйрәм сентябрьнең соңгы якшәмбесендә билгеләп үтелә.

Чаллы

– Республикабыз – илдәге иң эре машина төзелеше үзәге, – диде Татарстан Рәисе, машина төзелеше өлкәсендә эшләүчеләрне һөнәри бәйрәмнәре белән котлап. – Бүген Татарстан төзелеш предприятиеләрендә эшләүчеләр, санкцияләрнең басымы көчле булуына карамастан, үз бурычларын лаеклы үтиләр. Россия Президенты Владимир Путинга һәм Россия Хөкүмәтенә даими ярдәмнәре өчен рәхмәтебезне җиткерәбез.

Рөстәм Миңнеханов Татарстанның Оборона сәнәгать комплексы махсус хәрби операциягә зур ярдәм күрсәтүен ассызыклады. Моннан тыш, махсус хәрби операциядә катнашучы хезмәткәрләренә һәм гаиләләренә ярдәм итүче предприятиеләргә аерым рәхмәт әйтте.

– Россия Президенты технологик бәйсезлек тәэмин итү бурычын куйды. Бу җәһәттән бездәге оешмаларның яңа проектларны гамәлгә ашыруы бик мөһим, – диде Татарстан Рәисе.

Бу сүзләрен ул мисаллар белән раслады. Әйтик, КАМАЗның камилләштерелгән К5 модельле йөк машиналарын чыгаруны җайга салуын, автобуслар һәм электробуслар җитештерүне арттыруын, Владимир Путинның Казан авиазаводында Ту-214 самолетларын чыгаруны киңәйтү турындагы карар кабул итүен билгеләп үтте. Казан вертолет заводында җитештерүне киңәйтү буенча проектның гамәлгә ашырылуын, машина төзелеше тармагындагы күп кенә компанияләрнең үсешен дә искәртте. Моннан тыш, Миңнеханов әлеге тармак үсешен тәэмин итүче кадрлар мәсьәләсен дә телгә алды. Аерым алганда, Татарстандагы күп кенә предприятиеләрнең һөнәри белем бирү оешмалары белән нәтиҗәле хезмәттәшлек итүен ассызыклады.

– Без заводларда эшләүчеләрнең казанышлары белән горурланабыз. Сугыш елларында 22 предприятиегә күрсәткән хезмәт батырлыгы өчен «Хезмәт батырлыгы предприятиесе» исеме бирелде. Әлбәттә, һәр предприятиенең төп байлыгы – аның коллективы. Үз хезмәтләре белән республика үсешенә зур өлеш керткән барлык тармак ветераннарына аерым рәхмәт! – диде Рөстәм Миңнеханов ахырда.

САН

Хәзерге вакытта Татарстанда машина төзелеше өлкәсенә караучы **4** меңләп оешма бар, аларда **124** мең кеше хезмәт куя. Бу елның 8 аенда Татарстанда **32** мең берәмлек йөк машинасы, **1,8** мең берәмлек авыл хуҗалыгы һәм юл-төзелеш техникасы, **750** мең суыткыч җитештерелгән.

Алабуга

Яшәү өчен дә, уку өчен дә, эшләү һәм хәтта спорт белән шөгыльләнү өчен дә мөмкинлекләр бар. Сүзебез «Алабуга Политех»ның яңа штаб-фатиры турында. «Алабуга» махсус икътисадый зонасы эшчеләре һәм «Алабуга Политех» белем бирү үзәге студентлары өчен каралган әлеге яңа объектны ачу тантанасында Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов, «ВТБ» банкы идарәсенең президент-рәисе Андрей Костин һәм Россия финанслар министры урынбасары Ирина Окладникова катнашты.

Әлеге комплекста барлыгы 706 фатир бар. Объект җәмгысы 2 мең кешене сыйдыра ала. Эш һәм ял итү урыннарыннан тыш, монда аудиторияләр, спорт залы, балалар өчен уен бүлмәләре, матурлык салоннары һәм башкалар бар.

Чара кысасында Рөстәм Миңнеханов, Андрей Костин һәм Ирина Окладникова «Алабуга» махсус икътисадый зонасына алдагы 25 елга перспектива планын имзаладылар.

Моннан тыш, кунаклар «Алабуга Политех» үзәген карады. Студентлар монда белем алу үзенчәлекләре белән таныштырды. Сүз уңаеннан, әлеге белем бирү үзәгендә укучыларны көннең беренче яртысында «Алабуга» МИЗ заводлары-резидентларының иң яхшы инженерлары укыта. Шул ук вакытта алар компаниянең профильле бүлекчәләрендә стажировка уза.

Очрашу азагында кунакларга икътисадый зонаны күрсәттеләр.

КӨЗ «БҮЛӘГЕ»

Борчыган мәсьәлә

Шәһәр халкы матур һәм җылы сентябрьгә хозурланып йөргәндә, аграрийлар бер тамчы яңгыр булмаудан зар елый. Алар өчен көннәрнең җылы торуыннан бигрәк, җирдә дым булмау куркыныч. Синоптиклар фаразларына ышансак, октябрь дә явым-төшемнәре белән куандырмас төсле. Мондый һава торышының авыл хуҗалыгына нинди йогынтысы бар?

Илдар Мөхәммәтҗанов

Татарстан Гидрометеорология белгечләре әлеге җылы көннәрне «әбиләр чуагы» дип атады. Күреп торуыбызча, быел ул аеруча озын һәм җылы килде. Октябрь башында да берничә көн суытып алачак та, кабаттан җылы көннәр башланачак, дип фаразлый КФУның метеорология, климатология һәм атмосфера экологиясе кафедрасы мөдире, профессор Юрий Переведенцев.

– Татарстанда мондый һава торышы соңгы тапкыр сигез ел элек булган иде, ә туфракта дым кытлыгы июльдән бирле күзәтелә. Бездә сентябрьдә 52 мм урынына нибары 9 мм явым-төшем явып узды. Норманың 20 проценты тирәсе генә бу. Бик аз. Сентябрь бик коры килде, – диде ул.

Аның сүзләренчә, 125 еллык метеокүзәтүләр тарихында 1976 елның 25 сентябрендә 2,6 градус салкын, ә 2015 елда 25 градус җылы булган.

– Бу – бик зур аерма! – ди белгеч. – Явым-төшемгә килгәндә, иң күп яңгыр – 32 мм – 1954 елда күзәтелгән булган. Гомумән алганда, быелгы күренешне глобаль җылынуның бер өлеше дип карарга була, чөнки безнең төбәктә температура елдан-ел күтәрелүгә таба бара.

Россия белгечләре дә октябрьнең җылы булачагын фаразлый.

– Октябрьдә дә температураның түбәнәюе күзәтелмәячәк. Ул нормадан 3 градуска җылырак булачак, яңгырлар аз явачак, – дигән «Фобос» һава торышы үзәгенең әйдәп баручы белгече Евгений Тишковец.

Шулай итеп, синоптиклар алга таба да аграрийларны сөендерерлек фаразлар җиткермәде. Әлеге вакытта Буа районында күп көч шикәр чөгендерен алуга куелган. Алар өчен һава торышының җылы торуы уңайга гынадыр, дип уйлап ялгышканбыз икән. Буа районының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы Ранис Габитов әйтүенчә, көннәр эссе торганлыктан, татлы тамыразыкны кырга чыгарып җиләтеп булмый: тиз кибә.

– Бүгенгә әлеге культураның 40 проценты алынган. 100 мең тоннадан артыгы шикәр заводына озатылган. Гектарыннан 380–400 центнер уңыш алабыз. Начар түгел, тик шул ук вакытта авырлыклар да бар. Җирдә дым булмагач, болай да сусыл түгел ул. Киптереп тә булмый, шунлыктан уңышны җыеп алу һәм казу авырлык белән бара. Әгәр яңгырлар булган булса, уңыш гектарыннан 500–550 центнерга кадәр җиткән булыр иде.

Быел җәй бик кызу булса да, Буа районы хуҗалыклары мул уңыш алуга иреште. Алар уртача алганда гектарыннан 30 центнер ашлык җыеп алды.

– Монда технологияләр дә коры һава торышына яраклаштырылды, туфракка ашлама күп кертелде, җирне тирәнрәк эшкәртә торган техникалар сатып алынды. Алар барысы да коры һава торышы шартларында да яхшы уңыш алырга мөмкинлек бирде, – диде Ранис Габитов.

Идарә башлыгы сүзләренчә, уҗым культуралары 15500 гектар мәйданда чәчелгән, тик, кызганыч, бүгенгә горурланып күрсәтә торган кырлар юк.

– Мин башка районнар белән дә элемтәдә торам. Аларның берсе дә уҗымнарның күкрәп үсеп китүенә гарантия бирми. Без үзара: «Октябрь башына кадәр яңгыр яумаса, нишләрбез икән?» – дип сөйләшә идек. Шулай килеп чыкты да. Ләкин шул ук вакытта беребез дә күпме көч түгеп чәчелгән кырын «Булмады инде бу!» дип сөреп чыгарга да ашыкмый. Барыбыз да, яңгыр явар да уҗымнар тишелеп чыгар, хәл алыр, дип өметләнә. Әгәр шушылай дәвам итсә, 2024 елда ул кырлардан мул уңыш алырбыз, дигән бернинди дә ышаныч юк. Миңа калса, уңыш бик начар яки бөтенләй булмас.

Мондый һава торышына Мамадыш районында да сөенмиләр. Чөнки быел уҗым культуралары узган елгыга караганда да күбрәк мәйданда (1600 гектарда) чәчелгән.

– Мондый һава торышының бер яхшы ягы да юк. Августта чәчелгән уҗымнар тишелә алмый тора бит. Бүген бераз явым-төшем булып алды, тагын шулай булгаласа, яхшы булыр иде дә. Без яхшыга өметләнәбез инде. Көннәр җылы тора бит, яңгыры булса, тишелеп, матур гына үсеп китәргә вакыт бар анысы. Безгә, иң мөһиме, көзге бодайның тишелеп, көч җыеп калуы кирәк, – диде авыл хуҗалыгы идарәсе башлыгы Ильяс Гаптрахимов. – Без быел яфрактан тукландыруга зур игътибар бирдек. Шуның аркасында мул ашлык җыеп алуга ирештек.

Арча районыннан бакчачы һәм синоптик Рәис Шәкүров, корылык игеннәр өчен генә түгел, агачлар өчен дә зыянлы, ди.

– Тамырлары өстә булган агачлар киләсе язда корырга мөмкин. Бездә алай ук коры булды, дип әйтеп булмый. Сентябрьдә берничә тапкыр матур яңгырлар явып узды. Әле менә бүген дә шифалы яңгырлар булды. Күзәтүләремчә, октябрь дә явым-төшемгә мул һәм җылы булачак, – диде ул.

Корылык авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәрен генә түгел, гап-гади авыл халкын да борчый.

– Малларны чыгарып торырга кирәк дип, абзар артында утар ясап йөргән көннәребез. Баганалар утыртырга бер метрлап чокыр казыдылар. Туфрак коп-коры, дымның әсәре дә юк. Җәй буе тилмереп яңгыр көттек, инде көзен дә карашыбыз күккә төбәлгән. Мондый корылык сагайтып кына калмый, куркыта да, – диде Кукмара районының Бакчасарай авылында яшәүче Чулпан Һадиева.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ УКАЗЫ

1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгын бәйрәм итү турында

1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгын билгеләп үтү йөзеннән **карар бирәм**:

1. 2025 елда Татарстан Республикасы муниципаль районнарында һәм шәһәр округларында 1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгына багышланган тантаналы чаралар уздырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

2023 елның 1 декабренә кадәр, Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгын Татарстан Республикасында бәйрәм итүне әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты тәкъдимнәрен исәпкә алып, Татарстан Республикасында 1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны уздыру буенча чаралар планын, аларны уздыру срокларын, җаваплы башкаручыларны күрсәтеп, эшләргә һәм расларга, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тикшереп торуны тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасында яшәүче 1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы ветераннарының социаль-икътисадый хәлен яхшырту буенча чаралар күрергә;

әлеге Указны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган башка карарлар кабул итәргә.

3. Республика башкарма хакимият органнарына:

тиешле бәйрәм чараларын, шул исәптән 1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышының хәлиткеч бәрелешләренә һәм башка мөһим вакыйгаларына багышланган чараларны әзерләүдә һәм уздыруда катнашырга;

Татарстан Республикасында яшәүче 1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы ветераннарына аларны социаль яклау мәсьәләләрен хәл итүдә һәрьяклап ярдәм күрсәтергә;

хәрбиләр каберлекләрен һәм мемориаль комплексларны тәртипкә китерүдә, шулай ук Ватанны саклаганда һәлак булган сугышчылар мәетләрен эзләүдә һәм җирләүдә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына ярдәм күрсәтергә.

4. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына тиешле муниципаль берәмлекләрдә 1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгын бәйрәм итүне әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитетлары төзүне һәм чаралар планын раслауны тәкъдим итәргә.

5. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына 1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгын бәйрәм итүгә багышланган чаралар уздыруны массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны оештырырга.

6. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 30 сентябрь
№ 690

ШИНЕЛЬЛЕ УКЫТУЧЫЛАР

Ватан хакына

Махсус хәрби операциядән укытучылар да читтә калмады. Каләм урынына куллларына корал алып, алар да ил сагына басты. Кемнәр алар безнең заман геройлары?

Аерылышулар авыр

Илшат Әгъзамов Актаныш районы Пучы мәктәбендә сигез ел ОБЖ һәм физкультура дәресләре укыткан. Иске Кормаш авылы егете башта йөреп укытса, соңрак фатир арендалаган. Өйләнмәгән. Аңа 34 яшь.

– Узган ел сентябрь аенда бер айга хәрби җыенга киткән иде ул. Икенче көнне үк өлешчә мобилизация игълан иттеләр. Авылга кайтып тормыйча, хәрби операциягә шуннан гына китте. Позывное – «Физрук». Беренче мәртәбә кайтканда: «Балалар белән аерылышу кыен булыр», – дип мәктәпкә килмәде. Икенчесендә үзебез ишетеп чакырдык. Мәктәпкә килгәч, күзләре яшьләнде. Балалар да сагынган иде. «Кайда яшисең, абый?», «Нәрсә ашыйсың?», «Ядрәләр шартлаганда, куркытмыймы?» Балалар төрле сораулар бирде. Егетләр туган илләрен сакларга, армиягә барырга тиеш, дип сөйләде Илшат, – диде мәктәп директоры Алсу Шәйхетдинова.

Илшат Әгъзамов белән элемтәгә чыгып, мәктәпне ни дәрәҗәдә сагынуын, егетләрдә патриотик хис тәрбияләү турында кызыксындык.

– Укучыларымны, бергә эшләгән хезмәттәшләремне, җыештыручыларны, пешекче апаларның барысын да искә алам, – ди Илшат Әгъзамов.

Укытучылар илне сакларга тиешме, әллә укытыргамы? Әнә шундый сорауны да бирдек. Анның әйтүенчә, ул хезмәт иткән полкта гына – 30лап укытучы. Россия буенча алганда, яудагы укытучылар аз түгелдер.

– Ир-егет булып дөньяга килгәнсең икән, без беренче чиратта Ватан каршында бурычны үтәргә – илне саклаpга тиеш дип уйлыйм. Хәрби операция барган вакытта балаларны тәрбияләргә, укытырга да кирәк бит. Аларны нык, акыллы һәм патриот итеп үстерү мөһим.

– Чипсы ашап, телефон тотып үскән буында ватанпәрвәрлек хисен тәрбияләп булырмы? – дип тә сораштык анннан.

– Һәр чор баласы үзенчә тәрбияләнгән. Хәзерге буын гына аерылып торадыр дип уйламыйм. Аларны бары аңлый белергә генә кирәк. Телефон, гаджет һәм башкалар сәбәп түгел. Технология алга барганда, бала аннан калыша алмый. Бу аңа сәләтен яңача үстерергә ярдәм итә. Әлбәттә, әти-әни, укытучы, дәүләт, социаль челтәрләр дөрес юл күрсәткәндә генә патриотик хис туа һәм ныгый, – диде Илшат Әгъзамов.

Сабырлык үрнәге

Махсус хәрби операциядә Бөгелмә районыннан 5 укытучы катнаша. Шулар арасында 33 яшьлек Алексей Алексеев та бар. Төп эш урыны – шәһәрдәге балалар һәм үсмерләрнең туризм станциясе. 3 нче мәктәптә исә биш ел дәвамында физкультура укыткан. Әнисе дә укытучы икән.

– Балалар үзен бик яратты. Дәресләрен бик кызыклы итеп оештыра иде. Спорт чаралары, ярышлар үткәрде. Хәрби операциягә бөтен мәктәбебез белән озаттык. Күз яшьләрен тыеп торырга туры килде. Әйткән сүзен игътибар белән тыңладык. Фронтка балалар хатлар язды, открыткалар, җылы оекбашлар җибәрде, – ди директор Галина Дулова.

Җомга икмәге

Чирмешән районы Лашман мәктәбенең технология укытучысы, 29 яшьлек Айнур Салахов медвзводта хезмәт итә. Казандагы Идел буе физкультура, спорт һәм туризм академиясен тәмамлаган егет фронттагы хезмәттәшләренә беренче ярдәм күрсәтә. Апрель аенда Россия Оборона министрлыгының «Хәрби фидакарьлек өчен» II дәрәҗә медале белән бүләкләнгән. Фронтка киткәндә сигез айлык сабые калган. Ике тапкыр ялга кайтып киткән. Гаиләсе, якыннары белән аралашып тора.

– Башта бик авыр булды, – ди әнисе, үзе дә 33 ел математика укыткан Ризида Салахова. – Бер яктан, улыбыз белән горурландык. Икенче яктан, йөрәк янды. Бала да, онык та кызганыч. Күңелдә ике төрле уй көрәште. Җибәрәсе дә килми, шул ук вакытта илне дә сакларга кирәк. Педагогларны гына аерып калып булмый. Улым качып йөри торганнардан түгел. Каралары бары бер генә иде: барырга кушкач, барырга! Ул Таҗикстанда ике ел контракт буенча хезмәт иткән иде. Хәрби бурычның нәрсә икәнлеген яхшы белә.

Анның әйтүенчә, Айнур бик төпле егет, артыгын сөйләргә яратмый. Фронттагы хәлләрне дә сер итеп саклый. Кечкенәдән дини тәрбия алган. Күңелендә – игелек хисе. Армиядән кайткач, кибет ачкан. Җомга саен авыл халкына бушлай ипи тараткан.

Мәктәптә бер генә ел укытырга өлгергән ул, технология дәресләрен алып барган. Агач эшен ярарканга күрә, өстәмә белем алган. Балаларны һөнәргә өйрәтер өчен өеннән 100 мең сумлык станок алып килгән. Әлеге мәктәптә коррекцион сыйныфлар да бар. Айнур барлык балаларны да балта, пычкы тотарга өйрәткән.

Мәктәп директоры урынбасары Илдар Мөбарәкшин укытучыны бары уңай яктан гына бәяләде. Укучылар Айнур абыйларын сагына. Ялга кайткач, үзен кочаклап каршы алганнар. Сөенечтән концерт куйганнар. Айнур аларга ватанпәрвәрлек турында сөйләгән.

– Без – Советлар Союзы чорында тәрбияләнгән буын. Шуңа күрә егетләрнең илне саклавын хуплыйм. Чын егетлек! Айнур, бармыйм, димәде, качып китмәде. Гамәле – ватанпәрвәрлек үрнәге, – диде Илдар Мөбарәкшин.

«Бу бит – безнең Сергей Юрьевич!»

Әгерҗе районының Сарсак-Омга лицее укытучысы 42 яшьлек Сергей Маркитонов та – хәрби операциядә. Ул мәктәптә ОБЖ һәм физкультура дәресләрен укыткан. Ун ел лицей директоры булган.

Лицейда 92 укучы белем ала. Директор Ләйсән Шәйдуллина әйтүенчә, өлешчә махсус хәрби операция башлангач, кадрлар калмас, дип борчылалар. Укытучыларның уртача яше – 40–50. Сергей урынына армиядән кайткан егетне эшкә алганнар.

Сергей – укытучылар нәселеннән. Әнисе Людмила 43 ел математика укытса, хатыны Татьяна – инглиз теле укытучысы. Өч кыз тәрбиялиләр.

– Сергей – тырыш, төпле укытучы. Спортчы булаpак, район һәм республика күләмендәге бәйгеләрдә катнашып, җиңүләр яулады. Волейбол яратучы кызлар һәм егетләр тәрбияләде. Патриотизм хисе көчле анда. Гаиләдә – өч малай. Ул – иң олысы. Энесен дә алмакчылар иде, үзем барам, дигән. «Безнең ир-егетләр фронтка киткәндә, мин ничек читтә калыйм? Укучыларымның күзенә ничек карармын?» – диде. Ике тапкыр ялга кайтып китте. Бирешмибез, җиңеп кайтабыз, ди. Без аңа ышанабыз. «Хәрби фидакарьлек өчен» II дәрәҗә медаль белән бүләкләнгән, – ди директор Ләйсән Шәйдуллина.

Беренче тапкыр ялга кайтуы үзе бер дулкынландыргыч мизгел булган. Укучылар аны тәрәзәдән күреп: «Бу бит – Сергей Юрьевич!» – дип сөенгәннәр. Мәктәп коллективы фронтка посылкалар җибәрсә, балалар хатлар яза. Элемтә югалмый, кыскасы.

Сәрия МИФТАХОВА

Илшат Әгъзамов

Алексей Алексеев

Айнур Салахов

Сергей Маркитонов

Без бел(мә)гән тарих

БИШБАЛТАНЫ НИ КӨТӘ?

Бишбалта – Казан шәһәрендә үз исемен, бай тарихын, борынгы зиратын саклап калган бердәнбер татар авылы. Кукмара якларында туып, хезмәт юлын атаклы «Урак һәм Чүкеч» заводында башлаган һәм гомеренең күп өлешен шушы төбәкнең серләрен өйрәнүгә багышлаган Гарәфетдин абый Хисаметдинов шундый фикердә. Шуңа күрә дә ул туристларны җәлеп итәрлек проектлар эшләп, хәзер инде авыл тарихы турындагы китапны да тәмамлап килә. Ул якларга килеп чыксак, яңадан-яңа тарихи урыннар белән таныштыра, яңа идеяләрен бәян итә.

Әзләр кала

– Бу төбәк Казан шәһәре генә түгел, ә бөтен Татарстан өчен патриотик тәрбия үзәге булып тора. Башка бер генә урында да бу кадәрле дөнья, Россия буйлап дан казанган батырлар, галимнәр тупланган төбәк юк, – ди ул. – Кайберләрен генә искә төшереп үтик: ике тапкыр Советлар Союзы Герое Николай Столяров шушы төбәктә туып-үскән, «Урак һәм Чүкеч» заводында эшләгән, өч тапкыр Социалистик Хезмәт Герое, академик, беренче атом бомбасын ясаучы Игорь Курчатовны да язмыш шушы заводка китергән, Советлар Союзы Герое, очучы Михаил Девятаев Бишбалтадагы Елга техникумын тәмамлаган, шул ук заводта токарь булып эшләгән. Тарихы да бик бай Бишбалтаның. Бакалда йокымында (пристань) Казан ханбикәсе Сөембикә улы Үтәмеш белән саубуллашкан. Казанны басып алырга килгән Явыз Иван беренче тапкыр шушы җиргә аяк баскан һәм казанлылар тарафыннан каршылык күргән. 1772 елда Петр I Бишбалтага килә, 50 яшьлек юбилеен билгеләп, анда ясалган 25 корабны алып, Иранны яуларга китә. Патшабикә Екатерина Икенче дә шушы йокымга килә. Монда Владимир Ульянов-Ленин, Максим Пешков (Горький), Габдулла Тукай, Сара Садыйкова, Федор Шаляпин, Хәсән Туфан кебек шәхесләрнең эзләре саклансн.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Җәмигъ мәчете

Быел ике елга – Идел белән Казансу кушылган урында, 10 мең кеше сыешлы Җәмигъ мәчете төзелә башлады. Дөрес, бу урынны ошатмаучылар да булды. Шул җәһәттән Татарстан мөфтие Камил Сәмигуллин аңлатма бирде һәм килеп туган киеренкелеккә нокта куйды. Мөфтинең чыгышын күп яклап тикшереп, тәнкыйтьләп тә, яклап та чыктылар. Шуларның икесен дә мин дә тукталам. Күп кеше шәһәр читендә салына дип уфтана. Минемчә, бу – киләчәккә карап эшләнә торган төзелеш. Башкалабызның иң гүзәл урыны ул. Алга таба Яшел Үзән, Биектау, Югары Ослан Казан шәһәренә кушылып, мегаполис булыр дип фаразлана. Димәк, Җәмигъ мәчете бу мегаполисның үзәгендә булачак. Шул ук вакытта әдәби, тарихи әсәрләргә кереп калган, су буйлап килүче «Ефәк юл» сәүдәгәрләренең иң итү, сату-алу үзәге булган Мәркиз утравын торгызып, аны яшьләрнең, сәфәрчеләрнең, килгән кунакларның күңел ачу үзәгенә әйләндерергә иде.

Булачак мәчеткә кагылышлы күңелне борчып торган сораулар тагын да бар инде ул. Беренчесе – мәчет салынасы комлыкның төбендә урнашуы. Бу җәһәттән язгы ташулар, су басулар зыян салмасмы икән дип, Казан дәүләт архитектура һәм төзелеш университетының кафедра мөдире Александр Дембич та үз фикерен җиткергән иде. Икенчесе – Җәмигъ мәчетен Мәккә шәһәрендә урнашкан, мөселманнарның йөзек кашы булган «Кәгъбә ташы»на охшатып, бер манаралы итеп салмакчылар. Мондый тәнкыйтьләргә җавап йөзеннән Камил хәзрәт: «Татар орнаментлары булыр, үзгәрешләр кертелер», – дип җавап бирде бирүен. Проекта үзгәрешләр кертү ни дәрәҗәдә рөхсәт ителә бит? Ә тарихка әйләнеп кайтсак, бу төбәктә өч мәчет булган. Зур урамда – бер манаралы, Юнысов исемендәге – ике манаралы һәм биш манаралы «Бишбармак» мәчете.

Сораулар күп

– Мине борчыган тагын бер сорау – ташландык хәлдә калган борынгы мөселман зираты. Аның хакында, нишләптер, Камил Сәмигуллин да искә алмады. Минемчә, мөселман зиратын тәртипкә китереп, төзекләндереп, янында кечкенә генә Ак мәчет салып, тарихи җәдкәрләрне саклау урынын булдырырга кирәк. Зират бик аяныч хәлдә. Аның янында зур йортлар калкып чыкты. Инде күптәннән: «Нигез казыганда кеше сөякләренә тап булабыз», – дип сөйләгәннәрен ишеткәнем бар. Җәмигъ мәчетенең Бишбалтада салынасын ишеткәч, күңелдә, зират та төзекләндерелер, дигән өмет пәйда булды.

Татарстанның элеккеге мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры Николай Никифоров заманында Казан – Иннополис маршрутында метро төзү тәкъдиме белән чыккан иде. Шул проектны хуплап, Казан, Бишбалта, Адмиралтейство, Җәмигъ мәчете, Уракчы (Илдар Хановның Төрле диннәр үзәге, Юдино чиркәве, Хуҗәхмәт Басу (Гольф клубы) һәм башка туктальшлар тәгаенләнсә, бик тә уңайлы килеп чыгар иде.

Бу төбәктә ике базар булган. Шәрык базары – Зур урамда, ә икенчесе – «Урак һәм Чүкеч» заводы артында, тимер юл буенда. Бүген тарихи трамвай депосы ташландык хәлдә. Шәрык базары өчен бик кулай урын.

Инде килеп, Клара Цеткин урамының да иске – Бишбалта дигән исемен кире кайтару дөрес булыр иде дип саныйм. Бишбалта үзәген зур төзелешләр, үзгәрешләр көтә. Бу күп көч һәм чыгымнар сорый. Максатка ирешү өчен төбәк префектурасы төзелсә, кулай булыр иде. Төбәкне белүче тарихчылар, мөселман архитектурасын белүчеләр, эшмәкәрләр, Татарстан Рәисе ярдәмчеләре бергә туплансак, эш тизрәк тә, нәтиҗәлерәк тә барыр иде дип өметләнәм.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Лифтлар турында сөйләшү

Бу юлы социаль лифтлар торышы һәм кадрлар сәясәте хакында сөйләшәсе килгән иде.

Кеше, бигрәк тә яшь кеше, тормышта үзен-үзе тапсын өчен, аның кайсы катлаудан, нинди гаиләдән чыгуына да карамастан, тиешле шартлар, мөмкинлекләр булырга тиеш. Үзен социаль дип атаган дәүләттә бигрәк тә. Башкача әйткәндә, адәм баласына Ходай биргән сәләт җиргә күмелергә тиеш түгел. Сәләтнең бәндәнең үзенә дә, җәмгыятькә дә хезмәттә булуы мәслихәт. Авылда терлекче гаиләсендә туганмы син, олы шәһәрдә урнашкан банк җитәкчесенең газиземе – карьера шартларының якынча тигез булуы мөһим. Дәүләтнең бурычы шуны гарантияләү, тигез мөмкинлекләрне кануннар, норматив актлар, җәмгыятьтә дәүләт үзе тудырырга тиешле әхлакый кагыйдәләр аша көйләп тору. Әгәр бу шарт үтәлә икән, беренче булып дәүләт үзе ота. Шул көнне үк түгел, еллар узгач. Аның халык хуҗалыгы, икътисады ота. Дөрес эшләүче, гадел социаль лифт ул – киләчәккә карау, иртәгәгене кайгырту гына түгел, ул килер елларга инвестиция дә әле.

Тик, ни гаҗәп, бездә кеше генә түгел, дәүләт тә бугенге көн белән яшәргә күнеккән шул. Шуңа күрә социаль лифтлар төзек эшли дип һич әйтеп булмый. Акчасы чутсыз булган банкир, үзенең кадерледән-кадерле улын яисә кызын, илнең генә түгел, дөньяның теләсә кайсы университетына урнаштыра, укыта ала. Тик аның белән генә бетсә икән. Егет укуын тәмамлаганчы ук кайтгыртучан эти аңа гадәттә инде эш белешкән, барысын да җайлаган була. Кичәге студентны еш кына җылы, йомшак, югары хезмәт хакы түләнә торган кәнәфи көтә. Сәләте, эшкә омтылышы, тырышлыгы бармы, юкмы – анысы әти-әнине кызыксындырмый.

Ә шул ук авыл баласы, гади эшче, хезмәткәр баласы укып та чыгарга мөмкин. Тик менә йомшак кәнәфи аны беркайда да көтми. Тормышта еш кына шулай килеп чыга: банкирның сигезле-тугызлы улы авылдан чыккан тырыш, тәрбияле, белемле белгеч урырасы урынны ала, йә шунда ук аның җитәкчесе булып куя. Менә шуннан да начары юк инде. Ярым надан һәм мин-минлекле затның ипле кешеләр белән идарә итүендә. Әхлак, иман дигәндә дә өлгермәгән зат, эш рәтен белгән гыйлемле, акыллыны яратмый гына түгел, булдыра алганчы басымчакларга, хәтта кы җәберләргә дә мөмкин әле...

Проблеманың башка ягы да юк түгел. Совет заманында «Кадрлар барысын да хәл итә» дигән шигарь бар иде. «Кадр» дип тиешле компетенцияле, белемле, максатчан халыкны атадылар. Бүгенге җитәкчеләрнең хәтсезе, хезмәткәр сайлаганда, үзенә тугры, лояль булуы өстенлек бирә. Һөнәрилеге, мораль сыйфатлары – аннан соң. Бу принцип югарырак менгән саен ныграк үтәлә, диләр. Әлбәттә, кузенә генә карап торган, ни әйтсәң дә, койрык болгаган хезмәткәр белән эшләү җиңел, җайлы, тик алгарышы, үсеш булачакмы соң? Сорау риторик...

Әлеге темага тотынырга чынлыкта мине милләттәшебез, дөньякүләм танылган галим, Россия Фәннәр академиясе академигы Роберт Нигъмәтуллинның Орел каласында узган халыкара икътисадый форумдагы чыгышы этәрде. Илнең бүгенге икътисадына шул тикле аек бәяне бирсә дә шундый олпат зат, фикер иясе генә бирә аладыр. Бераз чигенеш ясап, шуны да әйтәсем килә: төрле дәрәҗәдәге башлыкларга табынып, алар күзенә карап яшәгән кайберәүләрдән аермалы буларак, фәкыйрегез күңелемә элек-электән затлылык, намуслылык үрнәге булган нәкъ менә Нигъмәтуллин кебек кешеләр – галимнәр, фикер ияләре, иҗади шәхесләр якын. Кеше башына баса-баса карьера ясаган, коррупциягә баткан, үзеннән өстәге башлыкка гына ярарга тырышкан тар маңгайлы, сыек иманлы җитәкченең илгә, халыкка файдага карагандаа зыянны күбрәк китерүен аңлау өчен академик булу да кирәкми.

Академик үз чыгышында нәрсәләргә басым ясады соң? Илдә югары постларда тиешле компетенцияле, белеме булмаган кешеләр күп булуга. Шул ук сәнәгать һәм сәүдә министры Мантуров, мәсәлән, белеме буенча социолог икән. Беренчедән, сәнәгать белән сәүдә – бер-берсеннән ерак өйберләр, аларны берләштерүдә мантыйк аз. Икенчедән, яңа индустриальләштерү, технологик алгарыш кирәклеге көн кебек ачык вакытта Сәнәгать министрлыгына социолог ничек килгән? Ник тармакны җитештерүдә мастердан башлап, олы берләшмәнең гендиректорына кадәр күтәрелгән белгеч җитәкләми? Ни өчен сәнәгать, җитештерүгә бәйле вазыйфаларда менеджер дип аталган «универсал»лар, юристлар, икътисадчылар утыра? Төрле абруйлы кешеләр илнең, икътисадның бүген кадрланган (запущенный) хәлаттә булуын билгеләгәндә, уңыш, алдыны илләр сафына басу юлы нәкъ менә җитештерү аша ятканда, кадрлар белән булган шундый буталчыклык, өлкән туган әйтмешли, «непозволительная роскошь» түгелме?..

Дөньяда һәр дәүләтнең үз капитализмы, Россиядә генә капитализмның – үз дәүләте. Һәм нәрсәгә ирешетек? Чималь сатып, череп баеган олигархлар илдә күптән үз тәртипләрен урнаштырды. Аларга бирелгә электроника да, авиалайнерлар да, заманча станоклар җитештерү дә кирәкми. Ул тармаклар алга чыкса, алар икенче планга күчәчәк. Кадрлар сәясәте дә хәтсездән алар белән килештерелә, чөнки музыкага заказны акча янчыгы өстендә утыручы бирә. Көйләрен беләбез: алар илне иртәгә дә үз кубызларына биетмәкче, барысын да элеккечә калдырмакчы. Шул исәптән кадрлар сәясәтендәге кода-кодагыйлык белән эшләрэшләмәс социаль лифтларны да.

Фикер

Авылны кем яшәтер?

Язмамның герое Рәшит – Сарман якларыннан. Югары белемле, берничә ел элек исламга килгән, намаз укый. Дөньяга да мөселман фәлсәфәсеннән чыгып карый.

Авылда яшәүнең сәбәбе бик күпләр өчен уртак, бик гади – аерым йортта, иркенлектә яшәргә теләү, үземнеке дип тырышу, табигатьне ярату. Хуҗа булу инстинкты ул – табигый инстинкттыр, мөгаен. Дистә еллар күмәк хуҗалык идеяләре өстенлек итсә дә, «үземнеке» дип яшәгәндә генә кеше үзенең көчен, булдыклылыгын тулысы белән эшкә җигә бит. Тормыш шуны раслый.

Танышым – реалист. «Шәһәр тирәсендәрәк яки район үзәгендә яшәсәң, яхшырак, әлбәттә. Эш табарга җайлырак».

«Бөтен юллар Римга илтә» дигән шикелле, авылларда хәзер бөтен сөйләшүнең үзәге – эш. Аларда да – инвесторлар. Шактый кеше фермерлык белән мәшгуль, ди. Җәен төзелеш буенча «шабашка»га йөрүчеләр күп икән. Кыш көне алар инде пассив режимга күчәләр, ди. Чаллыга яки башка шәһәрләргә вахта белән йөрүчеләр дә байтак, ди.

«Авылларны ничек саклап калып була соң?» дигән соравымны аңа да бирәм.

– Авылларны саклап калырга кирәк инде ул, тик заманы авылга игътибар бирмәүгә көйләнгән заман шул хәзер. Олы корпорацияләр урбанизация сәясәтен алга куялар, зур шәһәрләргә ставка ясыйлар. Шулай да халыкның күпмедер өлешенә авыл тормышын барыбер алып барырга тырышырга туры киләчәк. Экологик чиста продукция белән үзен тәэмин итәр өчен булса да.

Агрохолдинглар алар барысы да глобаль чит ил корпорацияләре астында утыра, Монсанто рәвешендәрәк, мисал өчен. Алар ГМО кулланмыйча калмый.

Шулай да агрохолдинглар әлегә күпмедер дәрәҗәдә экологик чиста продукция житештерә, бигрәк тә хәләл продукция. Алга таба ничек булыр тагы.

Авылларны саклауга килгәндә, авыл дип янып йөргән кешеләр тырышлыгы белән сакланырга гына мөмкин ул. Бер төркем кеше эше бу. Дәүләт масштабында түгел, ә җирле, төбәк дәрәҗәсендә генә. Дәүләт масштабында башка сәясәт бара: анда авылларны яшәтергә дигән пункт юк.

– Авыл кешесе сәясәт белән кызыксынамы ул? – дим әңгәмәдәшемә.

– Сәясәт белән хәзер авылда гына түгел, барысы да кызыксына. Ләкин хәзерге мәгълүмати чүп-чар арасыннан дөресен табып, анализ ясау бик кыен. Бу – бар кешегә дә бирелмәгән, шуңа күрә нәрсә ишетсәләр, шуны кабатлап утыручылар күп. Ә мәгълүмати чүп күп һәм ул махсус ыргытыла. Кешеләр шуңа күрә кайда дөреслек, кайда ялган булуын аңлый алмыйлар. Бигрәк тә дини гыйлемең булмаса, вазгыятьне дөрес аңлау-аңлату мөмкин түгел, – дип саный ул.

Ислам дине тарихын белү бик күп аңлашылмаучанлыктан коткарачак, ди.

– Мисал өчен, Гайсә пәйгамбәрне мөселман кешеләр үз пәйгамбәрләре, мөселман буларак таный, зурлый, ә христиан динендәгеләр өчен ул – Иисус Христос. Уртак тарихны белсәләр, кешеләр арасында дини дошманлык азрак булыр иде. Коръәндә, пәйгамбәребезнең хәдисләрендә, сәхәбәләрнең риваятьләрендә бүгенге көнне аңлар өчен дә дөрес, ялгансыз мәгълүмат бар.

Авыл язмышы белән татар язмышы бәйләнгән дип саный танышым. Сәламәт халык ресурсы ул – авыл, ди. ЛГБТ кебек юнәлешләргә каршы торырлык сәламәт тәрбияне дин бирә ала. Дини гыйлем һәм тәрбия саклап калачак милләтне сау килеш, ди. Этнотуризм рәвешендәрәк программа-проектлар белән дә авыл тормышын җанландырып җибәрергә була, ди. Ләкин ил масштабында түгел. Анысына ышанычы юк. Милли энтузиастлар ихтыярына калдыра ул бу эшне. Какшаган ышанычны ныгытыр өчен, нәтиҗәле гамәлләр кирәк шул.

Лилия ФӘТТАХОВА

МАРИ ЭЛ РЕСПУБЛИКАСЫ БӘРӘҢГЕ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ ӘЛФИТ ИБРАЕВ:

«ТУГАН ЯКНЫ ТАШЛАП КИТӘ АЛМЫЙМ»

Милләттәш

«Йодрык кадәрле, йомры гәүдәле», – дип җырларда җырланган бәрәңгенең атамасы кайдан килеп чыккан? Без, бер төркем журналистлар, бу яшелчәнең тарихы, һичшиксез, Мари Элдагы Бәрәңге бистәсенә бәйле, дигән фикергә килдек. Тарих шул хакта сөйли. Бөтендөнья татар конгрессы бу районның берничә авылына бик матур, эчтәлекле сәяхәт оештырды. Район башлыгы Әлфит ИБРАЕВ безне милләттәшләребезнең тормыш-көнкүреше, бу җирлекнең тарихы белән таныштырды.

:: Әлфит Габделхакович, соңгы араларда сезнең төбәккә игътибар бермә-бер артып китте кебек. Аңлашыла инде, бу 2024 елда Йошкар-Олада үткәреләчәк Федераль Сабантуйга бәйле. Әзерлек эшләре ничек, башландымы әле?

– Күптән инде. Башкалага барган саен, андагы яңалыкларны күреп, сөенеп кайтам. Бу җәһәттән үзебездә дә эшләр күбәеп китте. Әзерлек эшләре буенча комиссиягә дә әгъза итеп сайладылар. «Татарча яхшы сөйләшәсең, татар тормышын да яхшы беләсең, синнән башка булмый», – дип, салпы якка салам кыстырып, күп чараларда төп рольгә кертеп җибәрү ягын карыйлар.

:: Бик мәшәкатьле булса да, гомер буена милләттәшләрем, туган җирем дип җан аткан кеше өчен әллә ни авырлыгы да юктыр, мөгаен. Сүз сөрешеннән шулай сизелә. Күңелегез дә бик күтәренке күренә.

– Шулай инде. Башлык вазыйфасында гына да 21 ел эшлим бит. Район биләмәсендәге һәр кешене, һәр карыш җирне беләм дигән сүз бит бу. Күз алдыннан күпме язмышлар үткән. Аңа кадәр туган авылым Яңавылда 20 ел эшләдем. Шуның җидесендә колхоз рәисе дилбегәсен тарттым. «Яңа тормыш» дип атала иде ул. Исеменә туры китереп, гел яңартасы, әйбәт тормыш төзисе килде. Аңлашыла ки, яңа вазыйфага да шул ук теләкләр белән килдем.

:: Теләкләр тормышка аштымы? Ниләр белән шөгыльләнеп ятасыз?

– Бәрәңге – авыл хуҗалыгы районы. Сәнәгать юк дәрәҗәсендә. Шуңа күрә төп игътибар шәхси хуҗалыкларга бирелә. Халык бездә бик тырыш. Ерак та китми. Үз ихатасында гына да әллә ниләр майтарып ятучылар бар. Яшелчә, җиләк-җимеш тә үстерәләр. Хайван да асрыйлар. Үзләре үк эшкәртәләр дә. Уйлап кына карагыз, Мари Эл Республикасында җитештерелгән итнең 25 проценты безнең районга туры килә. Бу – 70 мең тоннага якын дигән сүз. Кечкенә генә район өчен бу – бик зур сан. «Акашево» дигән фирма билгеләрен күргәнегез, ризыкларын ашап та караганыгыз бардыр. Бәрәңгедә бу фирманың филиалы эшли. Тавык тизәгеннән эшләнгән органик ашламаларның да даны еракларга таралган. Сатып алырга теләүчеләр бик күп.

:: Башка төбәкләрдән килгән милләттәшләребез, шул исәптән без дә күбрәк телне, гореф-гадәтләрне саклау турында кызыксынабыз. Татар авылларында бала-чага нинди телдә сөйләшә?

САН

Мари Эл Республикасында **675332** кеше яши. **90** милләт вәкиле бар. Татарлар – **43400** кеше. Шуларның **26898**е – шәһәрләрдә, **16502се** авылларда гомер итә. Бәрәңге районында **22** татар авылы булган, шуларның **11е** юкка чыккан. Бүген районда **7730** татар яши.

«Татар-информ»

– Сөйләшүләр саф татар телендә, нәкъ элеккечә. Монысы – әти-әниләрдән, әби-бабайлардан килгән байлык. Әмма, ни кызганыч, мәктәпләрдә эшләр хөртиләнә бара. Татар телен укыту теләк буенча, ягъни ата-аналар карамагында булгач, әллә ни мактанып булмый. Бүген туган тел һәм татар теле дәресләре атнага нибары ике дәрес укытыла. Мин моны бик аз дип саныйм. Тик бернигә карамастан, без телебезне дә, гореф-гадәтләребезне дә сакларга тырышабыз. Районда да, мәктәпләрдә дә чараларның күбесе татар телендә үткәрелә. Эшләп бетермәгән урыннар да бардыр инде. Үзегез дә: «Мәктәпләрдә элмә такталар, күргәзмә әсбаплар – барысы да рус телендә язылган», – дидегез бит. Димәк, төзәтергә туры килер.

Мәктәпләргә килгәндә, федераль программа буенча 13 мәктәпнең дүртесен ремонтлап чыга алдык. Минемчә, хөкүмәт безнең мәктәпләрдә патриотик тәрбиянең бөтенләй юкка чыгуын аңлады кебек. Хәзер ватанпәрвәрлек эшләренә зур игътибар бирелүенә бик сөенәм. Ниһаять, хезмәт мәсьәләсе дә алгы планга чыкты. Мин элеккеге кебек укучыларга чиләк тоттырып кырга чыгару, яңгыр астында бәрәңге чүпләтү ягында түгел үзе. Әмма башны бәрә-бәрә укып кына кеше булу да бик шикле. Бала эш белеп, өйрәнеп үсәргә тиеш. Укучыларыбыз белән бик горурланабыз. Хәтта татар теле һәм әдәбияты буенча Татарстан үткәргән бәйгеләрдә дә призлы урыннарны алып кайталар. Дөнья күләменә дә чыгалар.

Авылларда мәчетләр эшләп килә. Намазларга бөтен кеше йөри дип әйтә алмыйм. Әмма бәйрәмнәрдә урын булмый. Туксанынчы елларда Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев: «Һәр авылда мәчет төзелсен», – дигән иде. Безгә дә шул сүзләр тәэсир итте кебек.

:: Сез әңгәмәне дә: «Безнең күзләр Татарстанга төбәлгән», – дип башлаган идегез. Эш-гамәлләрегез дә шуңа бәйле булып чыкты. Янәшәдә генә булу тәэсир итәме?

Бәрәңге авылы документларда беренче тапкыр 1699 елда телгә алына. Казан губернасы төзелгәч, ул Казан өязе составына кертелгән була. XVIII гасыр ахыры – XIX гасыр башында Нократ губернасы Уржум өязенең волость үзәгенә әйләнә. 1931–1932 елларда биредә яшәүче татарлар үтенече буенча, Татар районы дип йөртелә башлый. Шуннан соң хәзерге исемен ала. 1962 елда Мари-Төрек районына кертелә. 1965 елда район яңадан тергезелә.

– Татарстан янәшәсендә булгач, анда нинди карар чыга, ул безгә дә кагыла сыман. Һәрхәлдә, без шулай тоябыз. Аның сәбәпләре күп инде. Беренчедән, без бит – татар районы, бер телдә сөйләшкәч, гореф-гадәтләр бер булгач, күңел барыбер шул якка тартыла. Икенчедән, мин күп вакытта Әтнә, Арча, Балтач кебек Татарстан районнарындагы башлыклар белән аралашып яшим.

:: Аерма сизеләме?

– Мин гел әйтә киләм: Татарстаннан читтәге төбәкләрдә татарлыкны саклау җиңел түгел. Сез бит үзегез дә сизмәстән каймак эчендә яшисез. Бөтен шартлар тудырылган диярлек. Ә безгә татар булып калу өчен бик күп көч куярга кирәк. Начар эшләсәк, булдыра алмасак, басып китәләр. Ә арбадан бер төшеп калсаң, кире менеп утырып булмый.

:: Шул сез тарткан арбага менеп утырып, ярдәм итәргә тырышучылар бармы?

– Яшьләр китә инде. Күбесе Казанга укырга юл тота. Аннан Бәрәңгегә юллары суына. Без аларны тотып кала алмыйбыз. Минемчә, авылларда җирне яраткан кеше генә кала. Үземне дә шулар рәтенә кертәм. Шушы көнгә кадәр туып-үскән авылым Яңавылда яшим. Бәрәңгедә өй салырга теләгән идем. Ул уемнан да кире кайттым. Туган җирне ташлап китә алмыйм.

:: Мондый милләтпәрвәр булгач, сез төбәккә кагылышлы тарихны да, риваять-легендаларны да яхшы беләсездер? Бәрәңге яшелчә буларак беренче барлыкка килгәнме, әллә сезнең бистәме?

– Тарихчылар сүзенә караганда, яшелчәгә торак пункт исеме кушылган. Безнең якларда бәрәңге 1842 елдан соң гына пәйда була. Мазарбашы авылы кешесе Фәйзулла Гафтиев Санкт-Петербургтан беренче тапкыр аның бүлбеләрен алып кайта. Үстерергә, пешерергә өйрәтә. Башта халык каршы килә. Агулы булыр дип тә куркалар. Бу яшелчәне ничек атарга белмичә, башта «Гафти шалканы» дип йөртәләр, ә сатып алырга килгән Әтнә, Арча халкы «Бәрәңге шалканы» ди. Тора-бара «шалкан» сүзе төшеп кала, «бәрәңге» атамасы гына тагылып кала.

Ә торак пункт буларак Бәрәңге атамасының килеп чыгышы турында исә берничә версия бар. Шуларның берсе дөреслеккә бигрәк тә якын килә кебек. Тел галимнәре Бәрәңге авылы үзенең атамасын Илләт елгасына коя торган Параньга (марича Поранча, татарча Бәрәңге) инеше исеменнән алган, дигән фикердә тора. Удмурт телендә марилыларны «пор» дип атыйлар, ә -ан – мари һәм коми телләрендә сакланып калган сүз ясагыч кушымча. Фарсы телендә дә «Беренге» дигән сүз бар. Ул «Изгеләр авылы» дигәнне аңлата. Кыскасы, Бәрәңгенең килеп чыгышы турында бүгенгә кадәр рәсми версия кабул ителмәгән. Ул бары тик риваятьләрдә генә яши. Тарих төпкелендә өйрәнелмәгән нәрсәләр күп әле. Фатыйх Сибагатуллин үзе Арча районында туып-үскәнгәме, якташлар дип, бик үз итеп килеп йөри иде. «Казан ханлыгы җимерелгәннән соң, ханнар шушы җирлеккә килеп урнашканнар. Сез ханнар нәселеннән булырга тиеш. Мин моны исбат итәм әле», – ди иде. Өлгерә алмады. Кем белә, бу сүзләрнең дөреслеккә дә чыгып куюы бар. Димәк, бигрәк тә тырышып эшләргә кирәк, сер бирергә ярамый.

Әңгәмәдәш – Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

ЯЛЧЫГОЛ ЭЗЛӘРЕ БУЙЛАП

Татар дөньясын аң-белемле, мәгърифәтле итәргә тырышкан дин галиме, мәгърифәтче, язучы Таҗетдин Ялчыгол Зәй төбәге өчен аеруча якын, кадерле. Анда инде 10 ел рәттән аның исемендәге республика фәнни-гамәли конференциясен уздыралар. Х Таҗетдин Ялчыгол укулары аның мирасына кагылышлы фикер алышу урыны гына булып калмады, тел, милләт, милли мәгариф мәсьәләләрен дә колачлады.

«Татар-информ»

Зәйлеләр Таҗетдин Ялчыгол рухын бүген дә кадерләп саклый. Ялчыгол укулары күркәм гадәт буенча дин әһелләрен, галимнәрне, нәсел дәвамчыларын бергә җыйды. Дога белән башланган эш хәерле була, шуңа иң беренче эш итеп, галимнең рухына дога кылырга Имәнлебаш авылы зиратына юнәлдек. Кушъелга авылында нәсел дәвамчылары каберен зиярәт кылдык, төзекләндерелгән «Хәзрәт чишмәсе»ндә булдык.

Конференция Коръән аятьләрен уку белән ачылып китте. Беренче итеп сәламләү сүзләрен Зәй районы башлыгы Разиф Кәримов җиткерде.

– Уртак тырышлык нәтиҗәсендә Ялчыголны елдан-ел яңа яктан ачабыз. Конференциянең географиясе киңәя, эчтәлеге яңа мәгълүматлар белән байый бара. Халыкны мәгърифәтле, әхлаклы итү өчен күп көч куйган олуг шәхеснең моннан 3 гасырга якын элек Зәй җирендә яшәве, аның халкына хезмәт итүе белән горурланабыз. Бүген аның нәсел дәвамчылары арасында династияләре белән сәламәтлек сагында торучы табиблар, укытучылар, башка һөнәр ияләре бар. Алар ерак бабаларының эшен лаеклы дәвам иттерәләр, – диде район башлыгы.

Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары Илфар хәзрәт Хәсәнов күренекле галим эшчәнлегенең күпкырлы булуы, аның иң саллы әсәре – «Рисаләи Газизә» турында сүз тотты.

– Мәшһүр мәгърифәтче, дин галиме Таҗетдин Ялчыгол чын мәгънәсендә энциклопедик шәхес булган. Имам да, табиб та, тарихчы да, вәгазьче дә, кул эшләре остасы да. Галим хезмәтләренең иң саллысы – һичшиксез, «Рисаләи Газизә» әсәре. Бу әсәр үрнәгендә аның иң беренче чиратта дин юлында хезмәт иткәнен, халыкка әхлакый тәрбия бирүче һәм үзе дә күркәм әхлак иясе булган шәхес икәнен билгеләп үтәр идем. Ул шушы әсәре аша кешеләрне иманлы, укымышлы, матур холыклы булырга өйрәткән. Мәңге искерми торган китап язып калдырган, – диде хәзрәт.

«Рисаләи Газизә» китабын 2 томда «Иман» нәшриятында бастырып, халыкка кайтарган, конференцияне бер елда да калдырмаган галим Хатыйп Миңнегулов – әлеге укуларда кадерле кунак.

– Тарихыбызда шушындый затларның булуы – зур куаныч. Татарның яшәргәме, яшәмәскәме дигән кыен вакытларында да милләт турында, халык турында кайгыртучылары булган. Таҗетдин Ялчыгол Зәйнеке генә түгел. Ләкин гомеренең төп мәгънәле өлешен шушында уздырган. Ул язганнар хәзерге көнгә дә аваздаш. Кеше, дөньясын онытып, дингә генә табынырга түгел, хәрәкәттә булырга, гамәл кылырга тиеш. Бу фикерләр аның әсәрләрен сугарган, – диде ул үз чыгышында. – «Рисаләи Газизә»гә карап, татар телен өйрәтергә була. Кызганыч, телебез аяныч хәлдә. Моның төп сәбәпләренең берсе – милли мәгарифебез булмау. Аны торгызмыйбыз икән, киләчәгебез юк. Тел бар икән – милләт яши.

Хатыйп Миңнегулов дин әһелләрен дә тәнкыйть утына тотып алды.

– Элек хәзрәтләребез тарихчы да, бер үк вакытта телче, әдәбиятчы, фәлсәфәче дә булган. Язганнарында шушылар укмашкан һәм шуңа күрә аларның вәгазьләрен тыңлаганнар. Алар халкыбызга зур йогынты ясаган. Безнең дин әһелләре сай йөзә. Әдәбиятыбызны, мирасыбызны белү җитми. Хәзер саф динне генә түгел, халкыбызның үзен, аның телен, милли асылын яшәтү кирәк. Бу юнәлештә безнең әле шактый эшлисе бар, – диде галим.

Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Рифат Җамал мондый чараларны һәр районда үткәрергә тәкъдим итте.

– Таҗетдин Ялчыгол Зәйне танытты. Тукай булмаса, Кырлайны да белүчеләр аз булыр иде. Ә бит һәр районның күренекле шәхесләре бар. Ник шуларга багышлап, чаралар үткәрмәскә? Зал тулы, әмма монда балалар да булырга тиеш. Ялчыголны һәм башкаларны искә алып, аны киләчәк буыннарга җиткерергә тиешбез. Милләт үзенең хөрмәтле кешеләрен белмәсә, ул үзен хөрмәт итә алмый, – дип сөйләде язучы.

Бүген Ялчыгол нәселе дәвамчылары 300гә якын икән. Күренекле шәхеснең бишенче буын оныгы Разилә Җиһаншина-Таҗетдинова ерак бабасының мирасын өйрәнүен, аның иҗаты буенча фәнни эш эзләнүләре алып баруын әйтте.

Зәйгә барып, Таҗетдин Ялчыгол эзләреннән йөреп, аны искә алып, тарихка сәяхәт кылдык, рухи яктан баеп кайттык. Зәйдә Ялчыгол рухы яшәгән кебек, туган җирләрендә башка шәхесләрнеке дә яшәсен иде ул.

Ләйсән САФИНА

ЧИТ ИЛДӘН КЫЗЫН АЛЫП КАЙТА АЛМАУЧЫ МАРИНА САПУРИНА:

«БУЛЫШЫГЫЗ МИҢА, КЕШЕЛӘР!»

Мамадыш районының Владимир авылында гомер итүче Сапуриннар гаиләсенә зур хәсрәт килгән. Марина ханымның чит илгә киткән кызы 26 яшьлек Венера хастаханәдә аңсыз ята. Аны дәвалау, кайтару өчен дә күп суммада акча кирәк.

Марина Сапурина, баласын дәвалаганнары өчен, Казандагы фатирын сатып, 4 миллион сум акча түләгән инде. Тик кайтып китә алмагач, бурыч тагын җыелган. Кайтып китәр иделәр дә – Венераны алып кайту бик чыгымлы. Анысына да акча кирәк. Җитмәсә, хәле тагын да начарланган.

– Кызымны хәлсезләнеп егылып, башы белән каты бәрелгән, диләр. Ул өч ел элек Кореяга киткән иде. Бер дә җибәрәсем килмәде шулчакта. Кызым Казанда укыганда үз көнен үзе күрде. Дус кызының студентлар программасы белән чит илгә барып эшләп кайтканын күргәч, бик кызыккан иде. Ул чакта туктатып кала алдым, – ди Марина ханым. – Бу турыда оныткандыр, дисәм, әкренләп акча җыйган да Мәскәү аэропортыннан: «Әни, мин Кореяга киттем», – дип хәбәр җибәрде. Нишләтә ала идем инде? Ул чит илгә тиз ияләште. Телләр өйрәнде. Инглизчә, корейча яхшы сөйләшә иде. Тынычланып киттем. Тик менә мондый хәл булыр дип уйламадым да.

Марина ханымга күптән түгел 50 яшь тулган. Венера аны шушы вакытка үз янына чакырган да инде. «Әни, юбилееңны бергә үткәрәбез. Син монда кил дә, мин синең белән кайтам», – дигән. Марина ханым чит ил паспортын озак ясата. Тиз генә җыенып чыгып китә алмый. Кызы белән телефон аша сөйләшеп торалар. Соңгы аралашу 7 июньдә була.

– Мин эштә идем. Кызым белән сөйләштем. Кәефе юк иде. Күзләре сагышлы, авырып та торам, диде. 8е көнне Америкадагы иптәш кызы шалтыратып, Венераның авыр хәлдә хастаханәдә булуын җиткерде. Аңлатуларынча, кызым аңын югалтып егылган. Дуслары хастаханәгә илткәндә, йөрәге дә туктаган була. Мине чакырганда ук, соңгы көннәрендә кызыгызны күреп калыгыз, диделәр. Документларны ясатып, 22 июньдә генә чыгып китә алдым, – ди Марина ханым.

Ул бу хакта тыныч кына сөйли алмый. Үксеп-үксеп елый. Ике баласын берүзе аякка бастырган хатын ул. Ире белән 10 ел яшәгәннән соң аерылышканнар. Улы өйләнеп, хатыны белән өч бала үстерәләр. Әле менә Марина ханым чит илгә киткәч, өченче оныгы туган. Әле ярый Марина ханымны эш урынында аңлаганнар. Сәбәбең бар, эшеңнән җибәрмибез, кайтуыңны көтәбез, диләр икән.

– Ничек кайтырмын? Шушы сорау белән яшим. Мин моннан баламнан башка беркая да китмим. Аны алып кайтырга кирәк. Кызымны беренче күргәндә, үзем аңымны җуям дип торам. 1 ай комада булды. Аппарат аша гына сулады. Миннән рөхсәт алып, муенын тишеп, сулар өчен трубка куйдылар. Хәле уңайланып та киткән иде. Күзләрен ачып карый башлады. Табиблар, сез килгәнне белде, ахры, тынычланды, диделәр. Самолетка утыртып алып кайтырлык итәргә кирәк дип йөри башладым. Янәсе, ничек итсәм итәм, баламны алып кайтам. Үзбәкстанга билетлар да алдым. Тик авиалиниядә безне алып кайтудан баш тарттылар, – ди ул. – Инде кайтырбызмы дигән идем, Венераның сидек юлында инфекция табылды. Хәзер шуны дәваламыйча кайтып булмаячак. Юлда югалтасыз, диләр. Мин инде бөтен җаваплылыкны үз өстемә дә алырга риза. Кайтырга гына мөмкинлек юк. Әле бит һәр дәвалаган көннәре өчен акча кирәк. Монда аны меңнәр белән түгел, миллион белән исәплиләр.

Марина ханым, кызын утыртып булса, башта 24 сәгать паром белән Владивостокка бармакчы булган. Аннары кайтыр идек әле, ди. Самолетта ятып торган авыруны алып кайту бик кыйммәтле икән. Әни йөрәге барысына да әзер. Әгәр берәр акча биреп торучы булса, ничек тә түләр идем, ди ул.

– Казан табиблары кызымны дәваларга риза. Сөйләштем инде. Ничек кенә кайтырга соң? Хәлләремне белсәгез иде. Төннәр буе йоклый алмыйм. Кан басымым гел күтәрелеп тора. Кызым янына ярты сәгатькә генә кертәләр. Венера быел визасын һәм иминиятләштерүне озайтмаган булган. Кайтып китәм, дигәндер инде. Үземә дә бер ай вакыт бирделәр. Елыйелый яшем кибә инде. 50 яшемә җитеп, чит җирдә шушындый хәсрәткә юлыгырмын дип уйламаган идем, – ди ул. – Ярдәм сорап, кая гына язмадык. Кемгә генә мөрәҗәгать итмәдек. 4 аемны монда уздырам. Ичмаса, кызым да уңайланып китми, дим. Мине янына озаккаракка кертсәләр дә, хәле яхшырыр иде. Тәннәре тишелгән инде. Утыртып алып кайтырлык булмады. Бер аягы да бөкләнми. Янына керүгә, тизрәк аркасын юам, яраларына дарулар сөртәм. Әле элек күзләрен ача иде. Хәзер анысы да юк.

Татарстаныма кайтсам, ничек тә яшәр идем әле, ди Марина ханым. Әнә шуңа да мәрхәмәтле кешеләрдән ярдәм сорый. Бәлки, бу язманы укып, кайту проблемасын хәл итәрдәй кешеләр табылыр. Дәвалау өчен дә түләргә кирәк. **Булышырга теләүчеләр Марина Сапурина исемендәге ВТБ, Саклык банкы һәм Ак Барс банкы карталарына акча күчерә ала. Карталар 8-996-952-90-51 номерына беркетелгән.**

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Кышны ничек чыгарсыз?

Уйлы күңел уйлана

Каршыбызда күршеләрнең биек, киң ябалдашлы булып үскән миләш агачы бар. Елның-елында миләшләре мул була, салкын кышларга кадәр күзне кызыктырып, ут янып утыра иделәр. Быел җимешләре әллә ни күп булмады. Карасам, инде бөртеге дә калмаган – кошлар ашап бетергән.

– Бер тәлгәшен дә авыз итә алмый калдык, ни арада килгәннәр, ни арада ашап бетергәннәр – үзебез дә шаккаттык. Миләше дә алай аз түгел иде бит, – ди Балтачта яшәүче танышым. – Безнекен генә дә түгел. Урамыбызда бөтен кешенең диярлек капка төпләрендә миләшләр үсә, аларда да бер бөртек миләш калмаган… Башка елларда әле без җыйганнан соң калганына, кыш урталарында көтүе белән миләш чыпчыклары килеп, ашап китә иде, кайбер елны ашап та бетермиләр, язга таба кар өстенә коела иде. Быел бөтенләй аптырарлык булды…

Бездә башка елны әле бу вакытта миләш чыпчыклары авылга килми дә иде, диештек. Ачтыр инде ул, мескеннәр дип, бер җәлләсәк, бу исәптән кыш көне нишләрләр, кышны ничек чыгарлар дип, тагын бер җәлләдек. Коры килгән яз-җәйләрнең төп авырлыгы кыргый дөньяга төшә шул.

Ярый ла без йорт хайваннарына, кош-кортка дигәнен кышка җитәрлек итеп туплап куйдык. Кырдагылар турында бит кайгыртучы юк. Урманнарга да әллә ни өмет юк: чытырманлык басып бетергән урыннарда муллыкка өметләнеп тә булмыйдыр. Гомер күренмәгән аюлар юлларга чыга (безнең урманнарда аюлар, селәүсеннәр һәм тагын башкасы бардыр дип ышана торган да түгел – бу исәптән ялан кырларга чыгарга курка торган), кыек җәнлекләр авылларга елыша… Барысы да «котырган», «саташкан» түгел бит, ачлыктан котылу эзләп, ризык эзләп, кешеләргә якынаюларыдыр. Җәлләсәк тә, сала кешеләре аларга мәрхәмәт тә күрсәтә алмый. Кыргый кыргый булып кала, алардан әле мал-туарга гына түгел, кешеләрнең үзләренә дә куркыныч яный шул.

Кышын авылларда да кошларга элекке кебек муллык юк (дөрес, җимлекләр ясап куючылар күп. Балалар гына түгел, бу кадәресен өлкәннәр дә кайгырта). Хәзер бит авылларда да кош-корт элекке кебек иркендә түгел. Лапас-абзар ишекләре дә күп вакыт ябык тора (ачык булса да, аларда кошлар кереп ашарлык ризык юк – йорт кошлары үзләре аерым «куыш»ларда «яши»…

Шулай булгач, бөтен өмет урманчылардадыр инде. Алар элеккечә үк, һәр елны көздән чарасына керешәләр, кыргый җәнлекләр, җанварлар җыйнала торган урыннарга, табигать шартларына карамастан, даими ризык өләшеп чыгалар. Яңгырлы көзләрдә дә, карлы-буранлы кышларда да йөри алырлык техникалары булу өстенә, мәрхәмәтле ярдәмчеләр дә табылып тора икән үзләренә. «Мин үземне аучы дип саныйм, әмма үз гомеремдә бер тапкыр да җәнлек, кош атканым юк. Аучы бит ул атучы гына түгел, ул – аларга ярдәм итүче дә. Мин дә – көздән язга кадәр урмандагы җанварларга ризык, ашау өләшеп йөрүче аучыларның берсе. Андыйлар аз түгел», – дигән иде бер сөйләшүдә Балтач районының Карадуган авылында яшәүче, алтын куллы механизатор Альберт Шәрипов.

Арабызда андыйларның булуы бик тә сөенечле. Быелгы кебек елда кыргый дөнья аларга аеруча мохтаҗ булачактыр…

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

goodfon.ru

ГАСЫР КИЧКӘН МӘКТӘБЕМ

Очрашу

Мәктәпне тәмамлаганга дистә еллар узса да, аның җылысы, якты истәлекләр һәрвакыт күңел түрендә саклана. Нинди генә һөнәр ияләре булсак та, нинди генә дәрәҗәле урыннарда эшләсәк тә, балачак, яшүсмер еллар онытырлык түгел. Азнакай районы Урманай урта мәктәбенең 100 еллык бәйрәмен билгеләп узарга җыелгач та һәркем әнә шулай күңел түрендәге матур хатирәләрен барлагандыр.

Автор фотосы

Җанга дәва

Бу көнне мәктәп ветеран укытучыларны, белем йортын төрле елларда тәмамлаган укучыларны, район һәм мәгариф идарәсе җитәкчеләрен җыйды. 100 ел эчендә мәктәпне 15 директор җитәкли. Кадерле кунаклар арасында 1968–1977 елларда мәктәп директоры булган, хәзерге бинаны төзеткән Зөфәр Харисовның да булуы бәйрәмгә нур өстәде.

Тантаналы чараны ике өлештән оештырганнар иде. Беренчесендә «Остазлар аланы», «Классташлар тыкрыгы» һәм «Әдәбият мәйданы» дигән проектлар тәкъдим ителде. «Остазлар аланы»на ветеран укытучылар һәм мәктәбебезне тәмамлап, укытучы һөнәрен сайлаган авылдашлар җыелды. Алар арасында Равилә Абдуллина да бар иде.

– 48 ел элек мин шушы мәктәптә математика һәм физика укыта башлаган идем. Бүген безне бусагадан ук укучыларыбыз, оныкларыбыз каршы алды. Мин һәрвакыт мәктәп коллективыннан зур игътибар тоеп яшим. Укытучы хезмәте – иң гадел хезмәт, аның өчен иң кадерлесе – эшеңне бәяли белүче укучылар, – диде ул.

20 ел дәвамында кулга-кул тотынып эшләгән мәктәп коллективын котларга Азнакай районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Дамир Гыйләҗев тә килгән иде.

– Бер гасыр дәвамында шушы җирлектә никадәр кешегә белем бирелгән, аларны тәрбияләүдә күпме шәхесләр, мөгаллимнәр, директорлар тырышкан. Бу мәктәптә укымасам, эшләмәсәм дә, язмышым аңа бәйләнгән. 20 ел дәвамында районның мәгариф идарәсен җитәкләүче кеше буларак, мәктәпкә азмы-күпме хезмәтем тигәндер, дип уйлыйм. Бүген бирегә керү шулкадәр рәхәт. Мин эшләгән чорда мәктәпкә беренче компьютерлар кайтарылды, котельныйлар төзелде, бина газлаштырылды. Ул вакытта зур вакыйга иде ул. Кайчандыр мәктәп ябылуга дучар ителгән иде. Бу хәлне булдырмый калу өчен безгә шактый ишекләр кагарга туры килде. Бәхеткә, үз сүзебезне әйтеп һәм дәлилләп, аны урта мәктәп статусында калдыра алдык, чөнки мәктәпнең белем бирү сыйфаты югары дәрәҗәдә иде. Бүген дә ул үз дәрәҗәсен тотып яши һәм эшли.

Мәктәпне төрле елларда тәмамлаучылар өчен иң кадерле мәйданчык – «Классташлар тыкрыгы» булгандыр, күрәсең. Чөнки биредә сыйныфташлар очрашып, аралашып утырсын өчен барлык шартлар да тудырылган, коллектив матур гына чәй табынын да хәстәрләгән иде. Биредә укучыларның фотолары, музей экспонатлары урнаштырылган. Шулай, кеше тормышында очрашу һәм аерылышулар һәрвакыт аралашып тора. Аерылышу күпме сагышлырак булса, очрашу шулкадәр күңеллерәк. Бу көнне күпләр, минем шикелле үк, мәктәпне сагынып, матур очрашулар өмет итеп кайткандыр, дип уйлыйм. Шәхсән үзем әлеге җылылыкны укытучыларым, сыйныф җитәкчем Фәнүзә апа, сыйныфташларым, бер чорда укыган башка укучылар белән очрашудан алдым. Мәктәбемнең матур үзгәрешләрен күреп ихластан сөендем.

– Әлеге бәйрәмгә ялымны махсус туры китереп кайттым, – диде бүген Ватан сагында булган сыйныфташым Ленар Абдуллин да. – Миңа хәрби операциядә менә шушы җылылык җитми. Бүген җаныма рәхәтлек алып китәм. Дөрес, кабаттан яу кырына китү тагын да авыррак буласын да чамалыйм…

«Әдәбият мәйданы»нда исә Урманай авылында туып-үскән күренекле язучы Гариф Галиевның 120 еллыгын билгеләп үттеләр.

Тантананы шушы дәрәҗәдә уздыру өчен зур тырышлык куйган мәктәп коллективына сокланмый мөмкин түгел. Аларга рәхмәт сүзләрен район башлыгы Марсель Шәйдуллин да әйтте. Ул үз чыгышында мәктәпләрнең яшәргә тиешлеген ассызыклады, ә укучыларны туган җиребезнең чын патриотлары итеп тәрбияләргә, туган телебезне сакларга чакырды. Билгеле инде, бәйрәмгә саллы күчтәнәчен – 2 млн сумлык сертификатын да алып килгән иде ул.

Матур нәтиҗәләр

Азнакай авыллары арасында Урманай мәктәбе – йөзьеллыгын билгеләп узган бердәнбер белем учагы.

– Бәлки алар бардыр да, ләкин тарихы төгәл билгеле булмагач, дәлилләү авыррак, – ди 16 ел шушы мәктәпне җитәкләгән директор Гөлшат Хәйбуллина. – Кызганыч, тарихлары билгеле булып та, бүген ишекләренә йозак эленгән мәктәпләр бар. Ә без мәктәбебезне оптимильләштерү шаукымыннан саклап кала алдык. Соңрак балалар бакчасы кушылды, ә инде узган елдан безгә күрше Беренче Май һәм Таллы Бүләк авылларының балалар бакчалары өстәлде. Агрокласслар булдыру да – мәктәбебез өчен матур күрсәткеч. Аның максаты – укучыларны авыл хуҗалыгы белән кызыксындыру, балаларны шушы тармакка җәлеп итү. Инде укучыларыбыз беренче уңышлары белән сөендерә дә башлады. 8 нче сыйныф укучысы Роберт Карамов АгроНТРИ конкурсында катнашып, «АгроСмарт» номинациясендә җиңеп чыгып, республика данын Россия күләмендә танытты. Безнең өчен бүгенге шартларда җир кешесен тәрбияләү мөһим. Авылга да югары белемле белгечләр кирәк. Укучыларыбыз замана белән бергә атлап, алган белемнәрен авыл хуҗалыгында кулланырлар дип өметләнәбез.

Мәктәптә киләчәк өчен генә тырышып калмыйча, үткәнне, туган якны өйрәнүгә дә зур әһәмият бирәләр. Мәсәлән, берничә ел элек директор урынбасары, татар теле һәм әдәбияты укытучысы Эльвира Ихсанова башлангычы белән «Бай тарихлы Урманай» дип аталган саллы китап дөнья күрде.

Шәхсән үземә Урманай мәктәбен тәмамлаучылар арасында иҗади, гуманитар фәннәргә тартылган балалар күбрәк төсле. Бу фикерне Гөлшат Әсгатовна да дәлилләде. Укучылар иҗади бәйгеләрдә чыгыш ясый, олимпиадаларда алдынгы урыннар яулый, хәтта халыкара бәйге җиңүчеләре дә бар. Әйтик, Илнар Камаев татар теленнән халыкара олимпиадада җиңгән иде. Шуңа күрә безнең укучылар арасында тел белгечләре, укытучылар күп булу табигый күренеш шикелле. Артистлар (Илназ Хәбибуллин – Г. Кариев исемендәге Татар дәүләт яшь тамашачы театры артисты) һәм журналистлар да бар.

– Бүген иң төп бурычыбыз – алга таба да шушы матур нәтиҗәләрне саклап калу. Укучыларыбыз күп булсын иде. (Бүген белем йортында 50 укучы укый. – **Авт.**) Кызганыч, кайбер әти-әниләр балаларын шәһәр мәктәбенә йөртеп укыту яклы. Ләкин, беренчедән, авыл мәктәпләре дә сыйфат ягыннан бер дә калышмый. Икенчедән, шәһәргә киткән укучы анда игътибар җитеп бетмәүдән югалып калырга мөмкин. Ә монда без бер гаилә шикелле яшибез һәм укыйбыз. Моннан тыш, безне мәктәпкә кадрлар җитеп бетмәү дә борчый. Информатика, физика, ТИН, физкультура укытучыларын читтән җәлеп итәргә мәҗбүрбез. Димәк, ирешәсе уңышларыбыз алда әле.

Ә мин күп, акыллы һәм рәхмәтле укучылар телим сиңа, мәктәбем. Гомерең озын булып, алда әле тагын бик күп матур бәйрәмнәреңне күрергә насыйп булса иде!

Зөһрә САДЫЙКОВА

Язучы сүзе

Марат КӘБИРОВ

Туган көн

Балаларны яраталар, туган көннәрен матур итеп уздыралар. Барыбыз да шулай. Бу күренеш элек тә бар иде. Малайлар үзара туган көн бүләкләре белән мактанышa да торган иде.

Тик минем бәләкәй чакта беркайчан да туган көн уздырган, бүләкләр алган булмады. Әле киртәкураны төзәтеп, әле мунча, әле абзар салдырып, бертуктаусыз мәшәкатьләр арасында йөргәч, әнинең акчасы да җитеп бетмәгәндер инде. Үзе күреп, гадәтләнеп үскән нәрсә булмагач, башына да килмәгәндер, бәлки. Гомумән, безнең өйдә туган көннәр үткәрү, бер-береңә бүләкләр бирешү гадәте юк иде. Шуңа мин бер мәлне сорадым:

– Әни, нигә син миңа бер дә бүләк бирмисең?

Ул аптырап китте. Хәзер аңлыйм бугай инде аның хәлен. Малай үстерәсең менә, аның өсте бөтен, тамагы тук, тубы, сәпите, аталы балаларда булган бөтен нәрсәсе бар. Ни теләсә, шул бар. Ә ул бүләк сорап тора.

– Акчаның кайда икәнен беләсеңме? – диде ул тыныч кына.

Мин белә идем. Кирәк чакта кирәк кадәрле алырга рөхсәт ителәә, мин кайчагында иптәш малайларны да киноға алып керә, перәнник алып сыйлаштыра идем. Артык комсыз булмаганмындыр инде, әмма күпме генә алсам да: «Нигә шулкадәр алдың?» – дип төпченүче юк иде. Гомумән, бөтен нәрсә минем карамакта иде. Кәнфит-печенье-перәнникләр – кайчан телисең, күпме телисең… Минем әби дә бар бит, дәү әни, мин аны «әнкәй» дип йөртәм. Менә шулай, берүземә ике әни булгач, мин күз өстендәге каш кебек.

Мин баш кактым, әни әйтеп куйды:

– Миндә аның кайгысы гына түгел, улым. Акчаның кайда икәнен беләсең, үзеңә үзең бүләк яса.

Бик укымышлы хатын түгел иде ул, өч кенә сыйныф белемле, тик тормыш тәҗрибәсе дә җитәрлек булгандыр, башы да ничава гына эшләгәндер инде, югыйсә болай дип әйтә алмас иде. Мин дә артык башлы малай түгел идем, әмма аның теге сүзе шундук хәтердә калды: «Үзеңә үзең бүләк яса».

Кибеткә барып, бер кармак алдым. Кармак кына алган булсам, иң мөһим бер нәрсәне аңламый каласы булганмын, дип уйлыйм хәзер. Тик мин учымдагы акчаны әвәләп торганнан соң бер кило перәнник тә сорадым. Өйгә алып кайттым. И, дәү әни сөенде инде:

– Бер бала булса, үз тамагына тыгып бетерергә тырышыр иде әле, ә син өйгә алып кайткансың. Маладис, балам. Рәхмәт. Гел шулай бул, үзеңне генә кайгырта торган булма, – диде.

Мин өйгә кайтышлый ул перәнникнең яртысын диярлек үз тамагыма тыгып бетергән идем бугай инде, тик бу хакта беркемгә дә сөйләнеп тормадым. Әнкәйнең сүзләрен колагыма элеп кенә куйдым. Һәм үземчә ачыш ясадым: «Үзеңә бүләк ясау әйбәт, тик ул бүләк тагын кемнәрнедер сөендерсә, отыры яхшырак икән». Бу ачышны да кычкырып йөрмәдем, патент дауламадым. Үзем генә белдем. Кайбер нәрсәләрне үзең генә белү хәерле.

Шуннан мин үземә үзем бүләк ясарга күнегеп киттем. Башта туган көннәрдә… Үземнекендә, әнкәйнекендә, әнинекендә. Нәрсәдер алып кайтып, өстәлгә куям. Аптырап калалар. Алар бит туган көн уздыруга күнекмәгән. Шуннан үзләренең туган көннәре икәнен исләренә төшерәләр дә, аның да кем өчендер бәйрәм икәнен аңлыйлар да, и, сөенгән булалар. Аларның шулай шатлануы – минем өчен бүләк. Рәхәт. Хәзер инде гаиләдә туган көнне билгеләү гадәте китте.

Рәхәт нәрсәләрне гел кабатлыйсы килеп тора. Гел кабатлана башлагач, кайберләре гадәти кебек тоела башлый, сафлыгын, яңалыгын югалта. Шуңа яңаларын эзләргә мәҗбүр буласың, табасың, сөендерәсең һәм сөенәсең. Мин дә әниләремне сөендерү өчен төрле сәбәпләр эзлим. Кайберләре бик әйбәт килеп чыга, кайвакыт барып чыкмый. Ләкин мин яхшы беләм: үзеңә үзең ясаган иң зур бүләк ул – яраткан кешеләреңне сөендерү.

…Бүген мин өлкән яшьтәге кеше инде. Тормышның да әллә нинди урыннарын кичергән, шул урыннардан бик пычранмыйча чыккан кеше. Бала чактан күңелгә сеңеп калган теге тойгы һаман исән әле. Офыкларың киңәйгән саен, якын кешеләрең дә күбәя. Тик аларны сөендерүдән син кимемисең, шул кешеләрне шатландырудан син артасың гына. Безнең гомернең сыйфаты, бәлки, җыйган мөлкәт, туплаган мал, дан, дәрәҗә белән түгел, ә өләшкән шатлык белән үлчәнәдер. Шулайдыр ул. Мин шулай дип уйлыйм. Бер-беребезгә сөенеч өстәргә теләп яшәсәк, бик күп афәтләр булмый калыр иде.

«ВТ» архивыннан

СӘЙДӘШЕВ МУЗЕЕНЫҢ ЯҢА ҖИТӘКЧЕСЕ АЙДАР ӘХМӘДИЕВ:

«МАКСАТЫБЫЗ – ИШЕКЛӘРНЕ КИҢ ИТЕП АЧУ»

Танышу

Сәйдәшев музее яшьләр кулына тапшырылды: җитәкче вазыйфасына яшь язучы Айдар ӘХМӘДИЕВ билгеләнде. Җиде ел буе ябык торган музей ишекләре кайчан ачылыр? Яңа җитәкче нинди яңалыклар алып килер? Бу сорауларны без Айдарның үзенә бирдек, татарның югалган музыка сәнгате, мирас һәм аны халыкка кайтару турында сөйләштек.

Яңа җитәкче

:: Кем ул – Айдар Әхмәдиев? Ул музыка дөньясына ничек килеп эләкте?

– Мин – татар-рус мәктәбендәге татар сыйныфында укыган Казан баласы. Музыка, театр, гомумән, иҗат белән кечкенәдән кызыксынам. Татар музыкасына мәхәббәт «Шүрәле» балетын карагач уянды. Татар мохитендә үстем, музыкант булырга, опера язарга хыяллана идем. Килешәм, кечкенә малай өчен – бик сәер хыял бу. Үземне табу теләге мине Малайзиягә кадәр алып барып җиткерде. Алты ел читтә яшәгәннән соң, Казанга вакытлыча гына кайткан җиремнән кире китә алмадым. Башкала танымаслык дәрәҗәдә үзгәргән иде. Мондагы мохит, татар мохите, вакыйга арты вакыйга мине таң калдырды. Һәм мин калдым. Театр дөньясына кереп киттем. Озак та үтми, композитор Миләүшә Хәйруллина белән «Кави-Сәрвәр» операсын язарга керештек. Өч-дүрт еллап тырышканнан соң, ниһаять, «бала»бызны сәхнәгә күтәрдек.

:: …һәм шул уңыштан соң сезне җитәкче вазыйфасына билгелиләр. Иҗатыгызга киртә куяр дип курыкмадыгызмы?

– Миңа бу вазыйфаны берничә кеше тәкъдим итеп карады. Башта, әйе, шулай булыр дип уйладым. Ләкин иҗат итү ул өстәл янына утырып язу гына түгел бит әле. Шул ук чаралар, проектлар әзерләү дә – иҗат.

Ябык ишекләр артындагы мирас

:: Ниләр эшләргә өлгердегез?

– Музейга күбрәк яшьләрне җәлеп итәргә телибез. Шуңа да аларга кызыклы булган форматлардагы кичәләр оештырабыз. Фатирниклар, лекцияләр… Яшь композиторлар, музыкантлар өчен дә ачык буласыбыз килә. Үзләрен сынап карар өчен менә дигән мәйданчык бу.

:: Бу чаралар барыбер ябык ишекләр артында уза. Ягъни музей әле дә ачылмады.

– Әлегә чаралар менә шушы бүлмәдә (музейның беренче катындагы музыкаль салон турында сүз бара. – **Авт.**) генә уза. Бина бик иске, реставрация булса да, хәл итәсе техник мәсьәләләр бар әле. Гади генә йорт түгел бит бу, шуңа да белгечләр белән киңәшеп эшләргә кирәк. Ләкин эш бара, кышка кадәр өлгерербез дип өметләнәм. Аның концепциясе яңадан төзелде. Хыялыбыз – Салих абый белән генә чикләнмичә, татар музыкасы мирасы турында сөйләү. Билгеле, музейда Салих Сәйдәшевкә аерым урын биреләчәк. Ул иҗат иткән мемориаль бүлмәне – элекке Ак бүлмәне торгызырга ниятлибез. Композитор яшәгән чорда нәрсәнең кайда торганы билгеле, ул истәлекләрдә сакланган. Без шуларга таянып эшләргә, ул яшәгән мохитне тудырырга тырышабыз. Монда икенче хатыны бүләк иткән пианиносын алып керә алдык. Ул утырган урындык һәм башка кайбер җиһазлар сакланган. Ә башка бүлмәләрдә татар музыкасы тарихын чагылдырырга иде.

Татар музыкасы – үзенә күрә феномен бит ул. Башка милләтләрдә 200–400 ел дәвамында барган процессларны без бер гасыр эчендә барлап чыкканбыз. Билгеле, татар музыкасы тарихы исламга кадәр булган чорга ук барып тоташа. Ә узган гасырда барлыкка килгән профессиональ музыка башында Салих Сәйдәшев, Солтан Габәшиләр тора. Шул кыска гына вакыт дәвамында музыканың бөтен юнәлешләрен үзләштерә алганбыз. Кызганыч, бу җәһәттән халыкка хезмәт иткән бик күп шәхесләрнең исемнәре онытылган диярлек.

> Элек безнең аш бүлмәсендә гел «Татарстан» радиосы яңгырый иде. Көн саен концертлар, опералардан өзекләр... Ул язмаларны хәзер табып та булмый. Ә бит ул безнең музыка «җәннәт»ебез булган! Без аңа юлны югалттык кебек... Кире ачасы, бу байлыкны халыкка кайтарасы иде.

:: Сер түгел, музейдагы озакка сузылган ремонт шактый шау-шу уятты. Ачылу вакыты да, сездән генә тормый торган сәбәпләр аркасында, әледән-әле күчеп тора. Бу авырлыклар сезне куркытмыймы?

– Ничек кенә булса да, яңа эшкә алыну гел куркыныч. Әмма адым ясамасаң, алга барып булмый. Барып чыгармы-юкмы, барысы да – Аллаһы Тәгалә кулында.

:: Салих Сәйдәшевнең туганнары белән аралашасызмы?

– Ел саен Югары Ослан районының Кызыл Байрак авылында «Сәйдәшстан» фестивале уза. Быелгы фестивальдә аның туганнары белән танышырга насыйп булды. Киләчәктә алар белән тагын да тыгызрак элемтәдә эшлисе иде.

Бушлык

:: Салих Сәйдәшевкә бәйле экспонатлар турында әйттегез инде. Ә аның рухи мирасы, ягъни әсәрләре ни хәлдә? Алар ни дәрәҗәдә өйрәнелгән?

– Аның кулъязмалары музейда да, Камал театрында да, ИЯЛИдә дә саклана. Салих Сәйдәшев иҗаты буенча фәнни мәкаләләр дә юк түгел. Әмма болар барысы да билгеле бер даирә кешеләр өчен генә ачык. Мисал өчен, мин интернеттан аның көйләренең ноталарын эзли башласам, берни дә таба алмаячакмын. Кулъязма турында әйтмим дә, бастырылган вариант интернетта юк. Гомумән, бу – татар музыкасы өчен уртак проблема. Булган ноталарны туплап, бер электрон фонд ясыйсы иде. Ул – халык мирасы. Димәк, һәркемнең аны күрергә, файдаланырга хакы бар.

> Шуңа игътибар итәм: музыка уку йортларында татар композиторларына урын бирелми диярлек. Мин аралашкан яшь музыкантлар арасында, без алар турында бөтенләй берни белмибез, диючеләр дә бар. Нинди зур бушлык, упкын! Безгә күпсанлы сорауларга җавап бирергә кирәк. Татар музыкасы нинди ул? Ни өчен мөһим? Ни өчен без аның белән горурланырга тиеш?

:: Гаҗәеп бай татар музыка сәнгатенә тиешле игътибар бирелмәүнең сәбәбе нидә дип уйлыйсыз?

– Глобаль процессларның бер өлешедер бу. Сәяси факторлар да эзсез калмыйдыр. Күреп торабыз: без бер кечкенә генә халыкка әйләнәбез. Кая гына карама, интернет дисеңме, мәктәп системасымы – бар нәрсә рус телендә. Музыка өлкәсендә дә шулайрак. Безнең музыка сәнгатенә икенче сортлы әйбергә караган кебек карыйлар, музыка уку йортларында укучылар композиторларыбызны белми диярлек. Әйе, әйткәнемчә, татар музыкасы чагыштырмача яшь. Ләкин аның нинди контекстта барлыкка килүен белергә кирәк. Бәлки, шул ук Сәйдәшев әсәрләре дә гади кебек күренәдер. Ләкин аның катлаулылыгы – гадилегендә. Син аны бер утыруда уйнарсың, ләкин аның рухын, табигатен ача аласыңмы? Монысы – икенче мәсьәлә.

Әңгәмәдәш – Лилия ГЫЙМАЗОВА

ӨЗЕЛМӘС ҖЫР

МӘШҺҮР ҖЫРЧЫ РАФАЭЛЬ ИЛЬЯСОВНЫ ИСКӘ АЛДЫЛАР

Соңгы бүләк

Гаҗәеп тавыш иясе, татар халык җырларын башкаруда эталон, җыр сәнгатен зур югарылыкка күтәргән шәхес, туган җанлы кеше. Татарстанның халык артисты Рафаэль Ильясовны әнә шулай искә алдылар. Узган җомгада аның һәм тормыш иптәше Светлана ханымның каберләренә истәлек ташы куелды, рухларына дога кылынды.

«Татар-информ»

Истәлек ташы эскизының авторы – Татарстанның халык рәссамы Нәҗип Нәккаш. Ташның үзен рәссам-скульптор Эмиль Мөхәммәдуллин ясаган.

Рафаэль Ильясов вафатына өч ел тулып килә. Җырчы 2020 елның декабрендә вафат булган иде. Узган җомгада аның кабере янында янәдән туганнары, хезмәттәшләре, дуслары җыелды. Тормыш иптәше белән икесенең каберләрен тоташтырган истәлек ташы ачу мәрасимендә Коръән сүрәләре хатирәләр белән үрелеп барды.

Билгеле булганча, Рафаэль Ильясов 1964–2005 елларда «Татарстан» радиосының музыкаль тапшырулар редакциясенең баш мөхәррире була, радиодагы эшчәнлеген 2014 елга кадәр туктатмый. «Татарстан» дәүләт телевидение һәм радиотапшырулар компаниясе директоры Фирдүс Гыймалтдинов аның җыр сәнгатенә керткән бәһасез өлеше турында сөйләде.

– Рафаэль абый 1964 елдан бирле безнең радио комитетында эшләде. Татар җыр сәнгате мирасын туплау, кайтару, саклау өчен бар көчен куйды. Радио фондындагы язмаларның күбесе – Рафаэль Ильясов тырышлыгы белән тупланган хәзинә. Ни кызганыч, без аңа Тукай бүләген бирә алмадык. Үзе дә моны бик көтсә дә, үпкәсез кабул итте. Бик тырыштык, калганы безнең намуста түгел… Чын талантны халык болай да күрә, таный, ярата, – диде ул. – Әлеге истәлек ташын әзерләгән кешеләр күңелләрен биреп эшләде. Нәтиҗәдә зәвыклы, Рафаэль абыйга лаек таш килеп чыкты.

«Татарстан муниципаль берәмлекләре Советы» ассоциациясе рәисе Әгъзам Гобәйдуллин якташына бәйле истәлекләрен яңартты.

– Без кечкенәдән Рафаэль абый иҗаты белән горурланып яшәдек. Безнең районны бик белмиләр иде, ә «Рафаэль абый Ильясов районыннан» дисәк, Чүпрәледән булуыбызны шундук аңлап алалар иде, – дип искә алды ул. – Ул – бар гомерен, бөтен көчен Татарстан халкына хезмәт итүгә биргән шәхес, без аның алдындагы бурычларыбызны түләп бетерә алмадык әле.

Татарстанның Журналистлар берлеге рәисе Илшат Әминов та балачагына кайтып килде.

– Балачактан бер хатирә искә төште. Әни кунаклар килүенә матур гына өстәл әзерләгән. Кунаклар арасында Рафаэль Ильясов та бар. Мин өстәл астында аларның сөйләшүен тыңлап утырам. Бераздан Рафаэль абый җырлап җибәрде. Һәм шул мизгелдә бөтен хатын-кыз елый башлады… Аның тавышы гаҗәеп тылсымга ия иде. Ул аеруча хатын-кызларга бик тәэсир итте, – дип сөйләде ул.

Профессиональ җырчы, композитор, галим булуыннан тыш, Рафаэль Ильясов, бар туганнарын тигез күреп, алар өчен җанын бирергә әзер кеше булган. Кемерово шәһәреннән үк кайткан сеңлесе Гөлсинә Абдуллина абыйсын искә алганда күз яшьләрен тыя алмады.

– Ул бит әле дә безнең янәшәбездә кебек. Ишекне ачар да: «Ә, әле сез көне буе минем турында сөйлисезмени?» – дип елмаеп керер кебек… Абый, син бүген үз яныңа барыбызны җыйдың, очраштырдың. Бу көн әле озак кына йөрәкләрдән җуелмас. Аның турында шулкадәр күп җылы сүзләр әйтелде, аны хөрмәт итеп шулкадәр күп кеше җыелды, – диде ул.

Гөлсинә ханым абыйсының каберенә истәлек ташы куюны оештырган Шиһабетдиновлар гаиләсенә, Рәшит Фәсхетдиновка да олы рәхмәтен җиткерде.

– Рафаэль Ильясов һәм аның тормыш иптәшенең каберләренә таш эскизы әзерләгәндә, Казан ханлыгы чорындагы традицияләргә таяндым. Ташта икесенең дә тугралары язылды, ике каберне тоташтырган стелада Рафаэль Ильясовның музыка әһеле булуын күрсәттем. Үзәктә «скрипка ачкычы»на охшатып гарәп телендә «Әлһәмдүллилләһи» язуы, астагы нота станында исә ул башкарган «Олы юлның тузаны» җырының ноталары урын алды, – дип тасвирлады Нәҗип Нәккаш.

Җырчыны искә алырга «Башкортстан» дәүләт телевидение һәм радиотапшырулар компаниясенең радиотапшырулар хезмәте җитәкчесе Ришат Миндияровның килүе очраклы түгел.

– Бу бөек шәхес – ике республиканың да улы. Ул – татар һәм башкорт халыклары арасында күпер салучы. Бүгенге кебек искә алу көне бу дуслыкны дәвам итү традициясе булыр дип ышанам, – диде Ришат әфәнде.

Рафаэль Ильясов турындагы хатирәләрне газета битләренә генә сыйдырып бетереп булмас иде. Ул калдырган мирас турында да бик озаклап сөйләшергә була. Ләкин әлеге язманы җырчыга багышлап Рәфис Корбан иҗат иткән шигырьнең истәлек ташында урын алган дүрт юлы белән тәмам итик. Ул үзенә барын да сыйдырган кебек:

Син татарның җырчы кошы идең,
Җанга шифа булды моңнарың.
Халкың барда – аның күңелендә
Мәңге тынмас синең җырларың.

УКУЧЫ СҮЗЕ

ПАРТАДАШЫМ ӘЛФИЯ

Күрше кызы Әлфия белән бер партада утырып, Чуашстандагы Козловка районының Кармыш урта мәктәбендә белем алдык. Уку алдынгылары идек. Әлфия Рухина 43 ел Яшел Үзән районының Урысбага мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты укыта.

Күрше кызы кечкенәдән укытучы булырга хыялланды. Башка һөнәр турында уйлап та карамады. Олы абыйсы Ильяс – спортчы. Икенче абыйсы Исмәгыйль, Арча педагогия көллиятен тәмамлап, авылыбызда башлангыч сыйныфларны укытты.

Әлфия белән икәү китапханәдә иң күп китап укучы идек. Рус, татар классикларын бергә укыдык. Хәтерлим әле, Әлфия Мәхмүт Галәүнең «Мөһаҗирләр»ен бер көндә укып чыкты. Дус кызымның тырышлыгына соклана идем. Мин гаиләдә олы бала булгач, өйдә эш күп. Аның артыннан җитешә алмыйм. Ул китапларны шәл бәйли-бәйли укыды.

8 нче сыйныфны икебез дә «5ле»гә генә тәмамладык. Дустым Арча педагогия училищесына укырга керде. Аннан соң Казан педагогия институтын читтән торып тәмамлады. Бәчек егете Фазыл Рухин белән тормыш корып, шул авылда төпләнеп калды.

Тышкы һәм эчке матурлыгы тәңгәл килгән төпле белемле, үтә дә тәрбияле укытучы ул. Яхшылыкка өйрәтүче, үз артыннан ияртүче остаз. Һәрвакыт гадел, сабыр. Әлфияне якыннан белүче һәркем аны тырыш, эшен җиренә җиткереп башкаручы буларак бәяли.

Фазылы якты дөньядан китсә дә, сыйныфташым нигезен нык тота: мал-туар асрый, тавыклар тота. Бар җирдә дә чисталык. Балаларының өчесе дә тормышта үз юлларын тапкан. Олы улы Фаил әнисе юлын сайлаган. Татар гуманитар институтын тәмамлап, тарих укыта. Фәнил Казан төзелеш-архитектура институтын тәмамлаган, Лилия – хисапчы.

Балалары, оныклары, укучыларының хөрмәтен тоеп яши партадашым Әлфия.

Равилә МӨБАРӘКШИНА.
Казан

Бу – мин!

Күңелне кузгатты иртәнге шау кояш,
Талчыккан канатлар җанлана иңемдә.
Кемгәдер – бигайбә! Сезләргә ярыйм дип,
Үземә хыянәт италмыйм бүгенгә.

Ымсынам кабаттан күкләрне кочарга,
Дәртем дә, дәрман да хәзергә җитәрлек.
Күңелнең җегендә моң-мәкам ярала –
Юл чыгар алдыннан догалык итәрлек.

Бу очыш соңгысы булса да үкенмим,
Гарешкә төбәлдем: «Мең шөкер!
Мең рәхмәт!»
Кисәтеп, өн килде: «Канатың көймәсен!
Кыйблаңны үзгәртмә, купса да кыямәт».

Канатлар, киерелеп, җил көчен сынады,
Бирелгән карардан ваз кичү икеле.
Мин, янып төшсәм дә, бәхетле китәрмен,
Очышта җан биргән чал бөркет шикелле.

Сания ӘХМӘТҖАНОВА

Илдар Мөхәммәтҗанов

Онытмыйбыз

Безнең Яшел Үзән шәһәрендә бик күп еллар буе хөрмәтле кешебез, Россия Федерациясенең атказанган укытучысы Вәфилә Хикмәтуллина эшләде. Мәктәптән киткәч тә, үз укучылары өчен җан атып тора ул. Балалар да, ата-аналар да аңа бик рәхмәтле. Хәзер ул Казанда яши. Аралар ераграк булса да, без аны онытмыйбыз. Очрашып торабыз.

Якын кешебезне чын күңелдән Укытучылар көне белән котлыйбыз. Озын гомер, сәламәтлек телибез. Юлыгызда гел чәчәкләр, яхшы кешеләр очрап торсын. Шәкертләрегезнең елмаюлы йөзләрен күреп торырга язсын.

Барлык укучылары исеменнән,
Светлана АБДУЛЛИНА, Луиза ЗИЯТДИНОВА

ҖЫРЧЫ АГРОНОМ

Кай арада узып киткән диген: Рөстәмгә дә 60 яшь икән. Сүзем – Мамадыш районының Арташ авылында яшәүче, 40 елга якын гомерен авыл хуҗалыгына багышлаган агроном Рөстәм Галиев турында.

Әле дә хәтеремдә: 1985 елны килде ул. Балык Бистәсе районының Биектау авылыннан икән. Туган авылында 10 нчы сыйныфны бетергәч, Тәтеш совхоз техникумының агрономнар әзерләүче бүлеген тәмамлаган да ике еллык армия хезмәтен үтәп кайткан. Урта Кирмәндәге Киров исемендәге күмәк хуҗалыкка агроном булып урнашты.

Эшкә үҗәтлеге бәләкәйдән була малайның. Яшең җитми әле дип, Биектау мәктәбенә беренче сыйныфка алмыйлар аны. Рөстәмнең анда эше юк, ничек инде җәй буе бергә уйнаган ике яктагы күрше малайларны алганнар, ә аның, имеш, яше җитми. Ничек итсә итә малай, өч көннән әнисе хәлне партоешма секретарена җиткерергә мәҗбүр була. Шуннан соң «яше җитмәгән малай» урамдашлары белән бер партага утырып укый башлый.

Урта Кирмәндә эшли башлаганнан соң, бөтен гомере күз алдымда узды. «Минем бәхеттән, эшли башлаган елымда ике белгеч – ике Рөстәм эшкә килделәр: Галиев Рөстәм – агроном, Хамизуллин Рөстәм – инженер. Үз яннарына башка белгечләрне, яшьләрне тарттылыр, күңелдә бераз ышаныч, горурлык хисе туды», – дип искә ала ул елларда күмәк хуҗалык рәисе булган Хәлим Сәлахов. Колхозның тулай торагы юк, килгән белгечләрне ялгыз кешеләргә фатирга урнаштыралар. Ике Рөстәмне безнең күршегә урнаштырдылар. Шуннан соң аралар тагы да якынайды. Кеше өстендә торуның кыенлыкларын торып караган кеше үзе генә белә инде. Басу эшеннән гел чиста гына да кайтып булмый, өс-башны юарга да, киптерергә дә кирәк. Үзең теләгән әйберне генә дә ашап булмый. Үз куышы булганчы, берничә йортта өйдәш булып яшәргә туры килә әле аңа. Кая куйсаң, шунда сыя иде.

Шул елдан алып хәзерге көнгә кадәр туган җир туфрагына хезмәт куя һәм үз эшен белгән тәҗрибәле һөнәр остасына әверелә Рөстәм Мингалиевич. Читтән торып башкаладагы авыл хуҗалыгы институтын тәмамлый. Туксанынчы елларда ул баш агроном булган авыл хуҗалыгы предприятиесе районда иң уңышлысы һәм тотрыклысы була. Үсемлекчелек буенча эш хуҗалыкка яхшы табыш алып килерлек итеп җайга салына. Агроном өчен бу чорда ял көннәре дә, бәйрәм көннәре дә булмый. Икмәк уңышы гектарыннан 38 центнерга җиткән еллар була.

Рөстәм Мингалиевич бик ачык, аралашучан, теләсә кем белән уртак тел таба ала. Килүгә, авыл яшьләре аны, бик теләп, үз араларына алалар. Өстәвенә Рөстәм матур итеп җырлый да. Гомере буена туган авылында клуб мөдире булып эшләгән әтисе Мингали абый оста җырладымы икән, әллә дүрт баласын да бишек җырлары җырлап, күңелләренә моң салып үстергән әнисе Нурия йогынтысы булдымы – анысын белмим. Җырчы агроном үзешчән сәнгатьтә дә актив катнашты, авыл мәдәниятен үстерүгә дә күп өлеш кертте.

Алны-ялны белми хезмәт куйган елларында гаиләсе аның өчен төп терәк була. Үзенә тормыш иптәше итеп Арташ авылыннан фельдшер кыз Эльмираны сайлап ялгышмый. Йортны да шул авылда булдырып, матур гаилә коралар. Кызлары Илүзә дә, табиб профессиясен сайлап, Казан медицина институтын тәмамлап, районыбызга эшкә кайтты.Үз гаиләсен булдырып, әти-әнисенә ике онык бүләк иттеләр. Барысының бергә мул табын янына җыелуы – ата-ана өчен иң бәхетле мизгелләр. Иң сөендергәне – ике якның да әти-әниләре исән-саулар, аларга игелек күрсәтеп яши алудан да олы бәхет бармыни!

Ринат ХӘЙРУЛЛИН.
Мамадыш, Арташ – Урта Кирмән

Осталыкка – һәйкәл

«Пирамида» дип йөртелгән күркәм корылманы күпер салучылар осталыгына һәйкәл дип тә әйтергә ярыйдыр. Төгәл геометрия фигурасы ясап төзелгән үзенчәлекле корылма 113 нче санлы Чаллы күпер төзү отрядының хезмәт җимеше икән ул! Әлеге отрядның шундый уникаль архитектуралы мәдәният үзәген салырга җөрьәт иткән бердәнбер оешма икәнлеген дә искәртсәк, минем белән килешерсез дип уйлыйм. Бөтен Татарстанга бердәнбер булган төзелешкә ни өчен нәкъ менә күпер төзү отряды чакырылган дисезме? Эш бүлешү бәйгесендә байтак оешма катнаша анысы. Әмма тендер алырга ашыкмыйлар алар. Сәбәбе гади. Математика фигурасы булгач, анда төгәллек таләбе бик кырыс була. Һәм менә шул таләп бүтән төзелеш оешмаларын, хәтта чит илнекен дә өркетә. Шуннан Миллениум күпере төзелешендә ялтырап алган Чаллы осталарын чакырып карыйлар.

Бу хәлләрне мин әлеге отрядның геодезия белгече Госман Сәлахов белән танышкач белдем. «Пирамида» проектын өйрәнергә отряд җитәкчелеге алдан аны алып бара. Геометрик фигуралы конструкцияне җыйганда тайпылыш, ачуым бер килмәгәе, чәч бөртеге дә сыймаслык булырга, ягъни миллиметрдан узмаска тиеш. Тәҗрибәле белгеч эшли алачакларын әйтә. Тиз күтәрелә корылма. Чаллы егетләре Болак буен бизәгән «Пирамида»ны вакытында ачлап куялар.

Каян килеп чыкканнар икән соң Чаллы осталары бирегә? Әлбәттә, күпер салып килеп керәләр алар Казанга. Казансу елгасы аша Миллениум күперен коралар башта. Ике отряд төзи Миллениумны: уң яктан – Чаллы отряды, сул яктан каршыга Казанныкы килә. Ашыгырга кирәк! 2004 ел – мәркәзебезнең мең еллыгын каршы алырга әзерләнгән вакыт. Һәм төп-төгәл килеп тоташа ике яктан корылган күпер! 2005 елның 29 июнендә Яңа Савин һәм Совет районнары елга аша турыдан үтеп, кул кысыша. Казаныбызның 1000 еллык юбилеена лаеклы бүләк була бу күпер.

Чаллы егетләрен Казанга китереп җиткергән юлдан баруыбызны дәвам иттерсәк, тагын бер күпер үтәргә туры килә безгә. Аны Чулман кичүе дисәк, дөресрәк булыр. Тулаем исәпләгәндә, аның озынлыгы 13967 метрга җитә. Паром көтеп иза чигүләр, ниһаять, юкка чыга.

Госман Сәлахов белән очрашкач, фотосурәтләр карап, күпер төзелеше турында сөйләшеп утырдык.

– Субайларны күпернең нигезе диярга була – ялгышырга ярамый анда, – ди ул. – Башта субай сугыласы урынны үлчәп билгелибез, аннары шул төштә су төбен чокып, каты катламга хәтле төшәбез һәм корыч стакан төшереп беркетәбез. Аның эченнән суны насос белән суыртып алабыз һәм менә шул тимер кое эчендә иркенләп эшлибез. Башта корыч үзәген торгызабыз, аннары шуны тимер-бетон белән ныгытабыз.

Госман төзүче-монтажник һөнәренә укып чыккач, тугыз ел КамГЭС плотинасын төзүдә эшли. Аннары Менделеевскида химзавод кора, Апатит каласы янында шахта өчен ике тауны тоташтырган тимер күпер сала. Шахта ягыннан аларның оешмасы Ульяновскига Идел күперен төзергә кайта. Идел ярларын тоташтыргач, ниһаять, Чулманга юл тоталар. Чулманны кичкәч, мәгълүм Миллениум һәм «Пирамида» төзелешләре… Госман белән сөйләшкәндә, мин шуны абайладым: ул янып-кызыксынып эшли һәм төзелеш никадәр катлаулы булса, шулкадәр үк ул аңа кызыгып тотына! Егет шулай остарганнан-остара, белем-тәҗрибәсен үстерә. Ә ир-атларны эшенә карап бәһалиләр. Шундый зур кичүне күтәргән егетләребез белән, һичшиксез, горурлана алабыз.

Ильяс САЛИХҖАН



vk.com

ӨЙ САЛУНЫҢ НИЕ БАР?

Йорт сала башлаганда (бу 1975 ел иде), кырык яшен тутырган әни иң кече сеңлем Флүзәгә көмәнле булган. Әле бала тапканчы, фермада сыер саварга, бала-чаганы мәктәпкә хәстәрләргә, ихатада эшләргә кирәк.

Ул елларда яңа бәбиләгән хатынга бер ай гына ял бирелгән. Балалар ишәйгән саен, киңрәк йорт саласы килгән. Ризыгын хәләл көч белән табучы кешенең бу зур эшкә берничә ел гомере сарыф ителгән. Бураны бурау, аны киптерү, йортны җиткерү – шактый зур, мәшәкатьле эш. Шунлыктан халкыбыз аларны гомер-гомергә күмәкләшеп, өмә ясап башкарган.

– Бурага бүрәнәләр әзерләр өчен Югары Ложы урманыннан диләнке бүлеп бирделәр, – дип искә ала Әлфрит абый. Ул вакытта аның балта, чүкеч тотып, кул арасына керердәй үсмер чагы. – Безнең очтан Гарипҗан абый, югары очтан Рафаэль абый белән Зиннур абый, аръяктан Илдус абыйларны чакырып, бура бурадык. Ул абзыйлар бу эшнең чын осталары иде шул.

Осталарның кайберсе башына яулык чөеп бәйләгән, кайсы кулъяулыкның дүрт очын төйнәп, баш киеме әмәлләп куйган. Көн челләсендә бүрәнәгә аякларын чалыштырып утырган абзыйларның сеңерле каты кулларындагы балталары селтәнгән саен кояшта ялтырап китә. Суккан саен, чарт-чорт итеп, эреле-ваклы йомычкалар чәчри дә аста тәгәрәп яткан ишләре өстенә килеп төшә.

Үз йомышлары белән түбәндә ыгы-зыгы йөреп торган хатын-кызларның берәрсе күләгәгә яшереп куелган бидондагы катыклы салкын суны тамагы кипкән ир-атка салып бирә. Юан беләкләрен югары күтәреп, кояшта кызган тәннәрен уйнатып, абзыйлар зур калай чүмечне бушатып куя да, уч төпләренә төкергәләп, тагын җилләнеп эшкә керешә. Авыр эш булса да, бар кешенең күңеле күтәренке, кәефе шәп.

Еллар үткәч, әти салган йортны кирпеч белән тышладык.

Өмәгә пешерелгән сыйлар бигрәк тә тәмле була иде. Ул вакытка махсус үстергән бәрәннәр чалына. Мул иттән шулпа пешерелә, бәлеш салына. Хатын-кызларга ияреп, без – бала-чагалар да түбән очтагы Бүләк су буеннан бүрәнә арасына кыстырасы мүкне капчыкларга җыеп кайттык. Арасында дымлыраклары да очраса, яхшылап җәеп киптердек.

Иртәгә өй күтәрәсе дигән көнне бар туган-тумачага, күршеләргә, авылдашларга, балта осталарына әйтеп чыкканнар. Өмәгә дәшсәләр, кешеләр хәтта үз эшләрен калдырып булса да киләләр. Көн дә өмә булмый бит. Кеше сүзен тыңламасаң, үзеңне дә санламаулары бар.

– Булачак өйнең дүрт почмагына дүрт имән бүкән куйдылар. Осталар бүрәнәләрнең тигезлеген карап кына тора, – ди абый. – Кузлалар тезеп, кирәк кадәр бүрәнә салгач, биш-алты метрлы калын нараттан ырмаулап эшләнгән матча куела. Матчаны күтәрү – бик җаваплы һәм авыр эш.

Әзер бураны бер көндә күтәреп, мүкләп куйганнар. Өмәдә катнашкан һәр кеше йорттагыларга, озын, тигез гомер итсеннәр, салган йортларының игелеген күреп яшәсеннәр, дигән изге теләктә. Ул көнне туган-тумача, күрше-күлән ризык кертә. Кем – «коры аш», кем – йомырка, май, сөт, ипи…

Йортка җитәрлек төзелеш материалларын аннан табып, моннан җайлап кына кайтарышлы ул вакытта. Юк заман. Теле сөйләшә белгәннең, кулы бирә белгәннең, үзе ярдәмләшә белгәннең эшләре көйле барган.

– Кара әле, Нүрдидә, түбәлек калай юлладым, – дип сөенеп кайтып кергән әти. Әни, нинди калай булуын сораштыргач, кәефе төшеп:

– Алмыйкчы ул күгәрә торган калайларны, ел саен түбәдә мүкәләп калай буяу тагын бер мәшәкать була бит, Мөнәвир, – дип үгетли башлаган. Шуннан әти, күнеп, бераз ачулана төшеп, әнигә болай дигән:

– Ну, кызый, синең сүзеңне тыңлап, быел түбәне япмый калсак, кара аны, күзеңне дә ачтырмыйм.

Гөнаһ шомлыгына, әтине хастаханәгә салганнар. Сукыр эчәгенә операция булып, ул йорт мәшәкатьләреннән арынып торган арада, әни бик пошаманга төшкән. Вакыт уза, калай юк. Көз якынлаша, тиздән кышы да бастырып килеп җитәр. Шулай беркөнне әни каралты-кура арасында йөргәндә, аръяктан Халит абый килеп кергән.

– Артып калган калайлар бар иде, сезгә кирәкмиме? – дип кызыксынган. Бу – шушы минутта әни өчен җәүһәр бәясенә торырдай сорау бит!

– Әй, кирәкмиме соң, ничек кенә кирәк әле, Халит, – дип, әти белән булган хәлне сөйләгән әни. Коткардың, дип, бик каты сөенгән.

Түбәне япканда гына аяныч хәл булды. Ишегалдында, әтиләр үзләре көйләп куйган пилорамда авыр такта Илдус абыйның кулыннан ничектер ычкынып китеп, әллә ничә кабыргасын сындырган иде. Сөяк кыйпылчыклары үпкәсенә кадалып, байтак кына хастаханәдә ятып чыкты. Сүз куертып, кемнедер гаепләп йөрүче булмады, рәхмәт яугыры.

Тәрәзә йөзлекләрен әнинең абыйсы Әхмәтзәки абый ясаган. Идән-түшәмне Кәрәкәстән әбинең сеңлесенең ире, балта остасы Миңнулла җизни килеп җәеп киткән. Тәрәзә рамнарын ясарга әтине аръяктан Хәмәтдин абый өйрәткән. «Клуб кадәр өй салды Мөнәвир!» – дигән авылдашлар, йорт әзер булгач.

Без яңа йортка, мин башлангычны бетереп, дүртенче сыйныфка Бигеш урта мәктәбенә укырга киткән елны күчендек. Бүген анда абый белән җиңги яши. Әмма барыбыз өчен дә төп нигез ул.

Фирдәүсә БИКМӘТОВА.
Казан

ТӨЗӘТМӘ

Газетаның 29 сентябрь санындагы «Ялгыз бию» язмасында «Социология фәннәре кандидаты Чулпан Илдарханова» урынына «Татарстан Фәннәр академиясенең Гаилә һәм демография үзәге директоры, социология фәннәре докторы Чулпан Илдарханова» дип укырга.

Хата өчен гафу үтенәбез!

Студенческий билет, выданный Федеральным Государственным бюджетным образовательным учреждением высшего образования «Российская Академия Народного Хозяйства и Государственной службы при Президенте Российской федерации» Казанский филиал РАНХиГС, на имя Атнагулова Арсена Маратовича считать недействительным в связи с утерей.

ХА-ХА-ХАНӘ

Шушы урында көләсе

Мач әйткән!

Сергей КАПИЦА, танылган физик:

– Җитәкчелек итү – эшләүчеләргә комачау итмәү ул.

«Үпкәсез туй»

МУРАТ ГАЙСИН ЯҢГЫР ЯУДЫРА

Популяр башкаручы һәм җырлар авторы Мурат Гайсинны төрле туй-мәҗлесләрдә дә, концертларда да күрергә була. Бу җәйләре бик кызу узган. Пермь, Екатеринбург якларындагы татар авылларында 36 көн буе бертуктамый концерт куйганнар. Кайбер көнне хәтта икешәр концерт дип санасак, барлыгы 42 тамаша килеп чыга. Үзенә күрә рекорд. Җәйге турнеданниләр истә калган? Мурат «Ха-ха-хана»гә дә сөйләде. Авыл җирендә җырчыга чәчәк бүләк итү гадәте бик юк икән. Әмма җәй айларында тамашачылар бакчаларында үскән матур чәчәкләрен алып киләләр, ди. Бер концертта хәтта 10 букет бүләк иткәннәр. Аларга бигрәк тә коллективтагы кызлар шатлана икән. Ә беркөнне чәчәк бәйләмнәре әзрәк булган. Муратка бүләк иткәннәр, ә кызларга – юк. Күңелләре төшкән. Моны күреп, Мурат бер хәйлә уйлап таба: үз чәчәкләрен, кеше күрмәгәндә, арткы ишектән залның ахырына илтеп бирә. Шулай итеп, бер үк бәйләмне, икенче тапкыр сәхнәгә чыгарып, кызларга бүләк итәләр.

«Быел кайсы авылга барсак, шунда яңгыр яуды, – дип сөйләде Мурат. – Җәй буе бер тамчы да төшмәгән, безнең концерттан соң явып китә». Бу сәер күренеш турында сәхнәдән дә сөйли башлыйлар. Кайсы авылга яңгыр кирәк, чакырыгыз безне, янәсе. Шулай итеп, бу имеш-мимеш якын-тирә авылларга тарала. «Залларыбыз һәрчак тулы булды. Әллә җырларыбызны тыңларга килгәннәр, әллә яңгыр теләп – анысын аңламадык», – дип көлеп сөйләде Мурат җәйге гастрольләре турында.

Вәт килде замана!

– Дәү әни, син минем пауэрбанкны күрмәдеңме?
– Антресольдә түгел микән?
– Ә нәрсә ул антресоль?
– Ә нәрсә ул пауэрбанк?

❯❯❯

Гаепне үзеңнән эзләүдән тукта! Фэншуйны өйрән һәм гаепне дөрес тормаган йорт җиһазларына сылтый башла.

❯❯❯

– Мин – фрилансер.
– Эшең өйдәме?
– Өем – эшемдә.

❯❯❯

Чит ил машинасына оригинал булмаган кытай детальләрен сатып алабыз. Ә кытай машиналарына оригинал булмаган детальләрне каян аласы?

❯❯❯

Дәүләт минем һәр табышымны бүлешә. Ә һәр югалтуымны никтер бүлешми.

❯❯❯

– «Укы, эшлә! Ял беркая да китмәс!» – диләр иде миңа яшь чакта. Мин олыгайдым. Ял каядыр китте, ә уку белән эш калды.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Юмореска

ХӨКЕМ

Хөкем залында көр тавыш ишетелде. Ул үз исемен ишетеп, дертләп китте. Урындыгына ныграк ябышты. Тик бу котылу юлы түгел, барыбер урындыктан аерылырга туры киләчәк, аңа басарга кушалар иде. Ул бөтен көчен җыеп, аягүрә басты. Бар күңеле үкенү, әрнү белән тулды. Шулай да котылу юлы булырга тиеш кебек иде. Тик хөкемдарның көр тавышы өметкә охшаш хисләрне шундук куып таратты:

– Сез хезмәт урынында бөтен көчегезне куеп, тырышып эшләүдә гаепләнәсез!

Залдагы халыкның нәфрәтле карашы аңа төбәлде. Шулай булырга тиеш иде дер, беркайчан да артыгын тырышмаган бу кешеләр алдында ул гаепле иде. Үзенең нәрсәдер эшләргә тырышуы белән генә дә ул бу кешеләрне кимсетә, булдыксызга чыгарырга тырыша, бер сүз белән әйткәндә, аларның яшәү рәвеше өчен куркыныч тудыра иде. Ә үз тормышыңа янаган бәндәгә берәү дә сөеп-яратып карый алмый. Бу кешеләр хаклы, ул гаепле иде.

Гаепләүче аның җинаятьләрен санап китте. Бер карасаң, артык һуш китәрлек нәрсәләр юк иде. Эшенә вакытында килә, җыелышларны калдырмый, ул җыелышларда эшлекле тәкъдимнәр кертә, алай гына да түгел, шул уйларын тормышка ашырырга маташа. Һәм тормышка ашыра да. Ә бу башкаларны да эшләргә мәҗбүр итә, гадәттәгечә эленке-салынкы гына йөрергә ирек бирми. Соңгы вакытларда аның шушы юньсезлеге аркасында беркемгә дә тынгылык калмаган, бөтен кеше дә эшләргә мәҗбүр ителгән, ә көче җитмәгәннәр хезмәт урынын калдырып китәргә мәҗбүр булган. Ә бу илдә эшсезләр саны артуга китергән. Менә бит ничек! Бу гади җинаять кенә түгел. Моннан сәясәт исе килә.

Гаепләүченең чыгышын алкышларга онытмадылар. Шулай булырга тиеш иде. Үз мәнфәгатьләрен яклаучыны халык ярата. Ә бу юлы мәхкәмә халык мәнфәгатьләрен яклый иде. Адвокат әллә ни әйтә алмады. Шулай да эшкә вакытында килүне гаепкә чутламаска тәкъдим итте, чөнки бөтен кеше дә шулай итә, ләкин эшкә килү әле ул эшләү дигәнне аңлатмый. Бу тәкъдим белән килештеләр.

Залдагы халык ризасызлык белдермәсә дә, гаепләүченең ачуы чыкты һәм ул кабат сүз алды. Бу юлы гаепләү рәвеше бөтенләй башка яссылыкта яңгырады:

– Ул урлашмый, – дип башлады сүзен һәм җинаять эскәмиясендә утыручының гомерендә бернәрсә дә урламавын дәлилләрлек мисаллар китергәч, болай дип тәмамлады: – Менә монысы инде бернинди кануннарга да сыймый. Бу җинаяте белән ул безнең бөтен системаны куркыныч астына куя.

Зал озакка сузылган көчле алкышларга күмелде.

Алкышларлыгы да бар иде. Чөнки гаепләүче бөтен кешенең күңелендә җыелган дөреслекне ярып салды. Урлашмау бу илдә иң зур гөнаһ иде. Патшасыннан башлап гади кешегә кадәр һәркем үз ягын каера, җае чыкса-чыкмаса да, үз файдасына умырып калырга тырыша һәм бу иң гадәти хәл булып, яшәү рәвеше булып исәпләнә, системаның нигезен тәшкил итә иде. Хакимияттә утыручылар үзләренә урлашырга җайлы законнар кабул итә, шул законнар нигезендә мөлкәт җыя. Бандитлар шулай баеган кешеләрнең балаларын азгынлык, наркомания, эчкечелек юлына тартып акча эшли. Полиция шул бандитларның хәлсезләнеп яки бөлеп кирәксезгә әйләнгәннәрен төрмәгә яба… Һәм башкалар… Тормыш шул рәвешле бара һәм бу һәркемне канәгатьләндерә иде. Бу җәмгыятьтә урлашмаган кеше иң зур җинаятьче иде. Адәм үтерү дә – җинаять. Ләкин бер кешенең үлеме әллә ни зур югалтуга китерә алмый. Ә урлашмау ул – системаны нигезеннән черетергә, җимерергә омтылу. Син урлашмыйсың, мин урлашмыйм, ул урлашмый… Урлашмаучыларның саны шул рәвешле арта бара. Һәм рәхәтләнеп урлашырга теләгән хөрмәтле гражданнарның эшчәнлеге куркыныч астында кала. Бу илне таркату, идеологик диверсия, рухи террор иде.

Хөкем ителүче кечерәеп калуын үзе үк сизеп торды. Бетте. Болай булгач, бер өмет тә калмады. Аны ким дигәндә дә сәяси җинаятьтә гаепләячәкләр. Ким дигәндә дә гомерлеккә ябачаклар.

Адвокат хәзер гаепләүчегә каршы төшәргә тиеш кебек иде. Тик ул аны дәвам итте:

– Урлашмавы гына бер хәл әле. Ул бит шәфкатьлелек акцияләре дә оештыра. Әлбәттә, шәфкатьлелек белән шөгыльләнүчеләр сезнең арагызда да бар. Әмма моны һәркем үз мәнфәгатьләре өчен файдалана. Кемдер салым түләмәс өчен, кемдер – сәяси өстенлекләр, кемдер үзен рекламалау өчен. Ә бу бернинди шәхси максатларын күзалламыйча, чын-чынлап мохтаҗларга ярдәм итү өчен.

Моны көтмәгән зал тып-тын калды. Ә адвокат шул арада аның бу өлкәдәге эшчәнлеген барлап чыкты. Хәзер инде гаепләнүчегә гомерлеккә төрмәгә ябылу куркынычы буй җитмәслек хыял булып тоелды. Ул, берни дә күрмәскә теләп, күзләрен йомды.

– Үрдә чыгыш ясаучылар китергән дәлилләр бер генә нәрсәне куәтли, – дип сүзен тәмамлады адвокат. – Гаепләнүче – ахмак. Һәм аны төрмәгә ябарга түгел, ә хастаханәгә салырга кирәк.

Бу сүзләрне ишетүгә, халык никтер шаулаша башлады, урыныннан кубып, ишеккә юнәлде. Кинәт гаепләнүче күзләрен ачты. Һәм күңелен шатлыклы уй телде. «Аллага шөкер! – дип уйлады ул, ишеккә атлаган кешеләргә карап. – Аллага шөкер! Ярый әле юньләп эшләгәнем, башкаларга ярдәм иткәнем юк…» Һәм елмайды. Хөкем залында түгел икән бит, хезмәт урынындагы чираттагы җыелышта аз гына черем итеп алган икән. Шулай булгач, ничек шөкер итмисең инде?!

Ул арада бер хезмәттәшенең тавышы ишетелде:

– Кара әле! Арт ягыңа чуан чыкмагандыр бит?

– Юк, – дип елмайды ул. – Ник сорыйсың?

– Җыелыш буена басып тордың ич.

Марат КӘБИРОВ

Шаян шигырь

Хәдичә



Күрше кызы Хәдичә,
Шулай гадәттәгечә,
Озак йөреп бакчада,
Кичегеп кайтты кичә.

Каравылчы карт аның
Ишетмәгән кайтканын.
Шуңар күрә ачмаган
Хәдичәгә капканы.

Капкада тимер йозак,
Хәдичә көткән озак.
Тышта кунып булмый бит,
Булса да гәрчә йөз ак.

Ахры, кызга уй керә,
Төнлә белән кем күрә?
Күп тикшерми Хәдичә,
Койма аша сикерә.

Кайтып керә йортына,
Кайткач, бар да онтыла.
Тик, кадакка эләгеп,
Юбка гына ертыла.

Ул көн «соң» дип ямамый,
Аны-моны карамый.
Иртән китә хезмәткә,
Кичегергә ярамый.

Әле дә кичә соң кайтып,
Йоклаган кырын ятып.
Күрше карчык эшенә
Чак җибәргән уятып.

Менә бара ул, кара!
Юбка гына чайкала.
Исе китеп хатын-кыз
Юбкага карап кала.

Икенче көн ни күрәм? –
Бер елыйм да бер көләм.
Урам тулы хатын-кыз,
Бар да ерык юбкадан.

Күрче, күршем теккәнче,
«Мода» дип, көн үткәнче,
Бар да ерган юбкасын
Бот төбенә җиткәнче!

Әй, Хәдичә, Хәдичә!
Кичегеп кайтып кичә,
Нинди эшкә чуалдың –
Яңа мода чыгардың.

Кызлар, төнлә йөрмәгез,
Коймадан сикермәгез,
Тагын әллә ни ертып,
«Мода», – дия күрмәгез.

Муса ҖӘЛИЛ

Казан хәлләре

Бүген Бауман урамында сәер хәлгә юлыктым. Башта акча тулы эшләпә таптым. Аннары мине гитара белән ниндидер кеше куалап йөрде.

◆◆◆

Әнисе балконнан кычкыра:
– Кәрим!
– Нәрсә, әни?
– Тагын бер тапкыр телефон трубкаңны алмасаң, өйгә куып кертәм!

◆◆◆

Ул Илһам Шакиров, Әлфия Авзалова кебек мәшһүр җырчыларыбыз белән бер сәхнәдә чыгыш ясады. Дөрес, төрле концертларда.

◆◆◆

Кайвакыт университеттагы укытучыңны Бауман урамында очратасың да аны кем дип тә исеңә төшерә алмыйсың.

◆◆◆

– «Бертуган Касыймовлар» тукталышы. Киләсе – «Гарифҗанов» тукталышы.
– Гафу итегез, ә миңа кайчан чыгасы? Мин – Зәйнуллин.

Бала каләме

Сочинение «энҗе»ләре

Наташа Ростова нидер әйтмәкче иде, әмма кинәт ачылган ишек аның авызын япты.

Тарас Бульбаның ике улы бар иде: Остап һәм Бендер.

Бер генә күзем белән булса да Парижны күрер идем, дип хыялланган Кутузов.

Мәйданда төрле чүп ята иде: ташлар, плакат кисәкләре, агач ботаклары. Ленин да шунда.

Дубровский диванда телевизор карап ята иде.

Грибоедов «Горе от ума» әсәрен үзенең тормыш тәҗрибәсеннән алып язган, чөнки үзе дә бик акыллы булмаган.

Әтинең каршысына кыз һәм көчек өреп чыктылар.

Сыер савучы хатын мөнбәрдән төшкәч, аңа колхоз рәисе менде.

Учак янында ике кеше һәм бер хатын-кыз утыра иде.

Мин, үскәч, балалар табибы булам. Көчекләрне һәм песи балаларын дәвалыйсым килә.

Онегинның күңеле авыр иде һәм ул Татьяна янына җиңеләергә китте.

Лермонтов авылда дәү әнисендә туган. Ул чакта аның әти-әнисе Петербургта яшәгәннәр.

Походка без иң кирәкле әйберләрне генә алдык: чатыр, ашау-эчү, шырпы һәм укытучыбызны.

Гади халык, Некрасов әсәрләрен укып, үзенең ничек авыр яшәгәнен белгән.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5146 данә
Гомуми тираж – 13580 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 335

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасында мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыра торган муниципаль мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2023 елның 14 сентябрендә кабул ителде

1 статья

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасында мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыра торган муниципаль мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын әлеге Законга кушымталар нигезендә расларга.

2 статья

Әлеге Закон 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2023 ел, 28 сентябрь, № 76-ТРЗ

«2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасында мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыра торган муниципаль мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында»
Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

2024 елга Татарстан Республикасында мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыра торган муниципаль мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү
НОРМАТИВЛАРЫ

1. Гомуми үсеш төрендәге төркемнәрдә мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыруга финанс чыгымнары нормативлары

Төркемнәрнең төре	Тәрбияләнүчеләрнең яшь ягыннан составы	Җирлек/шәһәр округы	Гомуми үсеш төрендәге төркемнәрдә мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыруга финанс чыгымнары нормативы, елына бер тәрбияләнүчегә, сумнарда													
			биш көнлек эш атнасы									алты көнлек эш атнасы				
			көненә эш сәгатьләре саны									көненә эш сәгатьләре саны				
			3	4	5	6	7	9	10,5	12	24	9	10,5	12	14	24
Гомуми үсеш төрендәге төркемнәр (шул исәптән төрле яшьтәгеләр)	өч яшькә кадәр	шәһәр/шәһәр округы	18487	23101	27713	32327	34782	44010	53236	57848	108594	53236	62462	67076	80916	131660
		авыл	19506	24412	29317	34223	36679	46652	56462	61368	115324	56462	66273	71177	85894	139849
	өч яшьтән зуррак	шәһәр/шәһәр округы	19812	24425	24425	29039	35495	40109	44722	49336	58560	49336	53948	58560	67788	67788
		авыл	20915	25821	25821	30726	37475	42503	47407	52312	62122	52312	57217	62122	71931	71931
Мәктәпкәчә гаилә төркемнәре	барлык яшьтәгеләр өчен	шәһәр/шәһәр округы	0	0	0	0	30179	37099	41713	46326	50939	41713	48633	53245	60165	60165
		авыл	0	0	0	0	31900	39378	44283	49188	54094	44283	51641	56545	63903	63903

2. Компенсацияләү төрендәге төркемнәрдә мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыруга финанс чыгымнары нормативлары

Тәрбияләнүчеләр категориясе	Тәрбияләнүчеләрнең яшь ягыннан составы	Җирлек/шәһәр округы	Компенсацияләү төрендәге төркемнәрдә мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыруга финанс чыгымнары нормативы, елына бер тәрбияләнүчегә, сумнарда													
			биш көнлек эш атнасы									алты көнлек эш атнасы				
			көненә эш сәгатьләре саны									көненә эш сәгатьләре саны				
			3	4	5	6	7	9	10,5	12	24	9	10,5	12	14	24
Сөйләмнәре нык бозылган балалар	өч яшькә кадәр	шәһәр/шәһәр округы	57214	73923	93837	110544	146744	169194	185231	201267	329560	188439	207682	226926	252584	380877
		авыл	60963	78802	100085	117926	156721	180808	198010	215214	352850	201452	222098	242742	270269	407902
	өч яшьтән зуррак	шәһәр/шәһәр округы	39821	50488	61154	71818	94161	106990	116612	126233	139063	119820	129441	142270	158307	158307
		авыл	42345	53738	65130	76521	100467	114230	124552	134875	148639	127993	138316	152079	169284	169284
Начар күрүче балалар, амблиопияле, кылый күзле балалар	өч яшькә кадәр	шәһәр/шәһәр округы	57214	73923	93837	110544	146744	169194	185231	201267	329560	188439	207682	226926	252584	380877
		авыл	60963	78802	100085	117926	156721	180808	198010	215214	352850	201452	222098	242742	270269	407902
	өч яшьтән зуррак	шәһәр/шәһәр округы	39821	50488	61154	71818	94161	106990	116612	126233	139063	119820	129441	142270	158307	158307
		авыл	42345	53738	65130	76521	100467	114230	124552	134875	148639	127993	138316	152079	169284	169284
Психик үсешләрендә тоткарлыклар булган балалар; акылга җиңелчә зәгыйфь балалар	өч яшькә кадәр	шәһәр/шәһәр округы	57214	73923	93837	110544	146744	169194	185231	201267	329560	188439	207682	226926	252584	380877
		авыл	60963	78802	100085	117926	156721	180808	198010	215214	352850	201452	222098	242742	270269	407902
	өч яшьтән зуррак	шәһәр/шәһәр округы	39821	50488	61154	71818	94161	106990	116612	126233	139063	119820	129441	142270	158307	158307
		авыл	42345	53738	65130	76521	100467	114230	124552	134875	148639	127993	138316	152079	169284	169284
Акылга зәгыйфьлеге уртача, көчле булган балалар	өч яшьтән зуррак	шәһәр/шәһәр округы	49424	61154	76088	87816	117358	133394	143016	155846	171882	146223	162260	175089	194332	194332
		авыл	52609	65130	81091	93608	125271	142476	152798	166562	183766	156239	173443	187206	207851	207851
Ишетмәүче балалар	өч яшькә кадәр	шәһәр/шәһәр округы	57214	73923	93837	110544	146744	169194	185231	201268	329560	188439	207682	226926	252584	380877
		авыл	60963	78802	100085	117926	156721	180808	198010	215214	352850	201452	222098	242742	270269	407902
	өч яшьтән зуррак	шәһәр/шәһәр округы	61156	77866	97781	114487	150686	173138	189175	205210	227663	192381	211626	230870	256528	256528
		авыл	65134	82974	104258	122098	160893	184978	202183	219387	243472	205623	226269	246914	274440	274440
Күрмәүче балалар	өч яшькә кадәр	шәһәр/шәһәр округы	57214	73923	93837	110544	146744	169194	185231	201267	329560	188439	207682	226926	252584	380877
		авыл	60963	78802	100085	117926	156721	180808	198010	215214	352850	201452	222098	242742	270269	407902
	өч яшьтән зуррак	шәһәр/шәһәр округы	61156	77866	97781	114487	150686	173138	189175	205210	227663	192381	211626	230870	256528	256528
		авыл	65134	82974	104258	122098	160893	184978	202183	219387	243472	205623	226269	246914	274440	274440
Начар ишетүче балалар	өч яшькә кадәр	шәһәр/шәһәр округы	57214	73923	93837	110544	146744	169194	185231	201267	329560	188439	207682	226926	252584	380877
		авыл	60963	78802	100085	117926	156721	180808	198010	215214	352850	201452	222098	242742	270269	407902
	өч яшьтән зуррак	шәһәр/шәһәр округы	49424	61154	76088	87816	117358	133394	143015	155846	171882	146223	162260	175089	194332	194332
		авыл	52609	65130	81091	93608	125271	142476	152798	166562	183766	156239	173443	187206	207851	207851
Терәк-хәрәкәт аппараты бозылган балалар	өч яшькә кадәр	шәһәр/шәһәр округы	57214	73923	93837	110544	146744	169194	185231	201267	329560	188439	207682	226926	252584	380877
		авыл	60963	78802	100085	117926	156721	180808	198010	215214	352850	201452	222098	242742	270269	407902
	өч яшьтән зуррак	шәһәр/шәһәр округы	49424	61154	76088	87816	117358	133394	143015	155846	171882	146223	162260	175089	194332	194332
		авыл	52609	65130	81091	93608	125271	142476	152798	166562	183766	156239	173443	187206	207851	207851
Аутистик спектр җитешсезлекләре булган балалар	өч яшьтән зуррак	шәһәр/шәһәр округы	71818	93150	114479	135810	180535	206191	225437	244679	398631	228643	251096	276752	305619	305619
		авыл	76521	99306	122090	144874	192807	220332	240979	261624	289149	244419	268505	296032	326998	326998
Катлаулы кимчелекләр булган балалар (физик һәм (яисә) психик үсешләрендә ике яки аннан күбрәк җитешсезлек булган балалар)	өч яшькә кадәр	шәһәр/шәһәр округы	67874	89206	97707	131867	176592	202250	221492	240736	394687	224700	247151	272809	301676	455627
		авыл	72349	95134	117918	140702	188635	216160	236807	257452	422611	240247	264332	291860	322828	487987
	өч яшьтән зуррак	шәһәр/шәһәр округы	71818	93150	114479	135810	180535	206191	225437	244679	398631	228643	251096	276752	305619	305619
		авыл	76521	99306	122090	144874	192807	220332	240979	261624	289149	244419	268505	296032	326998	326998
Сөйләмнәрендә фонетик-фонематик җитешсезлекләр булган балалар	өч яшьтән зуррак	шәһәр/шәһәр округы	34484	44441	51189	61144	80821	90443	100065	106480	116101	100065	109687	119309	132139	132139
		авыл	36646	47284	54482	65120	86211	96533	106856	113737	124059	106856	117178	127500	141264	141264

3. Катнаш төрдәге төркемнәрдә мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыруга финанс чыгымнары нормативлары

Тәрбияләнүчеләр категориясе	Тәрбияләнүчеләрнең яшь ягыннан составы	Җирлек/шәһәр округы	Катнаш төрдәге төркемнәрдә мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыруга финанс чыгымнары нормативы, елына бер тәрбияләнүчегә, сумнарда													
			биш көнлек эш атнасы									алты көнлек эш атнасы				
			көненә эш сәгатьләре саны									көненә эш сәгатьләре саны				
			3	4	5	6	7	9	10,5	12	24	9	10,5	12	14	24
Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар	өч яшькә кадәр	шәһәр/шәһәр округы	46917	56194	60832	65472	78598	92513	101789	111068	185281	101789	115706	124982	138898	217749
		авыл	49040	58868	63779	68693	82600	97339	107166	116993	195609	107167	121906	131733	146474	230002
Ишетмәүче, күрмәүче, терәк-хәрәкәт аппараты бозылган, акылга зәгыйфьлеге уртача, көчле булган, аутистик спектр җитешсезлекләре яисә катлаулы кимчелекләре булган балалар	өч яшьтән зуррак	шәһәр/шәһәр округы	51639	60917	65555	70194	83320	97235	106511	115790	125066	106511	120427	129704	143620	222472
		авыл	54042	63868	68783	73696	87601	102342	112168	121996	131822	112168	126911	136735	151477	235006
Начар күрүче һәм (яисә) амблиопияле һәм (яисә) кылый күзле, сөйләмнәре нык бозылган начар ишетүче яки акылга зәгыйфьлеге җиңелчә булган балалар	өч яшьтән зуррак	шәһәр/шәһәр округы	39268	43906	48546	53184	55781	65057	74335	78973	88249	74335	83612	88249	102165	153188
		авыл	41396	46311	51222	56135	58889	68714	78542	83456	93282	78542	88368	93282	108023	162071
Психик үсешләрендә тоткарлык булган балалар	өч яшьтән зуррак	шәһәр/шәһәр округы	32810	37449	42087	46726	53637	58275	67552	72190	76829	67551	72192	81468	90743	137129
		авыл	34663	39577	44490	49403	56724	61638	71464	76378	81292	71464	76378	86206	96031	145167

4. Сәламәтләндерү төрендәге төркемнәрдә мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыруга финанс чыгымнары нормативлары

Тәрбияләнүчеләр категориясе	Тәрбияләнүчеләрнең яшь ягыннан составы	Җирлек/шәһәр округы	Сәламәтләндерү төрендәге төркемнәрдә мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыруга финанс чыгымнары нормативы, елына бер тәрбияләнүчегә, сумнарда													
			биш көнлек эш атнасы									алты көнлек эш атнасы				
			көненә эш сәгатьләре саны									көненә эш сәгатьләре саны				
			3	4	5	6	7	9	10,5	12	24	9	10,5	12	14	24
Туберкулез интоксикациясе булган балалар	өч яшькә кадәр	шәһәр/шәһәр округы	35878	46545	57211	67874	90217	103046	112669	122290	199266	115876	125498	138327	154364	231339
		авыл	38172	49565	60957	72349	96295	110058	120380	130704	213283	123821	134144	147906	165111	247691
	өч яшьтән зуррак	шәһәр/шәһәр округы	29161	35203	44452	50495	64351	73973	80387	86803	96424	80388	90009	96424	106046	106046
		авыл	30958	37406	47298	53744	68596	78918	85800	92681	103004	85800	96122	103004	113326	113326
Еш авыручы балалар һәм махсус сәламәтләндерү чаралары комплексы таләп ителә торган балаларның башка категорияләре	өч яшькә кадәр	шәһәр/шәһәр округы	35878	46545	57211	67874	90218	103046	112669	122290	199266	115876	125498	138327	154364	231339
		авыл	38172	49565	60957	72349	96295	110058	120380	130703	213283	123821	134144	147906	165111	247691
	өч яшьтән зуррак	шәһәр/шәһәр округы	29161	35203	44452	50495	64351	73973	80387	86803	96424	80388	90009	96424	106046	106046
		авыл	30958	37406	47298	53744	68596	78918	85800	92681	103004	85800	96122	103004	113326	113326

5. Аз комплектлы мәгариф оешмаларында мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыруга финанс чыгымнары нормативлары

Төркемнәрнең төре	Тәрбияләнүчеләрнең яшь ягыннан составы	Аз комплектлы мәгариф оешмаларында мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыруга финанс чыгымнары нормативы, елына бер төркемгә, сумнарда													
		биш көнлек эш атнасы									алты көнлек эш атнасы				
		көненә эш сәгатьләре саны									көненә эш сәгатьләре саны				
		3	4	5	6	7	9	10,5	12	24	9	10,5	12	14	24
Гомуми үсеш төрендәге төркемнәр (шул исәптән төрле яшьтәгеләр)	өч яшькә кадәр	146301	183090	219878	256665	275092	349894	423470	460257	864926	423470	497047	533835	644198	1048866
	өч яшьтән зуррак	194097	243146	243146	292198	359675	409951	459002	508053	606155	508053	557104	606155	704256	704256

«2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасында мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыра торган муниципаль мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында»
Татарстан Республикасы Законына
2 нче кушымта

2025 ел план чорына Татарстан Республикасында мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыра торган муниципаль мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү
НОРМАТИВЛАРЫ

1. Гомуми үсеш төрендәге төркемнәрдә мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыруга финанс чыгымнары нормативлары

Төркемнәрнең төре	Тәрбияләнүчеләрнең яшь ягыннан составы	Җирлек/шәһәр округы	Гомуми үсеш төрендәге төркемнәрдә мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыруга финанс чыгымнары нормативы, елына бер тәрбияләнүчегә, сумнарда													
			биш көнлек эш атнасы									алты көнлек эш атнасы				
			көненә эш сәгатьләре саны									көненә эш сәгатьләре саны				
			3	4	5	6	7	9	10,5	12	24	9	10,5	12	14	24
Гомуми үсеш төрендәге төркемнәр (шул исәптән төрле яшьтәгеләр)	өч яшькә кадәр	шәһәр/шәһәр округы	18487	23101	27713	32327	34782	44010	53236	57848	108594	53236	62462	67076	80916	131660
		авыл	19506	24412	29317	34223	36679	46652	56462	61368	115324	56462	66273	71177	85894	139849
	өч яшьтән зуррак	шәһәр/шәһәр округы	19812	24425	24425	29039	35495	40109	44722	49336	58560	49336	53948	58560	67788	67788
		авыл	20915	25821	25821	30726	37475	42503	47407	52312	62122	52312	57217	62122	71931	71931
Мәктәпкәчә гаилә төркемнәре	барлык яшьтәгеләр өчен	шәһәр/шәһәр округы	0	0	0	0	30179	37099	41713	46326	50939	41713	48633	53245	60165	60165
		авыл	0	0	0	0	31900	39378	44283	49188	54094	44283	51641	56545	63903	63903

2. Компенсацияләү төрендәге төркемнәрдә мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыруга финанс чыгымнары нормативлары

Тәрбияләнүчеләр категориясе	Тәрбияләнүчеләрнең яшь ягыннан составы	Җирлек/шәһәр округы	Компенсацияләү төрендәге төркемнәрдә мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыруга финанс чыгымнары нормативы, елына бер тәрбияләнүчегә, сумнарда													
			биш көнлек эш атнасы									алты көнлек эш атнасы				
			көненә эш сәгатьләре саны									көненә эш сәгатьләре саны				
			3	4	5	6	7	9	10,5	12	24	9	10,5	12	14	24
Сөйләмнәре нык бозылган балалар	өч яшькә кадәр	шәһәр/шәһәр округы	57214	73923	93837	110544	146744	169194	185231	201267	329560	188439	207682	226926	252584	380877
		авыл	60963	78802	100085	117926	156721	180808	198010	215214	352850	201452	222098	242742	270269	407902
	өч яшьтән зуррак	шәһәр/шәһәр округы	39821	50488	61154	71818	94161	106990	116612	126233	139063	119820	129441	142270	158307	158307
		авыл	42345	53738	65130	76521	100467	114230	124552	134875	148639	127993	138316	152079	169284	169284
Начар күрүче балалар, амблиопияле, кылый күзле балалар	өч яшькә кадәр	шәһәр/шәһәр округы	57214	73923	93837	110544	146744	169194	185231	201267	329560	188439	207682	226926	252584	380877
		авыл	60963	78802	100085	117926	156721	180808	198010	215214	352850	201452	222098	242742	270269	407902
	өч яшьтән зуррак	шәһәр/шәһәр округы	39821	50488	61154	71818	94161	106990	116612	126233	139063	119820	129441	142270	158307	158307
		авыл	42345	53738	65130	76521	100467	114230	124552	134875	148639	127993	138316	152079	169284	169284
Психик үсешләрендә тоткарлыклар булган балалар; акылга җиңелчә зәгыйфь балалар	өч яшькә кадәр	шәһәр/шәһәр округы	57214	73923	93837	110544	146744	169194	185231	201267	329560	188439	207682	226926	252584	380877
		авыл	60963	78802	100085	117926	156721	180808	198010	215214	352850	201452	222098	242742	270269	407902
	өч яшьтән зуррак	шәһәр/шәһәр округы	39821	50488	61154	71818	94161	106990	116612	126233	139063	119820	129441	142270	158307	158307
		авыл	42345	53738	65130	76521	100467	114230	124552	134875	148639	127993	138316	152079	169284	169284
Акылга зәгыйфьлеге уртача, көчле булган балалар	өч яшьтән зуррак	шәһәр/шәһәр округы	49424	61154	76088	87816	117358	133394	143016	155846	171882	146223	162260	175089	194332	194332
		авыл	52609	65130	81091	93608	125271	142476	152798	166562	183766	156239	173443	187206	207851	207851
Ишетмәүче балалар	өч яшькә кадәр	шәһәр/шәһәр округы	57214	73923	93837	110544	146744	169194	185231	201268	329560	188439	207682	226926	252584	380877
		авыл	60963	78802	100085	117926	156721	180808	198010	215214	352850	201452	222098	242742	270269	407902
	өч яшьтән зуррак	шәһәр/шәһәр округы	61156	77866	97781	114487	150686	173138	189175	205210	227663	192381	211626	230870	256528	256528
		авыл	65134	82974	104258	122098	160893	184978	202183	219387	243472	205623	226269	246914	274440	274440
Күрмәүче балалар	өч яшькә кадәр	шәһәр/шәһәр округы	57214	73923	93837	110544	146744	169194	185231	201267	329560	188439	207682	226926	252584	380877
		авыл	60963	78802	100085	117926	156721	180808	198010	215214	352850	201452	222098	242742	270269	407902
	өч яшьтән зуррак	шәһәр/шәһәр округы	61156	77866	97781	114487	150686	173138	189175	205210	227663	192381	211626	230870	256528	256528
		авыл	65134	82974	104258	122098	160893	184978	202183	219387	243472	205623	226269	246914	274440	274440
Начар ишетүче балалар	өч яшькә кадәр	шәһәр/шәһәр округы	57214	73923	93837	110544	146744	169194	185231	201267	329560	188439	207682	226926	252584	380877
		авыл	60963	78802	100085	117926	156721	180808	198010	215214	352850	201452	222098	242742	270269	407902
	өч яшьтән зуррак	шәһәр/шәһәр округы	49424	61154	76088	87816	117358	133394	143015	155846	171882	146223	162260	175089	194332	194332
		авыл	52609	65130	81091	93608	125271	142476	152798	166562	183766	156239	173443	187206	207851	207851
Терәк-хәрәкәт аппараты бозылган балалар	өч яшькә кадәр	шәһәр/шәһәр округы	57214	73923	93837	110544	146744	169194	185231	201267	329560	188439	207682	226926	252584	380877
		авыл	60963	78802	100085	117926	156721	180808	198010	215214	352850	201452	222098	242742	270269	407902
	өч яшьтән зуррак	шәһәр/шәһәр округы	49424	61154	76088	87816	117358	133394	143015	155846	171882	146223	162260	175089	194332	194332
		авыл	52609	65130	81091	93608	125271	142476	152798	166562	183766	156239	173443	187206	207851	207851
Аутистик спектр җитешсезлекләре булган балалар	өч яшьтән зуррак	шәһәр/шәһәр округы	71818	93150	114479	135810	180535	206191	225437	244679	398631	228643	251096	276752	305619	305619
		авыл	76521	99306	122090	144874	192807	220332	240979	261624	289149	244419	268505	296032	326998	326998
Катлаулы кимчелекләр булган балалар (физик һәм (яисә) психик үсешләрендә ике яки аннан күбрәк җитешсезлек булган балалар)	өч яшькә кадәр	шәһәр/шәһәр округы	67874	89206	97707	131867	176592	202250	221492	240736	394687	224700	247151	272809	301676	455627
		авыл	72349	95134	117918	140702	188635	216160	236807	257452	422611	240247	264332	291860	322828	487987
	өч яшьтән зуррак	шәһәр/шәһәр округы	71818	93150	114479	135810	180535	206191	225437	244679	398631	228643	251096	276752	305619	305619
		авыл	76521	99306	122090	144874	192807	220332	240979	261624	289149	244419	268505	296032	326998	326998
Сөйләмнәрендә фонетик-фонематик җитешсезлекләр булган балалар	өч яшьтән зуррак	шәһәр/шәһәр округы	34484	44441	51189	61144	80821	90443	100065	106480	116101	100065	109687	119309	132139	132139
		авыл	36646	47284	54482	65120	86211	96533	106856	113737	124059	106856	117178	127500	141264	141264

3. Катнаш төрдәге төркемнәрдә мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыруга финанс чыгымнары нормативлары

Тәрбияләнүчеләр категориясе	Тәрбияләнүчеләрнең яшь ягыннан составы	Җирлек/шәһәр округы	Катнаш төрдәге төркемнәрдә мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыруга финанс чыгымнары нормативы, елына бер тәрбияләнүчегә, сумнарда													
			биш көнлек эш атнасы									алты көнлек эш атнасы				
			көненә эш сәгатьләре саны									көненә эш сәгатьләре саны				
			3	4	5	6	7	9	10,5	12	24	9	10,5	12	14	24
Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар	өч яшькә кадәр	шәһәр/шәһәр округы	46917	56194	60832	65472	78598	92513	101789	111068	185281	101789	115706	124982	138898	217749
2) 13 статьяның 6 өлешендәге беренче җөмләсендә «дәүләт гарантияләре» сүзләреннән соң «, әгәр федераль законнарда башкасы каралмаган булса,» сүзләрен өстәргә, икенче җөмләне төшереп калдырырга;

3) 13^1 статьяның 3 өлешендәге беренче җөмләсендә «дәүләт гарантияләре» сүзләреннән соң «, әгәр федераль законнарда башкасы каралмаган булса,» сүзләрен өстәргә, икенче җөмләне төшереп калдырырга.

5 статья

Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 18 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 5, № 12 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш); 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 28 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 48 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле 6^3 өлеш өстәп, үзгәреш кертергә:

«6^3. Комиссиядә даими (штат) нигездә эшләүче хәлиткеч тавыш хокукына ия комиссия әгъзасы, әгәр «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда, коррупциягә каршы көрәш максатларындагы башка федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны һәм мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә аны җайга салу таләпләрен үтәмәү һәм бу законнарда билгеләнгән бурычларны башкармау «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 3 – 6 өлешләрендә каралган тәртиптә аннан тормаган хәлләрнең нәтиҗәсе итеп танылган очракта, мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәгән, шулай ук мондый бурычларны башкармаган өчен җаваплылыктан азат ителә.».

6 статья

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 24 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 17 статьяда:

а) 5 өлештә «чаралары күрелмәү» сүзләреннән соң «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш,» сүзләрен өстәргә;

б) 7 өлештә «чаралары күрелмәү» сүзләреннән соң «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш,» сүзләрен өстәргә;

2) 18 статьяда:

а) 7 өлештә «дөрес булмаган яисә» сүзләрен төшереп калдырырга, «белешмәләр тапшыру» сүзләреннән соң «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш,» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле 7^1 өлеш өстәргә:

«7^1. Муниципаль хезмәткәр тарафыннан әлеге статьяның 7 өлешендә күрсәтелгән белә торып дөрес булмаган белешмәләр тапшыру муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән җибәрүгә китерерлек хокук бозу булып санала.»;

3) 33 статьяга түбәндәге эчтәлекле 1^1 өлеш өстәргә:

«1^1. Муниципаль хезмәткәр, әгәр «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законда, коррупциягә каршы көрәш максатларындагы башка федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны һәм мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә аны җайга салу таләпләрен үтәмәү һәм бу законнарда билгеләнгән бурычларны башкармау «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның 13 статьясындагы 3 – 6 өлешләрендә каралган тәртиптә аннан тормаган хәлләрнең нәтиҗәсе итеп танылган очракта, мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәгән, шулай ук мондый бурычларны башкармаган өчен җаваплылыктан азат ителә.».

7 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2023 ел, 28 сентябрь, № 86-ТРЗ

Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2023 елның 14 сентябрендә кабул ителде

1 статья

Татарстан Республикасы Җир кодексына кушымтаның 2 пунктындагы 5 пунктчасына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 60 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) беренче абзацта «торак урыннарының гомуми мәйданы кимендә биш мең квадрат метр булган» сүзләрен «гомуми мәйданы кимендә өч мең квадрат метр булган» сүзләренә алмаштырырга;

2) алтынчы абзацта «50 миллион сум» сүзләрен «30 миллион сум» сүзләренә алмаштырырга.

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2023 ел, 29 сентябрь, № 87-ТРЗ

«Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 7 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2023 елның 14 сентябрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2022 елның 25 февралендәге 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясындагы 1 пунктының «е» пунктчасына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2022, № 17 (I өлеш), № 77 (I өлеш), «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон яисә «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән, гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм карап тоту эшләрен башкаруга граждан-хокук шартнамәләренә таянып» сүзләрен «гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм карап тоту эшләрен башкаруга «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон яисә «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән граждан-хокук шартнамәләренә, «Концессия килешүләре турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында каралган объектларга карата төзелгән концессия килешүләренә, «Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында каралган объектларга карата төзелгән дәүләти-хосусый партнерлык турындагы, муниципаль-хосусый партнерлык хакындагы килешүләргә таянып» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2 статья

Әлеге Закон 2023 елның 1 октябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2023 ел, 29 сентябрь, № 88-ТРЗ

«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 13 статьясына һәм «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2023 елның 14 сентябрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законының 13 статьясына (2020 елның 19 ноябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 12; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2020, № 87 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 20 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Салым ташламалары инвестиция проектын гамәлгә ашыру турындагы шартнамә төзегән инвестиция эшчәнлеге субъектларына инвестиция проекты чыгымнарын каплау срогына, әмма инвестицияләр башлану вакытыннан алып җиде елдан да артык булмаган вакытка, әлеге статьяда башкасы билгеләнмәгән булса, бирелергә мөмкин.»;

2) түбәндәге эчтәлекле 1^1 өлеш өстәргә:

«1^1. Машина төзелеше тармагында инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы инвестиция эшчәнлеге субъектларына салым ташламалары инвестицияләр башлану вакытыннан алып 13 елга кадәр бирелергә мөмкин.»;

3) түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәргә:

«3. Татарстан Республикасы территориясендә проект куәте елына кимендә 500 мең тонна этилен булган җитештерү куәтләрендә пиролиз ысулы белән этилен җитештерүне башкаручы, капиталь салулар күләме кимендә 10 миллиард сум булган инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы инвестиция эшчәнлеге субъектларына салым ташламалары җиде елга кадәр бирелергә мөмкин.».

2 статья

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш); 2015, № 6 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 1 – 2, № 6 (III өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 50 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш); 2023, № 48 (I өлеш), 56 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 21 пункт өстәргә:

«21) Татарстан Республикасы территориясендә проект куәте елына кимендә 500 мең тонна этилен булган җитештерү куәтләрендә пиролиз ысулы белән этилен җитештерүне башкаручы, «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә төзелгән инвестиция проектын гамәлгә ашыру турындагы шартнамәгә ярашлы рәвештә инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы оешмалар – яңа төзелгән яисә капиталь салулар күләме кимендә 10 миллиард сум булган инвестиция проектын гамәлгә ашыру максатларында сатып алынган һәм 2022 елның 1 гыйнварыннан да иртәрәк файдалануга тапшырылмаган мөлкәткә карата.

Салым ташламасы, күрсәтелгән мөлкәт салым салу объекты буларак исәпкә алынган айдан соң килүче айның 1 числосыннан башлап, инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында шартнамәнең гамәлдә булу срогы беткәнче, әмма җиде елдан да артмаган срокка бирелә.

Оешма салым ташламасын салым чоры йомгаклары буенча түбәндәге шартларны үтәгәндә әлеге пункт нигезендә кулланырга хокуклы:

бизнес-планда каралган шартлар үтәлү;

хисап елында Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына оешмалар табышына салымның, физик затлар керемнәренә салымның, оешмалар мөлкәтенә салымның, транспорт салымының, җир салымының кушма суммалары һәм тиешле пеняләр һәм штрафлар суммалары (салымнар буенча недоимка, пеняләр һәм штрафлар буенча бурычлар суммаларының һәм оешмалар табышына салым һәм оешмалар мөлкәтенә салым өлешендә артык түләнгән яисә артык түләтелгән салымнар (пеняләр, штрафлар) суммаларының үзгәрешләре йогынтысын исәпкә алмыйча), хисап елына кадәрге өч ел өчен булып (йә, оешма төзелгән вакытны исәпкә алып һәм әлеге пунктның җиденче абзацын исәпкә алып, хисап елына кадәрге башка чор өчен, ләкин ике елдан күбрәк түгел), тиешле тармак буенча тулаем Россия Федерациясендә Россия Федерациясе субъектларының берләштерелгән бюджетларына салымнардан кергән акчалар суммасы үзгәрү күрсәткеченә, ул салымнар һәм җыемнар өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек буенча вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан раслана торган форма буенча тапшырыла торган тиешле ел өчен икътисадый эшчәнлекнең төп төрләре буенча Россия Федерациясе бюджет системасына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре исәпләп бирелү һәм түләнү турындагы хисап белешмәләренә нигезләнеп билгеләнә, һәр ел йомгаклары буенча индексацияләнгән тиешле салымнарның (пеняләрнең, штрафларның) (салым ташламаларыннан файдалану өлешендә чагыштырма шартларда) оешма тарафыннан чынбарлыкта түләнгән суммаларының уртача арифметик күрсәткеченнән ким булмаган күләмдә түләнү;

Татарстан Республикасы финанс органына оешмага исәпләп бирелгән һәм аның тарафыннан түләнгән салымнар суммалары, салымнар буенча недоимка, пеняләр һәм штрафлар буенча бурычлар суммалары һәм артык түләнгән яисә артык түләтелгән салымнар (пеняләр, штрафлар) суммалары, бирелгән салым ташламаларының ташламалар киселешендәге суммалары турында белешмәләрне салым органы тарафыннан бирүгә ризалык бирелгән булу.

Яңа төзелгән оешма салым ташламасын салым буенча беренче салым чоры йомгаклары буенча, шушы пунктның бишенче абзацында билгеләнгән шартны үтәмичә, әлеге пункт нигезендә кулланырга хокуклы.

Салым ташламасын әлеге пункт нигезендә куллануның шушы пунктның бишенче абзацында билгеләнгән шартының оешма тарафыннан үтәлүен бәяләү тәртибе һәм методикасы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана. Мондый тәртиптә тиешле тармак буенча тулаем Россия Федерациясендә Россия Федерациясе субъектларының берләштерелгән бюджетларына салымнардан кергән акчалар суммасы үзгәрү күрсәткечен исәпләп чыгару методикасы булырга тиеш.»;

2) 2^1 өлешнең 2 пунктында «технопаркларның (индустриаль паркларның)» сүзләрен «технопаркларның, индустриаль паркларның (сәнәгать паркларының)» сүзләренә алмаштырырга.

3 статья

1. Әлеге Закон рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

2. «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законының 13 статьясындагы 3 өлеше (әлеге Закон редакциясендә) һәм «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 1 өлешенең 21 пункты (әлеге Закон редакциясендә) нигезләмәләренең гамәлдә булуы 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2023 ел, 29 сентябрь, № 89-ТРЗ

Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2023 елның 14 сентябрендә кабул ителде

1 статья

Татарстан Республикасы Сайлау кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 5, № 12 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш); 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 28 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 48 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяда:

а) 3 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Бу чакта әлеге статьяның 2 өлешендә каралган тавыш бирү көненә кадәр биш ай алдан башлана һәм күрсәтелгән тавыш бирү көненнән соң бер ай узгач тәмамлана торган чорда муниципаль берәмлек башлыгын вакытыннан алда сайлаулар күрсәтелгән тавыш бирү көненнән башка көнне уздырыла алмый һәм, әлеге статьяның 4 – 7 өлешләрендә каралган нигезләмәләрне исәпкә алып, шушы көнгә билгеләнә.»;

б) 3^1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Бу чакта әлеге статьяның 2 өлешендә каралган тавыш бирү көненә кадәр биш ай алдан башлана һәм күрсәтелгән тавыш бирү көненнән соң бер ай узгач тәмамлана торган чорда шундый сайлаулар күрсәтелгән тавыш бирү көненнән башка көнне уздырыла алмый һәм, әлеге статьяның 4 – 7 өлешләрендә каралган нигезләмәләрне исәпкә алып, шушы көнгә билгеләнә.»;

2) 6^1 статьяда:

а) исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6^1 статья. **Югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл, хәрби хәл режимы кертелгәндә сайлаулар үткәрү»;**

б) түбәндәге эчтәлекле 5 – 11 өлешләр өстәргә:

«5. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә, «Хәрби хәл турында» 2002 елның 30 гыйнварындагы 1-ФКЗ номерлы Федераль конституциячел закон нигезендә хәрби хәл кертелгәндә, Татарстан Республикасы Рәисе тавыш бирү көненә кадәр иң күбе 130 көн һәм кимендә 90 көн кала Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенә Татарстан Республикасы территориясендә сайлаулар үткәрү турында тәкъдим җибәрергә хокуклы.

6. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе әлеге статьяның 5 өлешендә каралган тәкъдим кергән көннән алып биш көннән дә соңга калмыйча оборона өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру, норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы һәм иминлек тәэмин итү өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы белән консультацияләр үткәрә.

7. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә әлеге статьяның 6 өлешендә каралган консультацияләр нәтиҗәсе буенча һәм күрсәтелгән өлештә билгеләнгән срок дәвамында Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тиешле сайлауларны билгеләү (үткәрү) турында (шул исәптән сайлау гамәлләре срокларын кыскарту мөмкинлеге белән) яисә Татарстан Республикасы Рәисенең аларны үткәрү хакындагы тәкъдимен кире кагу турында карар кабул итә.

8. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе, әлеге статьяның 7 өлешендә һәм әлеге Кодексның 6 статьясындагы 5 өлешендә билгеләнгән срокларны истә тотып, Татарстан Республикасы территориясендә сайлауларны билгеләү (үткәрү) турында карар кабул итә, бу хакта кичекмәстән Россия Федерациясе Президентына хәбәр итә. Бу чакта сайлаулар тиешле дәрәҗәдәге комиссия тарафыннан оештырыла һәм үткәрелә.

9. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә, әлеге статьяның 6 өлешендә каралган консультацияләр нәтиҗәсе буенча Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе Татарстан Республикасы Рәисенең сайлаулар үткәрү турындагы тәкъдимен кире каккан очракта, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе бу хакта кичекмәстән Татарстан Республикасы Рәисенә хәбәр итә.

10. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә, әлеге статьяның 8 өлеше нигезендә сайлаулар билгеләнгәннән соң аларны оештыру һәм үткәрү Россия Федерациясе гражданнарының гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч тудырса, сайлаулар Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе карары белән кичектерелә, ул бу хакта кичекмәстән Россия Федерациясе Президентына хәбәр итә.

11. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә, сайлауларны кичектереп тору өчен нигез булган хәлләр бетерелгән очракта, сайлау кампаниясе Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе карары белән әлеге статьяның 5 – 8 өлешләрендә каралган тәртиптә яңадан башланырга мөмкин.»;

3) 10 статьяның 13 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон, әлеге Кодекс нигезләмәләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр, шулай ук аларның вазыйфаи затлары комиссияләргә вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда ярдәм күрсәтергә тиеш, аерым алганда, түләүсез нигездә кирәкле биналар (биналарны территория, округ һәм участок комиссияләренә биргәндә – биналардан файдалану чыгымнары һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү комиссияләр тарафыннан капланмый һәм түләнми), шул исәптән участок комиссияләренең сайлау документларын (күрсәтелгән документларны архивка тапшырганчы йә законда билгеләнгән саклау вакытлары узып юкка чыгарганчы) һәм технологик җиһазларын саклау өчен, бирергә, бирелә торган биналарны һәм күрсәтелгән документларны һәм җиһазларны сак белән тәэмин итәргә, шулай ук түләүсез нигездә транспорт чаралары, элемтә чаралары, техник җиһазлар бирергә тиеш.»;

4) 12 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле 1^1 өлеш өстәргә:

«1^1. Казан шәһәре территориясендә җирле үзидарә органнарына сайлаулар әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы комиссия вәкаләтләре Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе белән килештерелгән карары нигезендә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә йөкләтелергә мөмкин.»;

б) түбәндәге эчтәлекле 9^1 өлеш өстәргә:

«9^1. Казан шәһәре территориясендә җирле үзидарә органнарына сайлаулар әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы комиссия вәкаләтләрен үтәгән очракта Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әлеге Кодексның 108 статьясында каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.»;

5) 16 статьяда:

а) 6 өлештә «6^1 өлеше» сүзләрен «6^1 яисә 6^{1-1} өлеше» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 6^{1-1} өлеш өстәргә:

«6^{1-1}. Әлеге Кодексның 76 статьясындагы 19 өлешендә һәм (яисә) 77 статьясындагы 19 өлешендә каралган тавыш бирүне һәм (яисә) әлеге Кодексның 76^1 статьясындагы 17 өлешендә каралган вакытыннан алда тавыш бирүне тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан махсус участок комиссияләре төзелергә мөмкин. Мондый комиссияләр шул исәптән шик белдерелгән һәм гаепләнүче затларны сак астында тоту урыннары хезмәткәрләре арасыннан төзелергә мөмкин, йә мондый участок комиссияләренең вәкаләтләре башка участок комиссияләренә йөкләнә ала.»;

6) 17 статьяның 9 өлешенә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Әлеге Кодексның 16 статьясындагы 6^{1-1} өлеше нигезендә төзелгән участок комиссиясе рәисе вазыйфага комиссиянең хәлиткеч тавыш хокуклы әгъзалары арасыннан билгеләнә һәм ул вазыйфадан Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары белән азат ителә.»;

7) 21 статьяның 1^2 өлешендә «яисә түләүле граждан-хокукый» сүзләрен төшереп калдырырга;

8) 22 статьяда:

а) 5 өлешнең беренче җөмләдә «һәр участок комиссиясенә, территория комиссиясенә һәм округ комиссиясенә» сүзләреннән соң «(округ сайлау комиссиясе вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә йөкләү очрагыннан тыш)» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле 9 өлеш өстәргә:

«9. Фото һәм (яисә) видеога төшерү әлеге Кодекс нигезендә аны башкарырга хокукы булган затлар тарафыннан тавыш бирү сере бозылмаслык һәм сайлаучыларның ихтыяр күрсәтүен контрольдә тоту мөмкинлеге булмаслык итеп, шулай ук сайлаучылар исемлекләренә кертелгән һәм федераль законда билгеләнгән тәртиптә конфиденциаль мәгълүматка кертелгән мәгълүматы булган башка документлардагы персональ белешмәләрнең конфиденциальлеге сакланырлык итеп гамәлгә ашырылырга тиеш.»;

9) 27 статьяда:

а) 4 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Шик белдерелгән һәм гаепләнүче затларны сак астында тоту урыннарында әлеге Кодексның 76 статьясындагы 19 өлешендә һәм (яисә) 77 статьясындагы 19 өлешендә каралган тавыш бирүне һәм (яисә) әлеге Кодексның 76^1 статьясындагы 17 өлешендә каралган вакытыннан алда тавыш бирүне үткәрү өчен сайлау участоклары Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан төзелергә мөмкин.»;

б) түбәндәге эчтәлекле 4^1 өлеш өстәргә:

«4^1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына сайлауларда Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары белән актив сайлау хокукына ия булган Татарстан Республикасыннан читтәге территорияләрдәге сайлаучылар тавыш бирү өчен сайлау участоклары төзелергә мөмкин. [illegible] «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә [illegible] Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе билгеләгән тәртиптә [illegible] Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.»;

10) 29 статьяда:

а) 17^1 өлешнең икенче абзацында «таныклана» сүзеннән соң «, яисә мондый күчермә электрон рәвештә әзерләнергә мөмкин, бу очракта ул участок комиссиясе рәисенең, секретареның электрон имзасы белән имзалана» сүзләрен өстәргә;

б) 17^1 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

в) түбәндәге эчтәлекле 17^2 өлеш өстәргә:

«17^2. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә, әлеге Кодексның 76 статьясындагы 19 өлешендә һәм (яисә) 77 статьясындагы 19 өлешендә каралган тавыш бирүне һәм (яисә) әлеге Кодексның 76^1 статьясындагы 17 өлешендә каралган вакытыннан алда тавыш бирүне үткәргән очракта, сайлаучылар исемлекләре Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе билгеләгән тәртиптә төзелә.»;

11) 47 статьяга түбәндәге эчтәлекле 13 өлеш өстәргә:

«13. Теркәлгән кандидат хөкем ителгән очракта, мондый кандидат хөкем ителгән көннән соң килгән көннән җирле вакыт буенча 18 сәгатеннән дә соңга калмыйча бу хөкем ителү турында үзен теркәгән сайлау комиссиясенә язмача белешмә тапшырырга тиеш. Кандидатның әлеге хөкем ителүе турында белешмәләр шулай ук әлеге Кодексның 49 статьясындагы 2 өлеше нигезендә кандидат исеменнән эш итү хокукы булган затлар тарафыннан да тапшырылырга мөмкин.»;

12) 52 статьяның 5 өлешендә «Ышанычлы затларның вәкаләтләре» сүзләреннән соң «, шул исәптән әлеге Кодексның 21 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгәннәре,» сүзләрен өстәргә, «бергә» сүзеннән соң «агитация чоры тәмамлану белән бер үк вакытта, шулай ук вакытыннан алда» сүзләрен өстәргә;

13) 73 статьяның 2 өлешендә «зал булырга» сүзләреннән соң «, шулай ук, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып, күзәтүчеләр һәм әлеге Кодексның 21 статьясындагы 1^2 өлешендә күрсәтелгән массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре өчен урыннар билгеләнергә» сүзләрен өстәргә;

14) 75 статьяда:

а) 16 өлештә «кимрәк була алмый» сүзләреннән соң «, моңа әлеге Кодексның 76^2 статьясы нигезендә дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүне үткәрү очрагы керми» сүзләрен өстәргә, түбәндәге эчтәлекле яңа өченче җөмлә өстәргә: «Бу очракта тапшырыла торган бюллетеньнәр саны, федераль законда башкасы билгеләнмәгән булса, сайлауларны оештыручы комиссия карары белән билгеләнә.»;

б) түбәндәге эчтәлекле 21^1 өлеш өстәргә:

«21^1. Әлеге Кодексның 76 статьясындагы 19 өлешендә һәм (яисә) 77 статьясындагы 19 өлешендә каралган тавыш бирүне һәм (яисә) әлеге Кодексның 76^1 статьясындагы 17 өлешендә каралган вакытыннан алда тавыш бирүне үткәргән очракта һәм әлеге Кодексның 27 статьясындагы 4^1 өлешендә күрсәтелгән сайлау участокларында тавыш бирүне үткәргәндә сайлау документларын, бюллетеньнәрне дә кертеп, турыдан-туры участок комиссиясе тарафыннан әзерләү рөхсәт ителә, бу чакта әлеге статьяның 3 өлеше нигезләмәләре кулланылмаска мөмкин. Сайлау документларын әзерләү турында карар, бюллетеньнәрнең кирәкле булган тиражын һәм аларны әзерләү срокларын күрсәтеп, югарырак комиссия белән килештереп, участок комиссиясе тарафыннан кабул ителә.»;

15) 76 статьяда:

а) 2^1 өлештә «сайлау участокларында» сүзләреннән соң «, шулай ук әлеге статьяның 19 өлешендә һәм (яисә) әлеге Кодексның 77 статьясындагы 19 өлешендә каралган тавыш бирүне һәм (яисә) әлеге Кодексның 76^1 статьясындагы 17 өлешендә каралган вакытыннан алда тавыш бирүне үткәрү өчен төзелгән сайлау участокларында» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле 19 өлеш өстәргә:

«19. Тиешле сайлау округыннан читтә һәм тиешле сайлау округы чикләрендә булган шик белдерелгән һәм гаепләнүче затларны сак астында тоту урыннарындагы сайлаучыларның сайлаулар үткәргәндә тавыш бирүе, «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә аның карары белән гамәлгә ашырыла.»;

16) 76^1 статьяга түбәндәге эчтәлекле 17 өлеш өстәргә:

«17. Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе карары белән, тиешле сайлау округыннан читтә һәм тиешле сайлау округы чикләрендә булган шик белдерелгән һәм гаепләнүче затларны сак астында тоту урыннарындагы сайлаучыларның сайлаулар үткәргәндә вакытыннан алда тавыш бирүе, «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда гамәлгә ашырыла.»;

17) 77 статьяда:

а) 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Күрсәтелгән реестр «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе билгеләгән тәртиптә электрон рәвештә төзелергә мөмкин.»;

б) түбәндәге эчтәлекле 19 өлеш өстәргә:

«19. Тиешле сайлау округыннан читтә һәм тиешле сайлау округы чикләрендә булган шик белдерелгән һәм гаепләнүче затларны сак астында тоту урыннарындагы сайлаучыларның сайлаулар үткәргәндә тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирүе, «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә аның карары белән гамәлгә ашырыла.»;

18) 79 статьяга түбәндәге эчтәлекле 30^1 өлеш өстәргә:

«30^1. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә, әлеге Кодексның 76 статьясындагы 19 өлешендә һәм (яисә) 77 статьясындагы 19 өлешендә каралган тавыш бирүне һәм (яисә) әлеге Кодексның 76^1 статьясындагы 17 өлешендә каралган вакытыннан алда тавыш бирүне үткәргән очракта, тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссиясе беркетмәсен төзү (мондый тавыш бирү йомгаклары турындагы белешмәләрне формалаштыру) үзенчәлекләре Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.»;

19) 80 статьяга түбәндәге эчтәлекле 16 өлеш өстәргә:

«16. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә, әлеге Кодексның 76 статьясындагы 19 өлешендә һәм (яисә) 77 статьясындагы 19 өлешендә каралган тавыш бирүне һәм (яисә) әлеге Кодексның 761 статьясындагы 17 өлешендә каралган вакытыннан алда тавыш бирүне үткәргән очракта, югарырак комиссия тарафыннан, әлеге Кодексның 76 статьясындагы 19 өлешендә һәм (яисә) 77 статьясындагы 19 өлешендә каралган тавыш бирү һәм (яисә) әлеге Кодексның 76^1 статьясындагы 17 өлешендә каралган вакытыннан алда тавыш бирү йомгаклары турында белешмәләрне исәпкә алып, җыелма таблица һәм тавыш бирү йомгаклары турында (сайлаулар нәтиҗәләре хакында) беркетмә төзү үзенчәлекләре Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.»;

20) 81 статьяның 1 өлешендә түбәндәге эчтәлекле яңа икенче җөмлә өстәргә: «Әлеге Кодексның 76 статьясындагы 19 өлешендә һәм (яисә) 77 статьясындагы 19 өлешендә каралган тавыш бирүне һәм (яисә) әлеге Кодексның 76^1 статьясындагы 17 өлешендә каралган вакытыннан алда тавыш бирүне үткәргән очракта сайлаулар нәтиҗәләре турында беркетмәгә, җыелма таблицага мондый тавыш бирү белешмәләре кертелергә тиеш.»;

21) 89 статьяга түбәндәге эчтәлекле 8 өлеш өстәргә:

«8. Гражданнарның һәм юридик затларның ирекле иганәләренең минималь күләме тулаем Россия Федерациясе буенча җан башына яшәү минимумы күләменең 3 процентын тәшкил итә.»;

22) 101 статьяның 1 өлешендә «кандидатларның ышанычлы затларына, сәяси партияләргә,» сүзләрен төшереп калдырырга;

23) 102 статьяның 2 өлешендә «сентябрьнең икенче якшәмбесендә, ә чираттагы чакырылыш Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлауларны уздыру елында – шушы сайлауларда тавыш бирү көнендә» сүзләрен «әлеге Кодексның 6 статьясындагы 2 өлешендә каралган тавыш бирү көнендә» сүзләренә алмаштырырга, түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Бу чакта әлеге Кодексның 6 статьясындагы 2 өлешендә каралган тавыш бирү көненә кадәр биш ай алдан башлана һәм күрсәтелгән тавыш бирү көненнән соң бер ай узгач тәмамлана торган чорда мондый кабат сайлаулар күрсәтелгән тавыш бирү көненнән башка көнне уздырыла алмый һәм, әлеге Кодексның 6 статьясындагы 4 – 7 өлешләрендә каралган нигезләмәләрне исәпкә алып, күрсәтелгән көнгә билгеләнә.»;

24) 104 статьяның 2 өлешендә «сентябрьнең икенче якшәмбесенә, ә чираттагы чакырылыш Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлауларны уздыру елында – шушы сайлауларда тавыш бирү көненә» сүзләрен «әлеге Кодексның 6 статьясындагы 2 өлешендә каралган тавыш бирү көненә» сүзләренә алмаштырырга, түбәндәге эчтәлекле яңа өченче җөмлә өстәргә: «Бу чакта әлеге Кодексның 6 статьясындагы 2 өлешендә каралган тавыш бирү көненә кадәр биш ай алдан башлана һәм күрсәтелгән тавыш бирү көненнән соң бер ай узгач тәмамлана торган чорда мондый өстәмә сайлаулар күрсәтелгән тавыш бирү көненнән башка көнне уздырыла алмый һәм, әлеге Кодексның 6 статьясындагы 4 – 7 өлешләрендә каралган нигезләмәләрне исәпкә алып, күрсәтелгән көнгә билгеләнә.»;

25) 104^6 статьяга түбәндәге эчтәлекле 6 өлеш өстәргә:

«6. Гражданнарның һәм юридик затларның ирекле иганәләренең минималь күләме тулаем Россия Федерациясе буенча җан башына яшәү минимумы күләменең 3 процентын тәшкил итә.»;

26) 104^{14} статьяның 1 өлешендә «кандидатларның ышанычлы затларына,» сүзләрен төшереп калдырырга;

27) 104^{16} статьяның 2 өлешендә «сентябрьнең икенче якшәмбесендә, ә чираттагы чакырылыш Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлауларны уздыру елында – шушы сайлауларда тавыш бирү көнендә» сүзләрен «әлеге Кодексның 6 статьясындагы 2 өлешендә каралган тавыш бирү көнендә» сүзләренә алмаштырырга, түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Бу чакта әлеге Кодексның 6 статьясындагы 2 өлешендә каралган тавыш бирү көненә кадәр биш ай алдан башлана һәм күрсәтелгән тавыш бирү көненнән соң бер ай узгач тәмамлана торган чорда мондый кабат сайлаулар күрсәтелгән тавыш бирү көненнән башка көнне уздырыла алмый һәм, әлеге Кодексның 6 статьясындагы 4 – 7 өлешләрендә каралган нигезләмәләрне исәпкә алып, күрсәтелгән көнгә билгеләнә.»;

28) 106 статьяга түбәндәге эчтәлекле 9 өлеш өстәргә:

«9. Гражданнарның һәм юридик затларның ирекле иганәләренең минималь күләме тулаем Россия Федерациясе буенча җан башына яшәү минимумы күләменең 3 процентын тәшкил итә.»;

29) 108 статьяда:

а) беренче абзацта «Җирле үзидарә органнарына» сүзләрен «1. Җирле үзидарә органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 2 өлеш өстәргә:

«2. Муниципаль берәмлек территориясендә берничә территория комиссиясе төзелгән булса, әлеге муниципаль берәмлектә җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләү һәм үткәрү вәкаләтләре Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары белән территория комиссияләренең берәрсенә йөкләнә.»;

30) 108^1 статьяның 5 өлешендәге икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль берәмлек территориясендә берничә территория комиссиясе төзелгән булса, округ комиссияләренең вәкаләтләре Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары белән күрсәтелгән территория комиссияләренә йөкләнергә мөмкин.»;

31) 121 статьяның 1 өлешендә «кандидатларның, сайлау берләшмәләренең ышанычлы затларына,» сүзләрен төшереп калдырырга;

32) 123 статьяның 2 өлешендә «сентябрьнең икенче якшәмбесенә, ә чираттагы чакырылыш Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлауларны уздыру елында – шушы сайлауларда тавыш бирү көненә» сүзләрен «әлеге Кодексның 6 статьясындагы 2 өлешендә каралган тавыш бирү көненә» сүзләренә алмаштырырга, түбәндәге эчтәлекле яңа өченче җөмлә өстәргә: «Бу чакта әлеге Кодексның 6 статьясындагы 2 өлешендә каралган тавыш бирү көненә кадәр биш ай алдан башлана һәм күрсәтелгән тавыш бирү көненнән соң бер ай узгач тәмамлана торган чорда мондый өстәмә сайлаулар күрсәтелгән тавыш бирү көненнән башка көнне уздырыла алмый һәм, әлеге Кодексның 6 статьясындагы 4 – 7 өлешләрендә каралган нигезләмәләрне исәпкә алып, күрсәтелгән көнгә билгеләнә.»;

33) 128 статьяның 1 өлешендә «кандидатларның, сайлау берләшмәләренең ышанычлы затларына,» сүзләрен төшереп калдырырга;

34) 129 статьяның 2 өлешендә «сентябрьнең икенче якшәмбесендә, ә чираттагы чакырылыш Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлауларны уздыру елында – шушы сайлауларда тавыш бирү көнендә» сүзләрен «әлеге Кодексның 6 статьясындагы 2 өлешендә каралган тавыш бирү көнендә» сүзләренә алмаштырырга, түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Бу вакытта әлеге Кодексның 6 статьясындагы 2 өлешендә каралган тавыш бирү көненә кадәр биш ай алдан башлана һәм күрсәтелгән тавыш бирү көненнән соң бер ай узгач тәмамлана торган чорда мондый кабат сайлаулар күрсәтелгән тавыш бирү көненнән башка көнне уздырыла алмый һәм, әлеге Кодексның 6 статьясындагы 4 – 7 өлешләрендә каралган нигезләмәләрне исәпкә алып, күрсәтелгән көнгә билгеләнә.».

2 статья

«Татарстан Республикасы референдумы турында» 2003 елның 9 августындагы 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 8; 2005, № 3 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 10 статьяның 1 пунктында «Россия Федерациясе» сүзләре алдыннан «Әлеге Законның 15^1 статьясындагы 7 һәм 10 пунктларында каралган очраклардан тыш,» сүзләрен өстәргә;

2) 15^1 статьяда:

а) исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15^1 статья. **Югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл, хәрби хәл режимы кертелгәндә референдум үткәрү»;**

б) түбәндәге эчтәлекле 4 – 10 пунктлар өстәргә:

«4. Федераль закон нигезендә, «Хәрби хәл турында» 2002 елның 30 гыйнварындагы 1-ФКЗ номерлы Федераль конституциячел закон нигезендә хәрби хәл кертелгәндә, Татарстан Республикасы Рәисе тавыш бирү көненә кадәр иң күбе 130 көн һәм кимендә 90 көн кала Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенә Татарстан Республикасы территориясендә референдум үткәрү турында тәкъдим җибәрергә хокуклы.

5. Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе әлеге статьяның 4 пунктында каралган тәкъдим кергән көннән алып биш көннән дә соңга калмыйча оборона өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру, норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы һәм иминлек тәэмин итү өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы белән консультацияләр үткәрә.

6. Федераль закон нигезендә әлеге статьяның 5 пунктында каралган консультацияләр нәтиҗәсе буенча һәм күрсәтелгән пунктта билгеләнгән срок эчендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе референдум билгеләү (үткәрү) турында яисә Татарстан Республикасы Рәисенең аны үткәрү хакындагы тәкъдимен кире кагу турында карар кабул итә.

7. Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе, әлеге статьяның 6 пунктында билгеләнгән срокларны истә тотып, Татарстан Республикасы территориясендә референдум билгеләү (үткәрү) турында карар кабул итә, бу хакта кичекмәстән Россия Федерациясе Президентына хәбәр итә. Бу чакта референдум тиешле дәрәҗәдәге комиссия тарафыннан оештырыла һәм үткәрелә.

8. Федераль закон нигезендә, әлеге статьяның 5 пунктында каралган консультацияләр нәтиҗәсе буенча Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе Татарстан Республикасы Рәисенең референдум үткәрү турындагы тәкъдимен кире каккан очракта, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе бу хакта кичекмәстән Татарстан Республикасы Рәисенә хәбәр итә.

9. Федераль закон нигезендә, әлеге статьяның 7 пункты нигезендә референдум билгеләнгәннән соң аны оештыру һәм үткәрү Россия Федерациясе гражданнарының гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч тудырса, референдумны үткәрү Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе карары белән кичектерелә, ул бу хакта кичекмәстән Россия Федерациясе Президентына хәбәр итә.

10. Федераль закон нигезендә, референдумны кичектереп тору өчен нигез булган хәлләр бетерелгән очракта, референдум кампаниясе Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе карары белән әлеге статьяның 4 – 7 пунктларында каралган тәртиптә яңадан башланырга мөмкин.»;

3) 16 статьяның 11 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Федераль закон, әлеге Закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр, шулай ук аларның вазыйфаи затлары комиссияләргә вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда ярдәм күрсәтергә тиеш, аерым алганда, түләүсез нигездә кирәкле биналар (биналарны территория һәм участок комиссияләренә биргәндә – биналардан файдалану чыгымнары һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү комиссияләр тарафыннан капланмый һәм түләнми), шул исәптән участок комиссияләренең референдум документларын (күрсәтелгән документларны архивка тапшырганчы йә законда билгеләнгән саклау вакытлары узып юкка чыгарганчы) һәм технологик җиһазларын саклау өчен, бирергә, бирелә торган биналарны һәм күрсәтелгән документларны һәм җиһазларны сак белән тәэмин итәргә, шулай ук түләүсез нигездә транспорт чаралары, элемтә чаралары, техник җиһазлар бирергә тиеш.»;

4) 17 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3. Әлеге Законның 50 статьясындагы 18 пунктында һәм (яисә) 51 статьясындагы 19 пунктында каралган тавыш бирүне тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан махсус участок комиссияләре төзелергә мөмкин. Мондый комиссияләр шул исәптән шик белдерелгән һәм гаепләнүче затларны сак астында тоту урыннары хезмәткәрләре арасыннан төзелергә мөмкин, йә мондый участок комиссияләренең вәкаләтләре башка участок комиссияләренә йөкләнә ала.»;

5) 22 статьяда:

а) 1^2 пунктта «яисә түләүле граждан-хокукый шартнамәсе» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 14 пункт өстәргә:

«14. Фото һәм (яисә) видеога төшерү әлеге Закон нигезендә аны башкарырга хокукы булган затлар тарафыннан тавыш бирү сере бозылмаслык һәм референдумда катнашучыларның ихтыяр күрсәтүен контрольдә тоту мөмкинлеге булмаслык итеп, шулай ук референдумда катнашучылар исемлекләренә кертелгән һәм федераль законда билгеләнгән тәртиптә конфиденциаль мәгълүматка кертелгән мәгълүматы булган башка документлардагы персональ белешмәләрнең конфиденциальлеге сакланырлык итеп гамәлгә ашырылырга тиеш.»;

6) 26 статьяда:

а) 13^1 пунктның икенче абзацында «таныклана» сүзеннән соң «, яисә мондый күчермә электрон рәвештә әзерләнергә мөмкин, бу очракта ул участок комиссиясе рәисенең, секретареның электрон имзасы белән имзалана» сүзләрен өстәргә;

б) 15^1 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

в) түбәндәге эчтәлекле 15^2 пункт өстәргә:

«15^2. Федераль закон нигезендә, әлеге Законның 50 статьясындагы 18 пунктында һәм (яисә) 51 статьясындагы 19 пунктында каралган тавыш бирүне үткәргән очракта, референдумда катнашучылар исемлекләре Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе билгеләгән тәртиптә төзелә.»;

7) 27 статьяның 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Шик белдерелгән һәм гаепләнүче затларны сак астында тоту урыннарында әлеге Законның 50 статьясындагы 18 пунктында һәм (яисә) 51 статьясындагы 19 пунктында каралган тавыш бирүне үткәрү өчен референдум участоклары Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан төзелергә мөмкин.»;

8) 47 статьяның 2 пунктында «башка урыннар булырга» сүзләреннән соң «, шулай ук Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе билгеләгән таләпләрне исәпкә алып, күзәтүчеләр һәм әлеге Законның 22 статьясындагы 1^2 пунктында күрсәтелгән массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре өчен урыннар билгеләнергә» сүзләрен өстәргә;

9) 49 статьяда:

а) 9 пунктта «кимрәк була алмый» сүзләреннән соң «, моңа әлеге Законның 50^2 статьясы нигезендә дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүне үткәрү очрагы керми» сүзләрен өстәргә, түбәндәге эчтәлекле яңа өченче җөмлә өстәргә: «Бу очракта тапшырыла торган бюллетеньнәр саны, федераль законда башкасы билгеләнмәгән булса, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары белән билгеләнә.»;

б) түбәндәге эчтәлекле 12^1 пункт өстәргә:

«12^1. Әлеге Законның 50 статьясындагы 18 пунктында һәм (яисә) 51 статьясындагы 19 пунктында каралган тавыш бирүне үткәргән очракта референдум документларын, бюллетеньнәрне дә кертеп, турыдан-туры участок комиссиясе тарафыннан әзерләү рөхсәт ителә, бу чакта әлеге статьяның 3 пункты нигезләмәләре кулланылмаска мөмкин. Референдум документларын әзерләү турында карар, бюллетеньнәрнең кирәкле тиражын һәм аларны әзерләү срокларын күрсәтеп, югарырак комиссия белән килештереп, участок комиссиясе тарафыннан кабул ителә.»;

10) 50 статьяда:

а) 2^1 пунктта «референдум участокларында» сүзләреннән соң «, шулай ук әлеге статьяның 18 пунктында һәм (яисә) әлеге Законның 51 статьясындагы 19 пунктында каралган тавыш бирүне үткәрү өчен төзелгән референдум участокларында,» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле 18 пункт өстәргә:

«18. Референдум округыннан читтә һәм референдум округы чикләрендә булган шик белдерелгән һәм гаепләнүче затларны сак астында тоту урыннарындагы референдумда катнашучыларның референдум үткәргәндә тавыш бирүе, Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе

тарафыннан билгеләнгән тәртиптә аның карары белән гамәлгә ашырыла.»;

11) 51 статьяда:

а) 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Федераль закон нигезендә күрсәтелгән реестр Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә электрон рәвештә төзелергә мөмкин.»;

б) түбәндәге эчтәлекле 19 пункт өстәргә:

«19. Референдум округыннан читтә һәм референдум округы чикләрендә булган шик белдерелгән һәм гаепләнүче затларны сак астында тоту урыннарындагы референдумда катнашучыларның референдум үткәргәндә тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирүе, Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә аның карары белән гамәлгә ашырыла.»;

12) 53 статьяга түбәндәге эчтәлекле 29^1 пункт өстәргә:

«29^1. Федераль закон нигезендә, әлеге Законның 50 статьясындагы 18 пунктында һәм (яисә) 51 статьясындагы 19 пунктында каралган тавыш бирүне үткәргән очракта, тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссиясе беркетмәсен төзү (мондый тавыш бирү йомгаклары турындагы белешмәләрне формалаштыру) үзенчәлекләре Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.»;

13) 54 статьяга түбәндәге эчтәлекле 10 пункт өстәргә:

«10. Әлеге Законның 50 статьясындагы 18 пунктында һәм (яисә) 51 статьясындагы 19 пунктында каралган тавыш бирүне үткәргән очракта югарырак комиссия тарафыннан, әлеге Законның 50 статьясындагы 18 пунктында һәм (яисә) 51 статьясындагы 19 пунктында каралган тавыш бирү йомгаклары турында белешмәләрне исәпкә алып, тавыш бирү йомгаклары турында (референдум нәтиҗәләре турында) җыелма таблица һәм беркетмә төзү үзенчәлекләре Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.»;

14) 55 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле тугызынчы абзац өстәргә:

«Әлеге Законның 50 статьясындагы 18 пунктында һәм (яисә) 51 статьясындагы 19 пунктында каралган тавыш бирүне үткәргән очракта референдум нәтиҗәләре турында беркетмәгә, җыелма таблицага мондый тавыш бирү белешмәләре кертелергә тиеш.».

3 статья

«Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 5 (I өлеш); 2005, № 3 (I өлеш); 2008, № 5 (I өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8, № 12; 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 18^1 статьяда:

а) исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18^1 статья. **Югары әзерлек һәм гадәттән тыш хәл, хәрби хәл режимы кертелгәндә референдум үткәрү»;**

б) түбәндәге эчтәлекле 4 – 10 пунктлар өстәргә:

«4. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә, «Хәрби хәл турында» 2002 елның 30 гыйнварындагы 1-ФКЗ номерлы Федераль конституциячел закон нигезендә хәрби хәл кертелгәндә, Татарстан Республикасы Рәисе тавыш бирү көненә кадәр иң күбе 130 көн һәм кимендә 90 көн кала Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенә референдум үткәрү турында тәкъдим җибәрергә хокуклы.

5. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе әлеге статьяның 4 пунктында каралган тәкъдим кергән көннән алып биш көннән дә соңга калмыйча оборона өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру, норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы һәм иминлек тәэмин итү өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы белән консультацияләр үткәрә.

6. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә әлеге статьяның 5 пунктында каралган консультацияләр нәтиҗәсе буенча һәм күрсәтелгән пунктта билгеләнгән срок эчендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе референдум билгеләү (үткәрү) турында яисә Татарстан Республикасы Рәисенең аны үткәрү хакындагы тәкъдимен кире кагу турында карар кабул итә.

7. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе, әлеге статьяның 6 пунктында билгеләнгән срокларны исәптә тотып, референдум билгеләү (үткәрү) турында карар кабул итә, бу хакта кичекмәстән Россия Федерациясе Президентына хәбәр итә. Бу чакта референдум тиешле дәрәҗәдәге комиссия тарафыннан оештырыла һәм үткәрелә.

8. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә, әлеге статьяның 5 пунктында каралган консультацияләр нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе Татарстан Республикасы Рәисенең референдум үткәрү турындагы тәкъдимен кире каккан очракта, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе бу хакта кичекмәстән Татарстан Республикасы Рәисенә хәбәр итә.

9. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә, әлеге статьяның 7 пункты нигезендә референдум билгеләнгәннән соң аны оештыру һәм үткәрү Россия Федерациясе гражданнарының гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч тудырса, референдумны үткәрү Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе карары белән кичектерелә, ул бу хакта кичекмәстән Россия Федерациясе Президентына хәбәр итә.

10. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә, референдумны кичектереп тору өчен нигез булган хәлләр бетерелгән очракта, референдум кампаниясе Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе карары белән әлеге статьяның 4 – 7 пунктларында каралган тәртиптә яңадан башланырга мөмкин.»;

2) 19 статьяда:

а) 11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон, әлеге Закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр, шулай ук аларның вазыйфаи затлары комиссияләргә вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда ярдәм күрсәтергә тиеш, аерым алганда, түләүсез нигездә кирәкле биналар (биналарны территория һәм участок комиссияләренә биргәндә – биналардан файдалану чыгымнары һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү комиссияләр тарафыннан капланмый һәм түләнми), шул исәптән участок комиссияләренең референдум документларын (күрсәтелгән документларны архивка тапшырганчы йә законда билгеләнгән саклау вакытлары узып юкка чыгарганчы) һәм технологик җиһазларын саклау өчен, бирергә, бирелә торган биналарны һәм күрсәтелгән документларны һәм җиһазларны сак белән тәэмин итәргә, шулай ук түләүсез нигездә транспорт чаралары, элемтә чаралары, техник җиһазлар бирергә тиеш.»;

б) түбәндәге эчтәлекле 16 – 18 пунктлар өстәргә:

«16. Казан шәһәре территориясендә референдум әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы комиссия вәкаләтләре Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе белән килештерелгән карары нигезендә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә йөкләнергә мөмкин.

17. Казан шәһәре территориясендә референдум әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы комиссия вәкаләтләрен үтәгән очракта, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әлеге Законның 20 статьясында каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

18. Әлеге Законның 52 статьясындагы 15 пунктында һәм (яисә) 53 статьясындагы 19 пунктында каралган тавыш бирүне һәм (яисә) әлеге Законның 52^1 статьясындагы 17 пунктында каралган вакытыннан алда тавыш бирүне тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан махсус участок комиссияләре төзелергә мөмкин. Мондый комиссияләр шул исәптән шик белдерелгән һәм гаепләнүче затларны сак астында тоту урыннары хезмәткәрләре арасыннан төзелергә мөмкин, йә мондый участок комиссияләренең вәкаләтләре башка участок комиссияләренә йөкләнергә мөмкин.»;

3) 20 статьяда:

а) беренче абзацта «Референдум» сүзен «1. Референдум» сүзенә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 2 пункт өстәргә:

«2. Муниципаль берәмлек территориясендә берничә территория комиссиясе төзелгән булса, бу муниципаль берәмлектә референдумны әзерләү һәм үткәрү вәкаләтләре Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары белән территория комиссияләренең берсенә йөкләнә.»;

4) 24 статьяда:

а) 1^2 пунктта «яисә түләүле граждан-хокукый шартнамә» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 14 пункт өстәргә:

«14. Фото һәм (яисә) видеога төшерү әлеге Закон нигезендә аны башкарырга хокукы булган затлар тарафыннан тавыш бирү сере бозылмаслык һәм референдумда катнашучыларның ихтыяр күрсәтүен контрольдә тоту мөмкинлеге булмаслык итеп, шулай ук референдумда катнашучылар исемлекләренә кертелгән һәм федераль законда билгеләнгән тәртиптә конфиденциаль дип классификацияләнгән мәгълүматны үз эченә алган документлардагы персональ мәгълүматларның сакланышын тәэмин иткән тәртиптә гамәлгә ашырылырга тиеш.»;

5) 25 статьяның 4 пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Әлеге Законның 19 статьясындагы 18 пункты нигезендә төзелгән участок комиссиясенең рәисе вазыйфага комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукы булган әгъзалары арасыннан билгеләнә куела һәм вазыйфадан Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары белән азат ителә.»;

6) 27 статьяда:

а) 14^1 пунктның икенче абзацында «таныклана» сүзеннән соң «, яисә мондый күчермә электрон рәвештә әзерләнергә мөмкин, бу очракта ул участок комиссиясе рәисенең, секретаренең электрон имзасы белән имзалана» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле 16^1 пункт өстәргә:

«16^1. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә, әлеге Законның 52 статьясындагы 15 пунктында һәм (яисә) 53 статьясындагы 19 пунктында каралган тавыш бирүне һәм (яисә) әлеге Законның 52^1 статьясындагы 17 пунктында каралган вакытыннан алда тавыш бирүне үткәргән очракта, референдумда катнашучылар исемлекләре Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе билгеләгән тәртиптә төзелә.»;

7) 28 статьяның 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Шик белдерелгән һәм гаепләнүче затларны сак астында тоту урыннарында әлеге Законның 52 статьясындагы 15 пунктында һәм (яисә) 53 статьясындагы 19 пунктында каралган тавыш бирүне һәм (яисә) әлеге Законның 52^1 статьясындагы 17 пунктында каралган вакытыннан алда тавыш бирүне үткәрү өчен референдум участоклары Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан төзелергә мөмкин.»;

8) 49 статьяның 2 пунктында «башка урыннар булырга» сүзләреннән соң «, шулай ук Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе билгеләгән таләпләрне исәпкә алып, күзәтүчеләр һәм әлеге Законның 24 статьясындагы 1^2 пунктында күрсәтелгән массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре өчен урыннар билгеләнергә» сүзләрен өстәргә;

9) 51 статьяда:

а) 8 пунктта «кимрәк була алмый» сүзләреннән соң «, моңа әлеге Законның 52^2 статьясы нигезендә дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүне үткәрү очрагы керми» сүзләрен өстәргә, түбәндәге эчтәлекле яңа бишенче җөмлә өстәргә: «Бу очракта тапшырыла торган бюллетеньнәр саны, федераль законда башкасы билгеләнмәгән булса, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары белән билгеләнә.»;

б) түбәндәге эчтәлекле 11^1 пункт өстәргә:

«11^1. Әлеге Законның 52 статьясындагы 15 пунктында һәм (яисә) 53 статьясындагы 19 пунктында каралган тавыш бирүне һәм (яисә) әлеге Законның 52^1 статьясындагы 17 пунктында каралган вакытыннан алда тавыш бирүне үткәргән очракта референдум документларын, бюллетеньнәрне дә кертеп, турыдан-туры участок комиссиясе тарафыннан әзерләү рөхсәт ителә, бу чакта әлеге статьяның 3 пункты нигезләмәләре кулланылмаска мөмкин. Референдум документларын әзерләү турында карар, бюллетеньнәрнең кирәкле тиражын һәм аларны әзерләү срокларын күрсәтеп, югарырак комиссия белән килештереп, участок комиссиясе тарафыннан кабул ителә.»;

10) 52 статьяда:

а) 2^1 пунктта «референдум участокларында» сүзләреннән соң «, шулай ук әлеге статьяның 15 пунктында һәм (яисә) әлеге Законның 53 статьясындагы 19 пунктында каралган тавыш бирүне һәм (яисә) әлеге Законның 52^1 статьясындагы 17 пунктында каралган вакытыннан алда тавыш бирүне үткәрү өчен төзелгән референдум участокларында,» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле 15 пункт өстәргә:

«15. Референдум округыннан читтә һәм референдум округы чикләрендә булган шик белдерелгән һәм гаепләнүче затларны сак астында тоту урыннарындагы референдумда катнашучыларның референдум үткәргәндә тавыш бирүе, «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә аның карары белән гамәлгә ашырыла.»;

11) 52^1 статьяга түбәндәге эчтәлекле 17 пункт өстәргә:

«17. Референдум округыннан читтә һәм референдум округы чикләрендә булган шик белдерелгән һәм гаепләнүче затларны сак астында тоту урыннарындагы референдумда катнашучыларның референдум үткәргәндә вакытыннан алда тавыш бирүе, «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм аларның референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда гамәлгә ашырыла.»;

12) 53 статьяда:

а) 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Күрсәтелгән реестр «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе билгеләгән тәртиптә электрон рәвештә төзелергә мөмкин.»;

б) түбәндәге эчтәлекле 19 пункт өстәргә:

«19. Референдум округыннан читтә һәм референдум округы чикләрендә булган шик белдерелгән һәм гаепләнүче затларны сак астында тоту урыннарындагы референдумда катнашучыларның референдум үткәргәндә тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирүе, «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә аның карары белән гамәлгә ашырыла.»;

13) 55 статьяга түбәндәге эчтәлекле 29^1 пункт өстәргә:

«29^1. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә, әлеге Законның 52 статьясындагы 15 пунктында һәм (яисә) 53 статьясындагы 19 пунктында каралган тавыш бирүне һәм (яисә) әлеге Законның 52^1 статьясындагы 17 пунктында каралган вакытыннан алда тавыш бирүне үткәргән очракта, тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссиясе беркетмәсен төзү (мондый тавыш бирү йомгаклары турындагы белешмәләрне формалаштыру) үзенчәлекләре Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.»;

14) 56 статьяның 6 пунктына түбәндәге эчтәлекле алтынчы абзац өстәргә:

«Әлеге Законның 52 статьясындагы 15 пунктында һәм (яисә) 53 статьясындагы 19 пунктында каралган тавыш бирүне һәм (яисә) әлеге Законның 52^1 статьясындагы 17 пунктында каралган вакытыннан алда тавыш бирүне үткәргән очракта референдум нәтиҗәләре турында беркетмәгә, җыелма таблицага мондый тавыш бирү белешмәләре кертелергә тиеш.».

4 статья

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 21 статьясындагы 5 өлешенең алтынчы абзацына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 5, № 6 (I өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 17 (I өлеш), № 24 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), «ул төзелгән көннән соң бер елдан да соңга калмыйча уздырылырга тиеш» сүзләрен «сайлаулар һәм референдумнар турындагы законнарда каралган срокларда уздырыла» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

5 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2023 ел, 29 сентябрь, № 90-ТРЗ

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2023 елның 14 сентябрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте турында» 2022 елның 23 декабрендәге 96-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2022, № 96 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) законнарда билгеләнгән очракларда хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарында Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне билгеләп кую, сайлау өчен күрсәтү, билгеләп куюны һәм сайлау өчен күрсәтүне килештерү;»;

2) 5 статьяда:

а) исемендә «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 өлештә:

4 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарын» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарын» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктның «б» пунктчасындагы дүртенче абзацында «федераль яки» сүзләрен «федераль милеккә, Россия Федерациясе субъектлары милкенә,» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) законнарда билгеләнгән очракларда хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарында Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне билгеләп кую, сайлау өчен күрсәтү, билгеләп куюны һәм сайлау өчен күрсәтүне килештерү;»;

в) 2 өлешнең беренче абзацында «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

3) 7 статьяда:

а) 4 өлештә «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең моңа вәкаләтле башка органнары» сүзләрен «моңа вәкаләтле республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

б) 5 өлешнең 2 пунктында «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга.

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2023 ел, 29 сентябрь, № 91-ТРЗ

Татарстан Республикасы Гаилә кодексына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2023 елның 14 сентябрендә кабул ителде

1 статья

Татарстан Республикасы Гаилә кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 9 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 5, № 7; 2014, № 4, № 6 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 60 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 20 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 13 статьяның 1 өлешенә «игълан ителүенә бәйле рәвештә» сүзләреннән соң «, шулай ук граждан хәле акты язмасына ир белән хатынның берәрсе җенесен үзгәртүе турында үзгәреш кертүгә бәйле рәвештә» сүзләрен өстәргә;

2) 79 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Мондый ярдәмнән баш тарткан һәм алимент түләү турында ир белән хатын арасында килешү булмаган очракта, матди мөмкинлеге булган ирдән йә хатыннан суд тәртибендә алимент түләүне таләп итү хокукына түбәндәгеләр ия:

1) хезмәткә сәләтсез ярдәмгә мохтаҗ ир йә хатын;

2) йөклелек чорында ир хатыны;

3) уртак бала туган көннән алып өч ел дәвамында фактта аны карап торучы ир йә хатын;

4) уртак инвалид баланы аңа унсигез яше тулганчы карап торучы яисә балачактан I төркем инвалид уртак баланы фактта карап торучы ярдәмгә мохтаҗ ир йә хатын.»;

3) 80 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Матди мөмкинлеге булган элеккеге ирдән йә хатыннан суд тәртибендә алимент түләүне таләп итү хокукына түбәндәгеләр ия:

1) никахта торганда барлыкка килгән йөклелек чорында элеккеге ир хатыны;

2) уртак бала туган көннән алып өч ел дәвамында фактта аны карап торучы элеккеге ир йә хатын;

3) уртак инвалид баланы аңа унсигез яше тулганчы фактта карап торучы яисә балачактан I төркем инвалид уртак баланы фактта карап торучы ярдәмгә мохтаҗ элеккеге ир йә хатын;

4) никах өзелгәнче яисә никах өзелү вакытыннан бер ел дәвамында хезмәткә сәләтсез булып калган ярдәмгә мохтаҗ элеккеге ир йә хатын;

5) никахлары өзелгәннән соң биш елдан соңрак булмаган вакыт эчендә пенсия яшенә җиткән ярдәмгә мохтаҗ элеккеге ир йә хатын, әгәр ир белән хатын озак вакыт никахта торса.»;

4) 116 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 14 пункт өстәргә:

«14) җенесен үзгәрткән затлар.»;

5) 134 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

«6) җенесен үзгәрткән затлар.».

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2023 ел, 29 сентябрь, № 92-ТРЗ

«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2023 елның 14 сентябрендә кабул ителде

1 статья

«Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; 2014, № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 3 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 24 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 2 өлешендә:

а) 15^2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15^2) Федераль законның 71^1 статьясындагы 6 өлеше нигезендә югары белем бирүнең уку-укыту программалары буенча Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән максатчан укыту турында шартнамә йөкләмәләрен үтәмәгән өчен штрафны түләү тәртибен, аның күләмен билгеләү һәм аны Татарстан Республикасы бюджетына күчерү тәртибен билгеләү;»;

б) 15^3 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

2) 11 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Инновацион эшчәнлек яңа дәреслекләрне һәм алар белән бергә комплектта эшләнгән укыту ярдәмлекләрен эшләүгә, апробацияләүгә һәм гамәлгә кертүгә, мәгариф системасын фәнни, укыту-методик яктан тәэмин итүне камилләштерүгә юнәлдерелгән һәм белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар һәм мәгариф өлкәсендә эшли торган бүтән оешмалар, шулай ук аларның берләшмәләре тарафыннан инновацион проектларны һәм программаларны башкару рәвешендә гамәлгә ашырыла. Мәгариф өлкәсендә инновацион эшчәнлекне гамәлгә ашырганда белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучыларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү, дәрәҗәсе һәм сыйфаты федераль дәүләт мәгариф стандарты, федераль дәүләт таләпләре, мәгариф стандарты белән билгеләнгән таләпләрдән түбән була алмаган белем бирү һәм аны алу тәэмин ителергә тиеш.»;

3) 20 статьяда:

а) 1 өлештә икенче җөмләне төшереп калдырырга;

б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Федераль законда каралган очракларда граждан һәм максатчан укытуга заказ бирүче белән берләттән максатчан укыту турында шартнамәнең яклары белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма була һәм граждан максатчан укыту хакында шартнамә нигезендә эшкә урнашачак оешма да булырга мөмкин.»;

в) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Максатчан укытуга заказ бирүче «Работа в России» халыкны эш белән тәэмин итү һәм хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендәге бердәм цифрлы платформада максатчан укыту турында шартнамә яисә шартнамәләр төзү турында тәкъдимнәр урнаштыра. Әлеге тәкъдимнәр булган мәгълүмат, федераль законнар белән файдалана алу чикләнгән мәгълүматтан тыш, һәркем файдалана ала торган мәгълүмат була.»;

г) түбәндәге эчтәлекле 3^1 өлеш өстәргә:

«3^1. Максатчан укыту турында шартнамә төзергә теләүче граждан урта һөнәри белем яисә югары белем бирүнең уку-укыту программасы буенча укуга кабул ителгәндә яисә турыдан-туры уку вакытында заявка бирергә мөмкин. Әлеге заявка укуга кабул ителгәндә кәгазь рәвешендә яисә электрон рәвештә бирелә, уку вакытында заявка кәгазь рәвешендә бирелә.»;

д) түбәндәге эчтәлекле 3^2 өлеш өстәргә:

«3^2. Урта һөнәри белем яисә югары белем бирүнең уку-укыту программасы буенча укуга кергәндә яисә уку вакытында граждан максатчан укыту турында шартнамәне бер максатчан укытуга заказ бирүче белән генә төзергә хокуклы.»;

е) түбәндәге эчтәлекле 3^3 өлеш өстәргә:

«3^3. Максатчан укыту турында шартнамә шартлары, аны төзү тәртибе һәм сроклары, граждан тарафыннан максатчан укыту турында шартнамә төзүгә заявка бирү тәртибе, максатчан укытуга заказ бирүче тарафыннан «Работа в России» халыкны эш белән тәэмин итү һәм хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендәге бердәм цифрлы платформада урнаштырыла торган белешмәләр Федераль закон нигезендә билгеләнә.»;

ж) 4 өлештә «йөкләмәләрне үтәмәгән» сүзләреннән соң «яисә максатчан укыту турында шартнамәне берьяклы тәртиптә өзгән» сүзләрен өстәргә, түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Гражданга максатчан укыту турында шартнамәдә каралган ярдәм чаралары күрсәтелмәгән очракта, граждан максатчан укыту турында шартнамәне вакытыннан алда өзәргә хокуклы.»;

з) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Максатчан укыту турында шартнамә төзегән граждан уку-укыту программасын үзләштерү һәм (яисә) максатчан укыту хакында шартнамәдә билгеләнгән срок дәвамында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру буенча максатчан укыту турында шартнамәдә каралган йөкләмәләрне үтәмәгән яисә максатчан укыту хакында шартнамәне берьяклы тәртиптә өзгән очракта, ул максатчан укытуга заказ бирүченең ярдәм чараларын күрсәтүгә бәйле чыгымнарын капларга тиеш.»;

и) 7 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Максатчан укыту турында нигезләмә, аңа шул исәптән максатчан укыту хакында шартнамәне төзү һәм өзү тәртибе, максатчан укытуга заказ бирүчеләр тарафыннан максатчан укыту турында шартнамә төзелә торган гражданнарга карата куелырга мөмкин булган таләпләр, хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру урынын билгеләү һәм үзгәртү шартлары, якларны максатчан укыту хакында шартнамә йөкләмәләрен үтәүдән азат итү тәртибе һәм нигезләре, максатчан укыту турында шартнамәнең яклары тарафыннан «Работа в России» халыкны эш белән тәэмин итү һәм хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендәге бердәм цифрлы платформада максатчан укыту хакында шартнамәне үтәмәү очраклары турындагы хәбәрнамәләрне урнаштыру тәртибе һәм сроклары, компенсацияне түләү тәртибе, чыгымнар күләмен билгеләү һәм аларны каплау тәртибе дә керә, максатчан укыту хакында шартнамәнең типлаштырылган рәвеше, максатчан укыту турында шартнамәне яисә шартнамәләрне төзү хакындагы тәкъдимнәрнең рәвеше, максатчан укыту турында шартнамә төзүгә заявканың рәвеше, максатчан укыту хакында шартнамә яисә шартнамәләр төзү турындагы тәкъдимнәрне «Работа в России» халыкны эш белән тәэмин итү һәм хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендәге бердәм цифрлы платформада урнаштыру тәртибе һәм сроклары, максатчан укыту хакында шартнамәне төзүгә ризалыкның эчтәлеге һәм аны дәүләт хезмәт күрсәтүләренең һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бердәм порталы аша бирү тәртибе Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.»;

к) 9 өлештә «яисә җирле үзидарә органы» сүзләрен «, җирле үзидарә органы яисә тиешле орган буйсынуындагы оешма» сүзләренә алмаштырырга.

2 статья

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 1 һәм 3 пунктларыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 һәм 3 пунктлары 2024 елның 1 маеннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2023 ел, 29 сентябрь, № 93-ТРЗ

КОТЛЫЙБЫЗ!

«Глобал Дата Консалтинг энд Сервисез» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең GDC директоры **Вагыйзов** Руслан Хәлим улына, «АйСиЭл – КПО ВС» акционер җәмгыяте финанс директоры – баш бухгалтеры **Шафранская** Наталья Валерьевнага, «Казан Экспо» конгресс-күргәзмә, мәдәни, тамаша-күңел ачу, спорт-массакүләм һәм социаль юнәлештәге чараларны үстерү һәм аларга булышлык итү үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасының маркетинг һәм реклама бүлеге маркетологы **Волина** Надежда Александровнага, «КАЗАН ЭКСПО» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең техник бүлеге башлыгы **Приешкин** Владимир Александровичка, «РИМЕРА-АЛНАС» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте җыю цехының участок мастеры **Гыйлаҗиев** Дамир Таһирҗан улына, «ЭНИКС» акционер җәмгыяте генераль директоры – баш конструкторы **Побежимов** Валерий Николаевичка, «Казан милли тикшеренү технология университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең «Союзхимпромпроект» проект институты проект баш инженеры **Хәкимов** Булат Рафис улына, «КАМАЗ-Автоспорт» коммерциячел булмаган партнерлыгы җитештерү цехының автомобильләрне төзекләндерү буенча слесаре **Мирный** Антон Валерьевичка **Татарстан Республикасы Рәисенең Рәхмәте** белдерелде.

***

Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен хезмәт ветераны **Идиятуллин** Рево Рамазан улы; радиоэлектроника сәнәгатен үстерүгә мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Казан приборлар төзү конструкторлык бюросы» акционер җәмгыяте 34 номерлы механика-җыю цехының авиация приборларын җыючы слесаре **Гайнуллин** Камил Шамил улы; һөнәри эшчәнлектә югары казанышларга ирешүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «КАМАЗ-Автоспорт» коммерциячел булмаган партнерлыгы директорының маркетинг һәм PR-коммуникацияләр буенча урынбасары **Хәйруллин** Эрик Альфред улы; республиканың финанс системасын үстерүгә мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен хезмәт ветераны **Хәмидуллина** Рүзәлия Кәримулла кызы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Эшендә ирешкән уңышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен «Ремдизель» акционер җәмгыяте генераль директоры **Захаров** Александр Владимирович, «КАМАЗ» гавами акционер җәмгыяте Мәгълүмати һәм коммуникация технологияләре үзәгенең техник сервис департаменты саклык һәм янгын сигнализацияләре цехы башлыгы **Исрафилов** Миңнехәмзә Абдулкотдус улы, «Вакууммаш» акционер җәмгыятенең механика-җыю производствосы мастеры-инструкторы **Михеев** Виталий Петрович, «ПРОФИТ» компанияләр төркеме җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директорының икътисад һәм корпоратив идарә мәсьәләләре буенча киңәшчесе **Муллахмәтов** Хәниф Шәрифҗан улы, «Вакууммаш» акционер җәмгыяте баш механигы хезмәтенең баш механигы **Сабиров** Мәҗит Шәйхи улы, «Әпсәләм төзелеш конструкцияләре һәм материаллары комбинаты» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Сафин** Илһам Ришат улы, «Казан төгәл машина төзү заводы» фәнни-җитештерү берләшмәсе» федераль казна предприятиесе генераль директоры **Хисамиев** Артур Ибраһим улы, «ТАНЕКО» акционер җәмгыятенең нефть эшкәртү заводы ароматик углеводород производствосы башлыгы **Шабалин** Владимир Евгеньевич, «Алексеевскдорстрой» ачык акционер җәмгыятенең төзекләндерү-механика остаханәсе мөдире **Шәрәфетдинов** Рифат Рәшит улы; һөнәри эшчәнлектә югары казанышларга ирешүләре һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен «Казан төгәл машина төзү заводы» фәнни-җитештерү берләшмәсе» федераль казна предприятиесе генераль директорының гомуми мәсьәләләр буенча урынбасары **Айнуллов** Марс Гыйниятулла улы, «Зеленодольскиның А.М. Горький исемендәге заводы» акционер җәмгыяте генераль директорының икътисадый куркынычсызлык, режим һәм персоналга идарә буенча урынбасары **Галиев** Даниил Әнвәр улы, «Гамәли оптика дәүләт институты» фәнни-җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыяте баш метрологы – метрология бүлеге башлыгы **Курт** Виктор Иванович, «Казан төгәл машина төзү заводы» фәнни-җитештерү берләшмәсе» федераль казна предприятиесе генераль директорының финанс-икътисад мәсьәләләре һәм персоналга идарә буенча урынбасары – икътисад бүлеге башлыгы **Рәхмәтуллина** Гөлчәчәк Нариман кызы, Казанның «Органик синтез» гавами акционер җәмгыяте генераль директоры урынбасары **Сәфәров** Рафаэль Атлас улы; югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен «А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең радиоэлектроника һәм телекоммуникация системалары кафедрасы доценты **Лаврушев** Владимир Никифорович; югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле фәнни-педагогик эшчәнлеге өчен «Иннополис университеты» югары белем бирү автоном коммерциячел булмаган оешмасы ректоры **Тормасов** Александр Геннадьевич **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен хезмәт ветераны **Мөхәммәтшина** Лалә Шиһап кызы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

«ЭНИКС» акционер җәмгыяте хезмәткәрләре: тәҗрибә производствосының ябыштыру участогы бригадиры **Ваккасов** Зөфәр Котдүс улына, баш конструкторның беренче урынбасары **Побежимов** Сергей Валерьевичка, баш технолог **Потупчик** Михаил Владимировичка, юнәлеш баш конструкторы урынбасары **Саттаров** Сөләйман Әнвәр улына, «КАМАЗ» гавами акционер җәмгыяте пресс-рам заводының буяу буенча баш белгече **Ибраһимов** Рамил Равил улына, «Әхмәт электромеханика заводы» ябык акционер җәмгыяте слесаре-ремонтчысы **Сергеев** Юрий Павловичка **«Татарстан Республикасының атказанган машина төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Россия Федерациясе Граждан оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларының нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе башлыгы, эчке хезмәт генерал-лейтенанты **Хәбибуллин** Рафис Җәүдәт улына **«Татарстан Республикасының атказанган коткаручысы»** дигән мактаулы исем бирелде.